www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 39 (1404) 7 октябрь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga



Фотограф Фәрит Гобәев өчен 2022 ел аеруча уңышлы булды: ул күләмле фотоальбомын чыгару гына түгел, шәхси күргәзмә дә тәкъдим итте.

8

Татарстанның атказанган артисты Лилия Мәхмүтова тамашачы күңелен мөлаемлыгы, сабырлыгы, моңлылыгы белән яулады.

12



Төркиянең танылган рәссамы Ялчын Гөкчәбаг эшләренең үзәк темасы – авыл тормышына мәхәббәт, хезмәт кешесенә хөрмәт.

24

Гомер буе хәлфәбезнең Фатихасы бара озатып!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан китап нәшрияты «Идел дулкыны – 2022» Халыкара китап ярминкә-фестивалендә катнашты.
- Казан мэриясендә кунакханә бизнесы, җәмәгать туклануы һәм сәүдә өлкәсе хезмәткәрләре өчен бушлай татар теле курслары башланды.
- Шагыйрә Сания Әхмәтҗанова Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Фидакяр хезмәт өчен» медаленә лаек булды.
- «Кадим Әлмәт» коллективы Идел буе һәм Урал төбәкләренә этнографик экспедицияләрдә тупланган музыкаль һәм шигъри мирас нигезендә «Гаҗәеп ирер Болгар тарихы» дигән альбомын чыгарган.
- Казанның Совет районында Татарстанның финанс министры Радик Гайзатуллинның әнисе исемен йөртәчәк «Рауза» мәчете ачылды.
- Казахстан белән Азәрбайҗан арасындагы хезмәттәшлеккә 30 ел тулу уңаеннан оештырылган фәнни симпозиумда Галимҗан Ибраһимов әсәре турында доклад тәкъдим ителде.
- Г. Кариев театры Севастопольдә балалар, өлкәннәр өчен «Хикмәт әкиятләре», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Кәҗүл читек», «Матур City» спектакльләрен уйнады.
- Пермь краеның унөч чишмәле Югары Шуртан авылында Чишмә бәйрәме узды.
- Самара өлкәсе Гали авылында ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгына, мәдрәсәнең һәм җирле мәчетнең 30 еллык юбилеена багышланган «Ислам һәм аның хәзерге дөньядагы әһәмияте» төбәкара форумы оештырылды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Разил ВӘЛИЕВ, Татарстанның халык шагыйре:

«Мин 30 ел депутат булдым, моңарчы бер язучының да анда ул кадәр әвәрә килгәне юк иде. Анда искиткеч кызыклы кешеләр бар икән, мин башта аптырап та калдым. Депутат итеп сайланып, аралашып йөри башлагач: «Болар арасында да юньле кешеләр бар икән бит!» – дим».

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 57 минутта** чыкты һәм ул **17 сәгать 04 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **11 сәгать 07 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **14 октябрьдә 10 сәгать 35 минут** тәшкил итәчәк.

СЫНАМЫШЛАР

7 октябрьдә – чегендер, 8 ендә кәбестә уңышын җыярга кирәк ● 8 октябрьдә беренче кар яуса, 21 ноябрьдән чын кыш башлана ● 15 октябрьгә кар яумаса, декабрьгә чаклы яумас.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

11 октябрь – җырчы, Татарстанның халык артисты Габделфәт Габдрахман улы Сафинга 60 яшь (1962).

12 октябрь – актер, җырчы, С.Юлаев премиясе лауреаты, Башкортстанның, Татарстанның, Россиянең халык артисты Фидан Сафа улы Гафарова 75 яшь (1947).

13 октябрь – әдәбият галиме, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллинның тууына 90 ел (1932–2021);

– әдәбият галиме, профессор, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Резедә Кадыйр кызы Ганиеваның тууына 90 ел (1932–2020).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Октябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, тулы айдан айның соңгы чирегенә кадәр **(9-17 октябрь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рабигүл әүвәл аеның 11 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Равил НАСЫЙБУЛЛИН,
социология фәннәре докторы, профессор

БӨЕК ШАГЫЙРЬ генә түгел...

2023 елда бөек шагыйребез Габдулла Тукайның бакыйлыкка күчүенә 110 ел тула. Татар халкы гына түгел, башка төрки халыклар хәтерендә дә ул бөек шагыйрь булып яши һәм яшәячәк. Әмма аның иҗаты шигърият белән генә чикләнмәгәнлеге шулай ук күпләргә мәгълүм. Тукай үзе яшәгән җәмгыятьнең икътисади, иҗтимагый, иҗтимагый-сәяси торышын, шул заманда, шул җәмгыятьтә көн күргән татар халкының тормыш-көнкүрешен гаҗәеп тирәнлектә күрә белүе белән дә, әдәби әсәрләрендә шул катлаулы процессларны тасвирлау мөмкинлекләренең гүзәл үрнәкләрен калдырган акыл иясе булуы белән дә укучыларның хәтерендә аерым урын алып тора. Мине, социолог буларак, бигрәк тә аның әсәрләрендә шагыйрьнең тормышка карашы, иҗтимагый процессларны күреп, тирән аңлап, әдәби әсәрләр кысасында укучыларның аңына җиткереп иҗат итүе сокландыра; ә ярты гасырдан артык үз балаларыннан күбрәк башка балалар белән классларда һәм аудиторияләрдә эшләгән укытучы буларак, шагыйрьнең балалар психологиясен, педагогика фәне кануннарын тирән аңлавы һәм белемен үзенең иҗатында шулкадәр оста куллана белүе хәйран калдыра.

Бу үзенчәлек шагыйрьләр арасында бары тик Тукайда гына чагыла. Ә аның рәсми рәвештә югары уку йортларында белем алмавын истә тотып фикер йөртсәк, бу чын мәгънәсендә уникаль хәл.

Мисал өчен, аның иҗатында иҗтимагый институцияләрнең эчке халәтен тасвирлаган әсәрләренә игътибар итик. Әйтик, уку-укыту, белем алу, мәгариф институциясе системасы. Шуны әйтергә кирәк: гомум алганда, Тукай яшәгән чорда татар җәмгыяте яшәешенә үтеп кергән яңалыклар мәгариф институциясенә дә тирән үзгәрешләр китерә. Бу үзгәрешләр, әлбәттә, бөтен татар халкы, барлык иҗтимагый төркемнәр тарафыннан, бертөрле кабул ителми. Төрле карашлы кешеләрнең төркемнәре арасында каршылыклар барлыкка килеп, төрле тирәнлектәге фикер бәрелешләренә генә түгел, төркемнәр арасында сыйнфый көрәшкә, хәтта кара-каршы сугышу хәленә кадәр китерә. 18 яшьлек шагыйрьнең дә бу бәрелешләрнең эчендә кайнавы аның шигырьләрендә ачык күренә. Мәсәлән, үзе укыган мәдрәсәдәге үзгәрешләр турында язган шигырендә аның еллар буе искелектә, җимерелеп-сүтелеп барган хәлдә көн күреп, иза чигеп яшәгән уку-тәрбия йорты үзе телгә килә, һәм:

“Мортаза бай!
Син тәэтмәссең бугай, –
Мин телимен Алладан
икенче бай”, –

дип, бу яшәешенә карата ризасызлыгын белдерә. Мондый авыр хәл белән килешеп яшәмәскә, бу хәлдән чыгу кирәклегенә дәгъва итә. Ниһаять, теләгенә ирешә, “игелекле кеше” килеп, кирәкле тәэтмәләрне кертеп, үзгәрешләрне башлап җибәрә.

Әлбәттә, иҗтимагый яшәештә бу үзгәрешләр төрле тирәнлектә, санап бетергесез күпкырлы һәм гаять катлаулы. Уку йортының, борынгы мәдрәсә булсынмы, хәзерге мәктәп, югары уку йорты булсынмы, аларның фасадын буяу, яисә эчендәге җимерекләрне сипләү, нинди дә булса ямау салу белән генә чикләнми. Һәм бу – элек тә, бүген дә шулай. Шуңа күрә дә, Тукайның әсәрләрендә бу үзгәрешләр, үзгәртеп корулар һәм нәтиҗәдә килеп туган каршылыкларның аның әсәрләрендә чагылышы безнең замандагы процесслар белән “бертуган” кебек тоела һәм шуның белән дә күңелгә ятыш. Әйтерсең лә Тукай безнең көнкүрештән беркая да китмәгән, ул безнең янда, безнең белән бергә мәктәптә, яисә университетларда йөри, күзәтеп торган кебек. Бу “тоелу” – аның җәмгыятьтә барган процессларны күрә-аңлый белүе, аларны матур әдәбият кысаларына салып, укучыга җиткерә белү таланты нәтиҗәсе.

Тукайның “Исемдә калганнар” әсәрендә үзенең беренче тапкыр ул заманның “уку йортына” белем алырга баруы турында язган өлешенә игътибар итик: “Әни мине кулымнан җитәкләде дә, үзебездән биш-алты гына адым булган Фәтхерахман хәзрәт өенә алып китте. Анда барып кердек. Мине укытачак абыстай кулына чыбык тотып утырган, аның тирә-ягында минем яшемдәге кечкенә кыз балалар күп булган кебек, шактый җитеп килә торган кызлар да бар иде. Алар арасында минем шикелле ир балалар да бар иде. Әни иң элек ике бөтен икмәк белән бер тиенме, ике тиенме акчасын абыстайга тоттыргач, алар да, бөтен шәкертләр дә бик озак дога кылдык”, – дип бәян итә шагыйрь егет.

Бу трагикомедик күренеш күз алдыма тулысы белән килеп баса: берәү бер-ике тиен акчаны икенчесенә “тоттыра”, икенче берәү ул акчаны “тотып ала”, ә тамашачы шәкертләр тын калып бик озак Хак Тәгалә тарафына дога җибәреп утыра. Иң әһәмиятлесе, әлеге көндә дә тын да алмый утыруларын дәвам итәләр кебек...

Тукай яшәгән чорда Россиядә шактый тирән үзгәрешләр булган, иҗтимагый каршылыклар тирәнәеп, 1905-07 еллардагы вакыйгаларга кадәр килеп җиткән. Сүз хәтта укытучы ролен башкарган абыстай кулына ике бөтен икмәк белән бер тиенме, ике тиенме акчасын “тоттыру” турында да түгел, чөнки бу безнең өчен яңалык була алмый. Бу безнең көнкүрешнең иң өстә яткан, барыбызга да таныш сыйфаты... Бары шул гына: бүгенге шигърият тебезд҄ә Тукайны борчыган хәлләр чагылыш тапмый икән, димәк, йә бездә андый хәлләр төбе-тамыры белән юкка чыккан, яисә безнең заманның андый шагыйре әле тумаган икән диген уйга киләсең.

Монысын читкә куеп, тирәндәрәк яткан каршылыкларның берсенә аерым тукталып китсәк, артык булмас. Тукай яшәгән чор татар тормышында уку-укыту институциясенең актив үзгәрү вакыты: мәдрәсәдәме, авылда мулла йортындамы, балаларны җыеп, аларга белем-тәрбия бирү кирәклеге күпләрнең аңына элеккегә караганда тирәнрәк үтеп кергән вакыт. Бер яктан, бу – һичшиксез кирәкле әйбер. Шагыйрь бу турыда 1905 елда басылган шигырендә:

“Гыйлем белән дөньяны
кулда тотты япон, немец, француз;
Без, аңсызлар, наданлык
аркасында йоклап калганбыз”, –

дип язып, үзенең шул вакытта халыкның белем дәрәҗәсе түбән булуга канәгатьсезлеген күрсәтә, уку кирәклеге турында кат-кат ачыргаланып, күп әсәрләрендә язып чыга.

Ә икенче яктан, социология фәне өйрәтүе буенча, җәмгыятьтә үзгәреш, йә нинди дә булса гомуми мәсьәлә хәл ителә икән, аның нәтиҗәсендә тәгаен берничә яңа каршылыклар килеп туу табигый хәл. Мисал өчен, Тукай үзенең 1907 елда, ягъни революцион хәрәкәткә охшаган хәлләр җиңелеп, реакция башлангач, татар телендә чыга торган гәзит-журналлар ябылган, цензураның өр-яңадан барлы-юклы ирекне дә кысуы көчәйгән чорда басылган “Азатлыкка” шигырендә әлегә кадәр барган көрәшнең кире нәтиҗәләре турында яза. Халыкның таләпләре үтәлмәгәнен, киресенчә, “...түбәннәр югары ашкан, бөекләр түбән төшкән”, “Җир аны эшкәртүчеләр өчен”, – дию юк ителгән” һәм башкаларны санап күрсәтә.

Балаларга белем бирү бик тә кирәк һәм бу урында бәхәскә урын юк. Әмма балалар яки өлкәннәр ни, кешеләр бөтен яктан бертигез һәм бертөрле була алмый. Бу – табигатьтә булмый торган хәл. Ә һәр кеше, һәр бала табигатьнең аңлап бетерә алмаслык катлаулы һәм кабатланмас, уникаль җимеше. Бу уникальлек укытучыга да карый. Грамматик кагыйдәләр булсынмы, тарихи йә арифметик мәгълүматмы, класста укытучы сөйләгәнне кайбер бала бер әйтүдә үк аңлый; кайберсенә ике-өч тапкыр кабатларга кирәк була; ә кайсы бала өйгә кайткач, кабатлап укып чыккач кына аңлый торган була. Монысы да табигый. Мәсьәлә шунда – ул балалар барысы да бер үк укытучы белән шул бер үк 40-45 минут эчендә аралашып утыра. Ә бит аның сәләте башкаларныкыннан аермалы булуда баланың гаебе юк.

“Социология фәне корифее П.Сорокин бу турыда шулай ди: “Без иң яхшы ният белән балаларны җыеп утыртабыз да, барысын бергә бер үк вакыт эчендә нәрсәгә дә булса укыта башлыйбыз. Ә алар арасында югары әзерлекле сәләтлеләр дә, сәләтләре түбән булганнар да утыра. Шул сәбәптән укыту процессы сәләтле укучыларның белемнәрен арттыру түгел, ә хәтта аны уртачага әйләндерүгә кайтып кала”. Җитмәсә, Тукай язган “мәктәптә” балалар айлар-еллар буе гарәп теле алфавитын ятлап, гарәп әлифбасын өйрәнеп утыра. Бер зур булмаган татар авылында бер йортта урнашкан “мәктәптә” очраклы рәвештә җыелган төрле яшьтәге бер төркем балалар арасында булачак бөек шагыйребез дә бар һәм ул зиһене югары булу белән шул вакытта ук башка балалардан аерылып тора.

Күпләребезгә таныш булган “Шәкертләр ни диләр” шигырендә Тукай күренекле социологның фикерен тагын да тирәнәйтә.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Җидегән
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

“ТАТМЕДИА”га – 15 яшь

Иң мөһиме – сыйфатлы журналистика

Россиянең иң зур региональ медиахолдингы – «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте оешуга 15 ел тулды. Компаниянең генераль директоры Шамил Садыйков «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгына журналистлар коллективының яңа медиалар чорына нинди проектлар белән керүен сөйләде.

– Газета һәм журналлар саны буенча Татарстан илнең күп кенә төбәкләрен уздыра. Район һәм шәһәр басмаларын бердәм дәүләт структурасына берләштерү идеясе нилектән туган?

– 15 ел элек булган вакыйгаларга кайтсак, «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте яхшы тормыштан тумаган. Ул вакытта Татарстанның медиатармагында бик күп проблемалар җыелган. Мин бу хакта ишетеп кенә белмим, чөнки ул вакытта муниципаль телекомпаниянең баш мөхәррире булып эшләгән идем. Республика җитәкчелеге алдында массакүләм мәгълүмат чараларын үстерү һәм моны системалы рәвештә эшләү бурычы куелды. Шуңа күрә медиахолдинг төзү турында карар кабул итeлде.

Баштарак район һәм шәһәр газеталары, телекомпанияләр җитди каршылык күрсәтте. Шәһәр һәм район башлыкларының барысы да мондый адымның мөһимлеген аңламагандыр, дип уйлыйм. Әмма хәзер, 15 ел үткәннән соң, барысы да моның дөрес карар булуын аңлый, ул Татарстан массакүләм мәгълүмат чараларын саклап калырга һәм аларның үсешен тәэмин итәргә мөмкинлек бирде. Күпмедер дәрәҗәдә бу карар үз вакыты өчен алдынгы булды – Россия төбәкләрендә моңа охшаш хәл күзәтелмәде. Хәзер «Татмедиа» АҖ – Россиядә иң алдынгы, иң эре, техник яктан җиһазландырылган төбәк медиахолдингы.

– Ул еллардагы район басмаларының матди базасын исәпкә алып, редакцияләрне техник яктан тулысынча яңадан җиһазландырырга туры килгән, дип уйларга җирлек бар.

– Шулай булды да. Массакүләм мәгълүмат чаралары «Татмедиа» медиахолдингына бик катлаулы хәлдә керде. Телекомпанияләр тасмалы магнитофоннарда эшләде, газета редакцияләрендә – искергән оргтехника, алар белән яңа эш форматларын куллану мөмкинлеге юк иде. Басмаларның эчтәлеге аерым игътибарга лаек. Шул ук вакытта район башлыклары массакүләм мәгълүмат чараларын үстерү юлларын ачыклый алмады, моның өчен профессиональ караш һәм зур инвестицияләр кирәк булды. Шуңа күрә республика җитәкчелегенең басмаларны, теле һәм радиокомпанияләрне үстерүгә системалы якын килүе бик дөрес иде. Хәзер Россиянең күп кенә эре төбәкләре вәкилләре Татарстанга килә, үзләрендә дә охшаш система булдыру өчен «Татмедиа» тәҗрибәсен өйрәнә. Тик һәркем дә моңа ирешә алмый, чөнки илдәге вазгыять үзгәрде, Татарстан файдаланып кала алган оптималь вакыт бүген узды инде.

– Басма матбугат аудиториясе Интернетка китә. 2022 елның беренче яртыеллыгы нәтиҗәләре буенча «Татмедиа» басмаларының тираж динамикасы нинди?

Аудитория Интернетка китә, бу – дөрес. Ләкин бу – басма матбугатның тиражын киметә, дип әйтмәс идем. 55 яшьтән өлкәнрәк аудитория газета һәм журнал укуын дәвам итә. Татарстан – халык санына туры килгән газета-журналлар саны буенча Россиянең иң күп укучы төбәкләренең берсе. Бездә язылу тиражларының кимүе беркадәр күзәтелә: газеталарда – 3 процент тирәсе, журналларда бераз күбрәк. Бу, нигездә, «Россия Почтасы» эше белән бәйле, ул чыгымнарына бәяләрне гел арттырып тора. Өстәвенә, аларның матбугатны китереп җиткерү белән дә проблемалары чыкты – почтальоннар җитми һәм бүлекләрнең эш режимы бар җирдә дә безнең абунәчеләрне канәгатьләндерми.

Шул ук вакытта, без басмаларны ваклап сатуга керештек. Сыйфатлы эчтәлек булдырып һәм матбугатны сатып алуны җайлаштыру хисабына тиражны арттырып булуын күрәбез, мондый мисаллар бар. Подписка кими, әмма без «Татмедиа» акционерлык җәмгыятендә моны газета-журналларны ваклап сату челтәрләре үсеше белән компенсацияләргә тырышабыз. Без продуктларны онлайн ресурслар, киосклар, альтернатив язылу хезмәтләре аша пропагандалыйбыз. Гомумән, без басма матбугат тиражларын саклап калуга ирештек.

– Медиахолдингның продуктларын алуны тагын да җайлырак итү өчен нинди яңа ысуллар кулланыла?

– Подписканы стимуллаштыруның иң төп коралы – зур шәһәрләрдә дә, кечкенә торак пунктларда да басма продукциянең кешегә якын булуын булдыру. Бу – безнең төп бурыч. Мөмкинлекне арттыру өчен, без берьюлы берничә юнәлешне үстерәбез. Казанда кеше күп йөри торган урыннарга: метро станцияләренә, тимер юл һәм автомобиль вокзалларына куела торган вендинг автоматлары сатып алдык. Бүгенге көндә Казанда 17 автомат бар, якын арада аларның саны 20 гә җиткереләчәк. Сату машиналары нәтиҗәле булуларын исбатлады, чөнки алар аша сату күләме газета киоскларына караганда югарырак. Мондый машиналар белән эшләүнең киләчәге бар.

(Дәвамы 5 нче биттә).

Мөнәсәбәт

Кагыйдәсез уеннар

Цивилизацияле яшәештә кешеләргә ниндидер уртак кагыйдәләргә буйсынып яшәү кирәк. Зурдан алганда, адәми зат өчен мондый хәл эшчәнлекнең барлык өлкәләренә дә кагыла. Хәтта хәрби бәрелешләр чорында да кешеләр билгеле бер кагыйдәләрне бозарга базмаган (бала-чага, хатын-кызлар, карт-корыга каршы сугыш коралы кулланылмаган; яралыларга карата гуманлылык күрсәтелгән һ.б.). Үткәндәге сугышларда халыкара әһәмияткә ия трассаларга (электр линияләре, газ вә нефть үткәргечләре һ.б.) мөнәсәбәт тә сакчылрак булган. Әмма, бүгенге глобаль (сәяси яки икътисади яктан гына түгел, ә рухи, әхлакый һәм хокукый планда да) кризис һәм соңгы вакытларда күзәтелә торган кайбер хәтәр хәлләр боларның һәммәсе дә үткәндә калуы, әхлак нормаларының җимерелүе, адәми затның бу яктан отыры урта гасырлар кыргыйлыгына кайта баруы турында сөйли. «Төньяк агымы-1» һәм «Төньяк агымы-2» газ үткәргечләренең Дания һәм Швеция өлешендә 26 сентябрьдә (бер үк көндә!) өч торбаның сафтан чыгарылуы (ә 29 сентябрьдә Швеция үз зонасындагы торбаларда инде тагын бер тишелгән урын тапкан) һәм экологиягә дә җитди зыян салынуы моны янә бер кат раслый. Сейсмик үзәкләр бу зоналарда су астында көчле шартлатулар булуын да теркәгән. Шуңа күрә бу язмабызда инде, ошбу вакыйгага карата рәсми фикерләр төрлелеген чагылдыру белән бергә, игътибарны мәсьәләнең сәяси ягына да бераз юнәлтербез.

Әүвәл шунысын да искәртеп үтик, рәсми яктан барлык илләр дә ошбу вакыйгаларны алдан уйлап кылынган җинаять буларак бәяли. Аерма шунда гына – берәүләр (ЕС, НАТО, Алмания, Дания һ.б.) аларны диверсия дип саныйлар, икенчеләре (АКШ, Швеция һ.б.) инде аңа «саботаж» дигән мәгънә дә өсти. Кремльдә исә әлеге хәтәр хәлне «дәүләт дәрәҗәсендә үткәрелгән террор акты» буларак та бәялиләр. Моның белән дә килешергә кирәктер, чөнки Дания һәм Швеция андагы шартлату егәрен, тротил эквивалентына күчергәндә, 500 кг чамасы дип саный. Шартлатуларның 60 м тирәнлектә диңгез төбендә һәм яхшы ныгытылган торбаларны җимерерлек итеп башкарылуын да исәпкә алсак, чыннан да, аның дәүләт дәрәҗәсендә оештырылуында шик калмый. Тик, нинди дәүләт икән соң ул? Әлегә бу сер булып кала. Әмма техник яктан кайсы дәүләтләр андый мөмкинлеккә ия булуын ачыклау инде шикләләр санын күпкә киметергә дә мөмкин. Әлегә исә Россия һәм Көнбатыш бер-берсен гаепләүдән ары китә алмый. Моның өчен алар бер-беренә шик төшерә торган дәлилләр китерә һәм шартлатуларның кем өчен отышлы булуыннан чыгып та эш итә.

Мәскәү гаепне алдан ук АКШка аудара һәм Ак йорт хуҗасы Джо Байденның февраль башында әйткән, әгәр Россия Украинага басып керсә, «Төньяк агымы-2» булмаячак, дигән сүзләрен искә төшерә, андый адымның икътисади яктан АКШ өчен отышлы булуын да әйтә. Чөнки, ул аңа сыек газны Европага күпләп сату һәм зур керемнәр алу мөмкинлеге бирәчәк. Шартлатуларның АКШ разведкасы контролендәге зонада булуы да телгә алына. Сәяси яктан исә, Кремль әлеге шартлатуларны «халыкара террорчылык акты» буларак та бәяли. Россия президенты В.Путин әйтүенчә, «англосакслар»га санкцияләр генә аз булып тоела, шуңа алар хәзер гомуметвропа энергетика инфраструктурасына да кизәнә. Шул ук вакытта, Мәскәү бу җинаятьне Көнбатыш илләре кылуын раслый торган мәгълүматның булмавын да таный. Вашингтон исә, АКШ президенты үз сүзләрен «Төньяк агымы-2»не, Алмания ярдәме белән, эксплуатациягә кертмәүне күздә тотып әйтүе һәм моның нәкъ шулай эшләнүе турында әйтә. АКШ дәүләт секретаре Э.Блинкен Мәскәүнең Көнбатышны гаепләүләрен абсурд дип атый, әмма җинаятьнең сәбәпләрен ачыкларга һәм аларны җәмәгатьчелеккә дә җиткерергә вәгъдә итә. Газ үткәргечләрдәге шартлату 30 сентябрьдә БМО КШ утырышында да тикшерелгән.

Әлбәттә, җинаятьне ачуда аның кем өчен отышлы булуын ачыклау зур роль уйный. Тик, сүз әлегә икътисади як турында барды. Ә бу очракта мәсьәләнең сәяси ягын да исәпкә алу лязем, чөнки бериш дәүләтләрдә бүген бар нәрсә дә сәясәткә буйсындырылган. Бу яктан, әлеге «диверсия» Көнбатыш өчен берничек тә отышлы була алмый, чөнки кышка каршы ике агымның да сафтан чыгарылуы халыкта канәгатьсезлек һәм паника гына уятырга мөмкин. Искә төшерик, «Төньяк агымы-2» сафка кертелмәгәч, ясалма сәбәпләр белән «Төньяк агымы-1» дә туктатылды. Ул чакта Мәскәүдән, «газ кирәк булса, әнә, «Төньяк агымы-2» әзер», дигән тәкъдим дә ишетелде. Әмма Көнбатыш моңа колак салмады. Шуннан соң инде әлеге вакыйга килеп чыкты да. Аның асылын, әлбәттә, төпле тикшерү нәтиҗәләренә таянып, халыкара суд кына ачыклый ала.

Фоат УРАЗАЙ.

Тамашачы бәясе югары

Анапада XXXI «Киношок» кинофестивале тәмамланды. Җиңүчеләр исемлегендә Татарстаннан «Микулай» фильмы белән Илшат Рәхимбай һәм кыска метражлы «Пувырга» картинасы белән Влад Петров бар. «Пувырга» кыска метражлы фильмнар арасында иң төп призны яулады, ә «Микулай» фильмы фестивальнең Матбугат призына лаек булды.

«Бу Россиянең иң борынгы фестивальләренең берсе. Аны карарга белгечләр, шул исәптән, профессиональ журналистлар да килә. Кинофестивальдә бер кызыклы чара бар – фильм күрсәтелгән көнне кич белән матбугат конференциясе үткәрелә. Анда дистәләгән рецензентлар белән фильм турында фикер алышу үткәрелә, – дип сөйләде Илшат Рәхимбай. – «Микулай» турында яхшы сүзләр Татарстан мәдәниятенә карата игътибар уятты. Мондый фильмга нәрсә этәргеч булган дип фикерләшүләр булды. Төрле сәяси сораулар аркасында төп призны Монголия фильмы алды»..

Илшат Рәхимбай, җиңүгә караганда, фестиваль барышында булган очрашулар һәм фикерләр күпкә мөһимрәк булуын ассызыклады. Ул иң мөһиме фильмның профессиональ җәмәгатьчелеккә күрсәтелеп аларның уңай бәясен алу икәнлеген әйтте: «Фильмның тамашачыга ошавыннан да зуррак җиңү була алмый».

«Киношок» фестиваленең «Киномалышок» балалар фильмы конкурсында махсус призга Мостай Кәрим әсәре буенча куелган «Таганок» фильмы белән Айнур Әскәров ия булды.

Рузилә МӨХӘММӘТОВА.

1 нче биттә – «Ел укытучысы» бәйгесенең төбәк этабыннан бер күренеш. Фото: zainsk-inform.ru

Игътибар үзәгендә – мәгариф мәсьәләләре

Казанда көн дәвамында мәгариф хокукларын яклау мәсьәләләре буенча «Хатын-кыз игътибары» кайнар линиясе эшләде. Аны Дәүләт Советының «Мәрхәмәт-Милосердие» берләшмәсе әгъзалары Татарстанда Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил белән берлектә үткәрде. Сорауларга, бер-берсен алыштырып, депутатлар һәм хокук яклаучылар, Татарстанда кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил аппараты хезмәткәрләре, министрлыклар һәм ведомстволар вәкилләре җавап бирделәр, аңлаттылар, һөнәри консультацияләр бирделәр.

«Кайнар линиягә йөзгә якын кеше мөрәҗәгать итте, – диде «Мәрхәмәт-Милосердие» депутат берләшмәсе җитәкчесе Алсу Нәбиева, – районнардан каникулларга, мәктәп балаларын эчәргә яраклы су белән тәэмин итүгә, өстәмә белем бирүне оештыруга, мәктәпләр төзүгә, патриотик тәрбиягә, транспорт белән тәэмин итүгә, мәктәпнең биш көнлек уку режимына күчүенә бәйле күп кенә сораулар килде. Сорауларның бер өлеше мәктәпләрдә психологик хезмәтләрнең эшен көчәйтүгә кагылды».

Еш бирелә торган сораулар арасында – мәгариф оешмаларында балаларның иминлеген саклау. Ата-аналар Ижаудагы фаҗига уңаеннан бик борчылалар. «Ата-аналарның куркынычсызлык мәсьәләләре буенча борчулары бар, сораулар күп, – дип сөйләде Социаль сәясәт комитеты рәисе Светлана Захарова, – Бу уңайдан Татарстан бюджетыннан акчалар бүлеп бирелде, мәктәпләрнең ишегалды территорияләрен ныгыту, профилактик чаралар уздыру, саклау агентлыклары эшен оештыру буенча зур эш башкарылды».

Кайнар линия эше кысаларында саулыгы аркасында мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укыту буенча күп сораулар килгән. Бу инклюзив укытуга да, йомгаклау аттестацияләрен оештыруга да кагыла. Мөгаллимнәр җитмәү проблемасы кала. «Һичшиксез, ата-аналары мәктәптән, һөнәри белем бирү учреждениеләреннән соң мөмкинлекләре чикләнгән балаларны укыту мәсьәләсе борчый, – диде Светлана Захарова, – хезмәт базарында яңа һөнәрләр барлыкка килә. Аларга инвалидлыгы булган балаларны өйрәтәләрме? Мондый сорауларны карау өчен түгәрәк өстәл уздырырга кирәк дип уйлыйм».

Өч яшькә кадәрге балалар бакчаларында урын җитмәү мәсьәләсе үзенең актуальлеген югалтмый. «Бүген безнең проблеманы хәл итүнең берничә юлы бар, – диде Алсу Нәбиева, – мәсәлән, Казанда балаларны Яңа Савин районында ясле төркемнәренә урнаштыру мөмкинлеге бар. Сорауны шәхси тәртиптә дә хәл итәргә мөмкин. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгында әлеге мәсьәләләр буенча кайнар линия эшли».

Яхшы ниятле эшләр

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Нәзарәттә Бөтенроссия мөселман яшьләре форумында җиңү яулаган иң яхшы социаль проект авторларын бүләкләде. Форум июль ае ахырында бер атна дәвамында Россиянең төрле почмакларыннан килгән 150 гә якын 18-30 яшьлек мөселманнар һәм мөслимәләр катнашында үткән иде.

Мөселман җыены Россия өммәте файдасына социаль проектлар булдыру һәм аларны гамәлгә ашыру өчен мөмкинлекләр мәйданчыгы булараk уздырылды, ягъни яшьләрне Россия мөселман җәмәгатьчелеге тормышындагы төрле мәсьәләләрне хәл итүгә кагылышлы социаль стартапларны оештырырга өйрәтте: алар идея рәвешендә яки грант алырлык әзер проект булырга мөмкин иде. Форумда катнашучылар барлыгы 91 проект тәкъдим итте. Алар арасында: интернет, кино, мәгърифәтчелек, инфраструктура, экология, спорт, хәйриячелек белән бәйле булган, шулай ук хатын-кызлар, балалар һәм яшьләр, шәхси үсеш өчен атап эшләнгән проектлар бар иде. Проектлар, спикерларның киңәш-тәкъдимнәрен исәпкә алып, камилләштерелде һәм тулыландырылды. Катнашучылар хәзерге вакытта үз проектларын тормышка ашыру эшенә керешә.

Болгар шәһәрендә узган форумда катнашучыларның «Понимающий подкаст для мусульманский молодежи» һәм «41 чишмә: Чапшар авылының тарих һәм мәдәни мирас музее» проектлары җиңүче дип табылды. Аларның авторлары мөфти кулыннан диплом һәм акчалата бүләк алды. Җиңүчеләр Камил хәзрәтне үз проектлары белән якыннан таныштырды, хәзерге вакытта тормышка ашыру барышын сөйләп узды.

«Понимающий подкаст...» проектын Казан яшьләре – Ксения Кириллова, Каусәрия Мәүлетдинова, Камилла Магамедова тәкъдим итте. Кызларның проекты аудио һәм видео форматында подкаст мәйданчыклар өчен ислам дине темасына материаллар яздыруны үз эченә ала, подкастларны алар мөселманча караштан чыгып гомумкешелек темаларына төшерәләр. Соңгы арада, мәсәлән, алар «Ислам динен кабул иткәндә үзеңне ничек тотарга» дигән тема буенча эшләгән.

«41 чишмә...» проекты белән Балтач районыннан Алсу Әсәдуллина, Ләйсән Мадиярова, Гөлфинә Фәйзуллина шөгыльләнә. Алар элекке клуб бинасында авыл музее төзергә һәм бу мәйданчыкта яшьләр өчен кызыклы чаралар үткәрергә җыена.

Нәзарәт премияләреннән тыш, социаль стартап төзегән 3 командага РФ Мөселман эшмәкәрләре ассоциациясе махсус акчалата призлар тапшырды, ә «Ярдәм» хәйрия фонды 2 проектны тормышка ашыру өчен мәйданчык бирде.

Бөек шагыйрь генә түгел

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Уку йортына җыеп утыртып, аларга кыйммәтле мәгълүматны барысына тигез итеп бүлеп бирү генә тиешле күләмдә укучыны белемле, башкаларга, җәмгыятькә файдалы белгеч булыр өчен җитәрлек шарт була алмый. Шуңа да шагыйрь егетебезнең шәкертләре:

– «күп яттык без мәдрәсәдә, аңламадык бернәрсә дә»;

– «яктылыктан ни килсә дә, аны куа торган булдык»;

– «йоклый торгач, череп бетеп, бөҗәккә әйләндек»;

– «әхлакны, вөҗданны сөреп чыгардык»;

– «азган-тузган кызлар төсле бетләп яттык»;

– «яшьлекне наданлыкка корбан итеп, тол хатыннарга йортка кердек», – дип тагын күп «казанышлары» турында сөйли. Тукайның мәдрәсәдә укуын тәмамлаган елда, 21 яшендә бастырып чыгарган бу шигырен укучылар, бигрәк тә шәкертләр, бик җылы каршы алган.

Ничек кенә булмасын, һәр җәмгыятьтә тарих буена барган каршылыклар булган һәм бүген дә бар. Уку-укыту институцияләре дә, җәмгыять тормышының башка өлкәләре кебек үк, кеше белән табигать, шәхес белән җәмгыять арасында һәрдаим килеп туган каршылыкларны җайга салу юлында көн күрә. Бу юлда әдәбиятның, шигъриятнең, шагыйрьнең роле бәяләп бетергесез. Чөнки алар җилкәсендә дөньяның рухи нигезе. Яшәешнең матди-техник нигезендә хезмәт куючылар саны миллионнар белән исәпләнсә, рухи нигезендә, бигрәк тә шигъриятендә, берәмтекләп санарлык кына.

Г.Тукайның иҗатында соклandырган тагын бер ягы – аның балалар өчен язган әсәрләре тәрбияви яктан укучыларга тәэсир итү көче белән аерым игътибарга лаек. Беренче чиратта, бу, әлбәттә, әсәрләренең гади һәм шул ук вакытта әдәби тел белән язылуында. Моннан тыш, әсәрләрнең сюжет төзелеше, сәнгатьчә матурлап, бизәп язылган, бигрәк тә педагогика кануннарын аңлап, аның алымнарын актив кулланып язылган әйберләренең балаларның «таләбе»нә туры килүе.

Дөрес, мондый әсәрләр иҗат итәр өчен балалар психологиясен һәм педагогикасын белергә, аңларга кирәктер. Моның өчен, беренчедән, авторның үзенә күп укырга кирәк; икенчедән, укыр өчен, үрнәк булырлык талантлы укытучыларының иҗат җимешләре булу мотлак. Ә бу яктан караганда Тукайга юл уңай туры килә. Аның укытучылары – дөньякүләм билгеле булган язучылар, шагыйрьләр. Алар арасында бигрәк тә мәсәлләр иҗат итүче И.Крылов, бөек урыс язучысы Л.Толстой. Билгеле булуынча, аның балалар өчен язган әсәрләре, 1874-75 елларда «Новая Азбука» исеме астында махсус уку китабы итеп төзелеп, бастырып чыгарылган.

Тукай да күптән үзенең татар мәктәпләрендәге балаларга уку өчен җыентык чыгару теләге белән яши, моның өчен Л.Толстойның шул җыентыгын үрнәк итеп алганын әйтә. Аның әле 1906 елларда ук балалар өчен язган әсәрләре, тәрҗемәләре бар. Алар да бу җыентыгына теркәлгән. Билгеле булуынча, укучы балаларның нәфис әдәбиятка караган әсәрләргә таләбе үзенчәлекле. Әйтик, әсәрдә ямьсез кыланышны сурәтләгәндә уңай күренешне кулланып, матур тәртип белән чагыштырып, кара-каршы куеп күрсәткәндә, яхшылыкка өндәп әйтелгән өстәмә сүзләрнең кирәге дә калмый. Укучы үзеннән-үзе матур тәртипле герой ягына тартылып, аның тәртибен хуплап, аңа ярдәм итү юлына баса, аның өчен борчылу, кайгыру кебек кичерешләргә күчә. Шуңа күрә дә күп вакыт аңа нинди нәтиҗәгә килергә кирәклеген әйтүнең кирәге дә калмый.

Үз вакытында югары бәя алган җыентыкның бүгенге көндә дә, бигрәк тә балаларны уку-укыту, аларның системага салынган белем нигезендә тормышка карашларын тәрбияләүгә шагыйрьнең мөнәсәбәтен, татар халкы тарихының, әдәбиятының, мәдәниятенең тирән тамырларын күрсәтү юлында әһәмиятен сызык өстенә алыр идем. Шулай да, бу урында «үз вакытында» сүзенә кайтып, шуны өстәп әйтү урынлы. Шагыйрь, җыентыкны төзүче буларак, үзенең «сүз башында» ук бурычын ачыклап, яңа үсеп килгән милли әдәбият бакчасыннан анда әлегә кадәр яшәп килгән әрекмән, кычыткан, балтырганнарны кертмичә, хуш исле гүзәл чәчәкләрен аерып алып, сабый балаларыбыз кулына бер букет тапшыру кирәклеген нигезли. Беренчедән, балаларның рухларына никадәр булса да азык бирүне бурыч итеп алса да, күз алдында икенче мәсьәлә торуына да басым ясый. Ул вакытта да җәмгыятьтә тормышка карашның күптөрле булуы табигый, һәм бу хәл әдәбиятка да, мәгариф өлкәсенә дә, башка өлкәләргә дә карый. Әдәбиятның мәктәпкә үтеп керүе нәтиҗәсендә укучы татар балаларына киләчәк буынга кирәкле рухи азык һәм тәрбия бирү мәсьәләләренә гомуммилләт тарафыннан игътибар һәм илтифатны арттыру кирәклеген аңлауга бер этәргеч булуына дә өмет итә шагыйрь.

«Кызыл таң» газетасыннан.

● Хоккей тарихында иң яхшы бомбардир Уэйн Гретцкиның «Эдмонтон Ойлерс» составында соңгы уенында кигән свитеры аукционда 1,452 миллион долларга, перчаткалары 204 162 долларга сатылган.

● Пәрәвез – иң нык табигый материаллардан берсе. Көньяк Америка тарлавыкларындагы пәрәвез күперләрдән маймыллар рәхәтләнеп йөри. Яңа Гвинеядә исә пәрәвез ятьмә белән балык тоталар.

● Җирдә һәрвакыт 10 квадрильон чамасы кырмыска яши, әлеге бөҗәкләр планетадагы хайваннарның тулаем биомассасының 15-20 процентын тәшкил итә. Кырмыска үзеннән 5меңтапкырга авыррак йөк күтәрергә, секундына 20 сантиметр тизлек белән (әгәр кеше шулай ук тиз йөгерә алса, тизлеге сәгатенә 55 чакрым булыр иде) хәрәкәтләнергә сәләтле. Һәр колониянең үз исе бар, шунлыктан кырмыскалар чакырылмаган кунакларны мизгел эчендә сизә.

ИҢ МӨҺИМЕ – СЫЙФАТЛЫ ЖУРНАЛИСТИКА

(Ахыры. Башы 3 нче биттә).

Икенчесе – без продукцияне онлайн алып булу мөмкинлеген арттырабыз. Хәзер Калининградтан Камчаткага кадәр һәр торак пунктта Wildberries, Ozon, KazanExpress, Яндекс.Маркет маркетплейсларының постаматлары бар. Без инде ярты ел басма продукцияне маркетплейслар челтәре аша актив сатабыз.

Хәзер электрон сәүдә каналлары аша газета, журнал һәм китап сатуның күләме киоскларда сату күләме кадәр булды. Бу – бик мөһим нәтиҗә. Иң мөһиме – Россия төбәкләрендә яшәүче татарларның туган телләрендәге басма продукция сатып алу мөмкинлеге бар.

– «Татмедиа» холдингының үз продукциясен сату челтәрен үстерү буенча проектлары бармы?

– Безнең алда басма продукцияне сата торган үзебезнең системаны булдыру бурычы тора. Без Казанның барлык киосклары белән эшлибез, барлык почта бүлекчәләрендә дә үзебезнең киштәләрне куярга тырышабыз. Кибетләрдә һәм элемтә бүлекчәләрендә безнең продукцияне өскә чыгарып кую системасы безнең журнал һәм газеталар сатылышын берничә мәртәбә арттырды.

Моннан тыш, һәр район газетасы альтернатив сату нокталары булдыра. Кайбер районнарда аларның саны 40ка җитә. Редакция хезмәткәрләре үз машиналарында газеталарны кибетләргә, социаль объектларга тарата. Болар барысы да нәтиҗә бирә. Без подписка тиражларының кимүенә, ә ваклап сатуның бу кимүне компенсацияләвенә ирешәбез.

– Россиядә медиаконтентны цифрлы мохиттә кулланучыларның саны арта. «Татмедиа»ның интернет версияләрен карау саны ничек үзгәрде?

– Әле 5 ел элек кенә без район басмалары үз сайтларын актив үстерсен өчен эшләү юлларын корган идек. Ләкин хәзер сайтларның вакыты уза. Социаль челтәрләр һәм мессенджерларның үсеше сайтлар аудиториясенең артмавына китерде. Контент куллану Telegram, WhatsApp, социаль медиага күчә. Укучыларга мондый мәйданчыкларны файдалану күпкә җайлырак, без моны эш барышында исәпкә алабыз. Тик шулай да без сайтларны да үстерергә тырышабыз. Күптән түгел «Татмедиа» акционерлык җәмгыятендә барлык филиалларның сайтларын модернизацияләделәр, аларны яңа админкага күчерделәр, кулланучы интерфейсларын оптимальләштерделәр.

– Хәзерге аудитория эчтәлек ягыннан нинди мәгълүматка өстенлек бирә?

– Хәзерге аудитория аз сүзләр белән күпне сыйдырган кыска мәгълүматны якын итә. Шул ук вакытта хәзер без зур форматларга – лонгридларга зур ихтыяҗ күзәтәбез, алар республикада, илдә, дөньяда барган вакыйгаларның асылын аңлата. Автор фикере бик кирәк. Халык үзләрен кызыксындырган сорауларга җавап табарга тели. Кешеләр яңалыклардан арыды, аларның теге яки бу фактларның ни өчен булганын аңлыйсы килә.



«Сторителлинг» форматындагы мәкаләләр аеруча кызыксыну уята, бу мәкалә-тарихларда бер кешенең тормышы сурәтләнә. Аларда уңышка ирешү тарихы яки, киресенчә, тормыш фаҗигасе булырга мөмкин.

Күптән түгел без «Татмедиа»да журналистлар өчен сторителлинг буенча семинар үткәрдек, анда федераль массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен чакырдык. Район басмалары журналистлары бу эш юнәлешен активрак үзләштерсен өчен, «Татмедиа» медиа-мәктәбе дә укуга кушылды.

– Яшьләргә яңалыкларны социаль челтәрләрдән һәм Телеграм каналлардан уку уңайлырак. «Татмедиа»да аудиториянең әлеге өлеше белән эш ничек җайга салынган? Бу юнәлештә нинди проектлар тормышка ашырыла?

– Медиа куллануның хәзерге картинасы: 30 яшькә кадәрге аудитория – тулысы белән социаль челтәрләрдә, 30-40 яшьтәге кешеләр социаль челтәрләр белән дә, сайтлар белән дә кызыксына, ә 55 яшьтән өлкәнрәкләр традицион медиа куллануны дәвам итә. Бу – газета, телевидение, радио.

Мондый күренеш аудиториянең бүленешен, ә ул массакүләм мәгълүмат чараларының билгеле бер тармакларга бүленүен күрсәтә. Бу юнәлештә яңа медиаларга ихтыяҗ туа, алар һәрвакыт сайт яки газетага гына бәйле була алмый. Бу – социаль челтәрләрдәге, мессенджерлардагы мәйданчыклар булырга мөмкин, алар махсус аудитория таләпләренә җавап бирергә тиеш.

Россиядә яңалыклар тәртибен формалаштыручы төп медиа-платформа – Telegram. Бу мессенджер медиа куллану пирамидасының иң башында тора. Барлык оператив мәгълүматны кешеләр беренче чиратта аннан белә.

Telegram мәгълүмати фон булдыра, шуңа күрә заманча массакүләм мәгълүмат чаралары башта мәгълүматны үз Телеграм каналларында, аннары социаль челтәрләрдә һәм, соңрак, сайтта урнаштыра. Шуңа күрә Telegram үсешенең индексы – медианың эффективлык күрсәткече.

Татарстанда Telegram үсеше өлкәсендә лидерларның берсе – ул «Татмедиа» АҖ. Бездә 40 каналдан торган челтәр бар, язылучыларның гомуми саны 110 меңнән артып китә. Без Телеграм каналларны рус телендә генә түгел, татар телендә дә булдырабыз.

– «Татмедиа» медиахолдингының аудиториясе Татарстан территориясе белән генә чикләнми, чөнки татар диаспоралары Россиянең күп төбәкләрендә бар. Монда эш ничек?

– «Татмедиа» медиахолдингы Россиянең барлык төбәкләренә дә эшли. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгының яңалыкларын яки татар телендә эшли торган «Интертат» сайтын бөтен илебездә укыйлар. Бездә «Без бергә» проекты бар – ул бөтен Россиядә, татарлар яшәгән төбәкләрдә чыга торган барлык татар телле газеталарның кушымтасы. Бер ел элек без «Миллиард.Татар» проектын булдырдык, ул бик уңышлы булып чыкты. Аны Новосибирскида да, Камчаткада да, Уралда да укыйлар.

– Тенденцияләр реклама базары торышында ничек чагыла? Татарстанда реклама базары үсештәме?

– Реклама базары үзгәрә, ул җайга салына торганга әверелеп бара. Нәтиҗәлелек күзлегеннән караганда, беренче планга натив реклама чыга. Туры реклама элеккеге кебек уңышлы эшләми. Без тармакта барлыкка килгән заманча тенденцияләргә игътибар итәргә тырышабыз. «Татмедиа»ның өлеше реклама базарында медиахолдингта барлык төр мәгълүмат чаралары, барлык жанр форматлары тәкъдим ителү хисабына кимеми. Киң колачлы мөмкинлекләр бәрабәренә без базарның зур өлешен колачлыйбыз.

Хәзерге вакытта бастырылып чыгарыла торган реклама күләме кими, ләкин бу рекламаның онлайн һәм социаль челтәрләрдә артуы белән каплана. Соңгы вакытта төп үсеш динамикасы – Интернет сайтларга, икенче урында – радиостанцияләргә туры килә. Радио кече һәм урта бизнес өчен төп реклама коралы булып кала бирә. Бу сегментта тотрыклы үсеш тә бар. Реклама төшүен без телевидение өлкәсендә һәм матбугатта күзәтәбез, әмма болар барысы да социаль челтәрләр һәм Интернет хисабына тулыландырыла.

– Киләчәктә медиа куллану ничек үзгәрәчәк? «Татмедиа» АҖ бу үзгәрешләргә, нинди дер инновацион проектларга әзерме?

– Медиа-продукцияне куллану вакыт узу белән көчлерәк тармакларга бүленәчәк, ә гаммәви мәгълүмат чаралары төрләре киңәячәк. Вакытлар узу белән, һәр кеше, шәхси мәнфәгатьләреннән чыгып, мәгълүмат куллану коралларын гаджетлар ярдәмендә активрак киңәйтәчәк. Бу хәл инде күзәтелә. Без дә бу юнәлештә эшлибез.

Инвестицияләрнең 70 процентын хәзер яңа медиага юнәлтергә кирәген аңлыйбыз, чөнки киләчәк турында бүген үк уйларга кирәк. Безнең өчен, һичшиксез, традицион медиа – газеталарга, радио, телевидениегә инвестицияләр кертү мөһим, чөнки алар, вакыт узу белән, үзләренең тирәсендә медиа куллану экосистемалары формалаштырачак: болар – Интернет мәйданчыклар, социаль челтәрләр.

Гомумән, безнең өчен өстенлекле булган түбәндәге үсеш юнәлешләр бар. Беренчесе – мессенджерларда проектлар үсеше, икенчесе – видеопроектлар, өченчесе – балалар медиасы үсеше.

Хәзерге балалар кулларында гаджетлар белән үсте, һәм без аларга татар халкының телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен өйрәнергә мөмкинлек бирә торган 30дан артык төрле проект эшләтеп җибәрдек. Бу проектлар хәзер бик уңышлы, аларның бәхәссез уңышы – мультимедиа. Әйтик, «Салават күпере» журналын кулына алган бала аны башта укый, аннары анда рәсем ясый, аннары наклейка ябыштыра, һәм QR-код буенча сайтка күчә, видеоконтент карый. Шулай итеп, медиа куллануның яңа форматы формалаша.

Безнең өчен дүртенче мөһим юнәлеш – мем-журналистика үсеше, чөнки 20 яшьтән 30 яшькә кадәрге яшь буын яңалыкларны мем форматында, юмор аша куллана. Моның өчен без KARA проектын эшләдек.

Бишенче төп юнәлеш – әдәбиятны үстерү. «Казан утлары» журналы күптән түгел PocketBook форматындагы кесә китаплары чыгара башлады. Бүген 40 меңнән артык данә тираж белән 15 тән артык китап басылып чыкты һәм бу продукциянең якынча 70 проценты инде сатылып беткән. Уңышы нәрсәдә? Безнең китапларның эчтәлеге бик гади, аңа ихтыяҗ бар. Икенчедән, басмаларның форматы бик уңайлы, өченчедән, без бу китапларны үзебезнең мәйданчыкларда һәм интернетта рекламалыйбыз. Без аларны маркетплейс һәм вендинг автоматлары аша сатабыз. Китапларны пропагандалауның яңа форматы безгә аудиторияне киңәйтергә мөмкинлек бирә.

Моннан тыш, «Татмедиа»да әдәби радио – «Китап» бар, анда Татарстан кешеләре шигырьләр, әдәби әсәрләр, аудио спектакльләр тыңлый ала. Шулай ук без почта открыткаларын бастыруны үстерәбез, бу да – татар мәдәниятен популярлаштыра торган перспективалы юнәлеш.

Без һәрвакыт яңа эш ысулларын эзлибез, яңа эчтәлек булдыру һәм алга җибәрү технологияләрен өйрәнәбез. Моның белән «Татмедиа» медиа-мәктәбе шөгыльләнә. Без яңа медиа чорында эшләү үзенчәлекләренә багышланган дәреслек эшләдек. Аны шулай ук маркетплейсларда сатып алырга мөмкин. Тормышның бик тиз үзгәрүен күрәбез. Яңалыкларның киләчәге – роботизация. Инде хәзер үк «Снег» сайтында яңалыкларны робот яза, бу – безнең өчен эксперимент. Шул ук вакытта медиа өчен иң мөһиме – сыйфатлы авторлык журналистикасы икәнен аңлыйбыз. Шуңа күрә профессиональ журналистларның эше һәрвакыт кирәк булачак.

Алексей УГАРОВ.
Алена НИЗАМОВА
тәрҗемәсе.
intertat.tatar

Шагыйрә сабак бирә

Камал театрының «Шәрык клубы»нда язучы-шагыйрә, галимә-педагог Рифә Рахман белән очрашу булды. Ул, нигездә, шигырь язуга багышланган иде. Башта – язучыларга хас булырга тиешле сыйфат-билгеләр турында. Рифә Рахман фикеренчә, шагыйрь өчен детальләрне күрә белү мөһим.

– Кеше чын шагыйрьме, юкмы икәнне күп билгеләр күрсәтә. Беренчедән, шагыйрь башкалар күрмәгән детальләрне күрергә тиеш. Мин урамнан барганда кешеләрнең йөзенә карамыйм. Миннән: «Фәлән кешене күрмәдегезме?» – дип сорасалар, «Нинди күлмәк кигән иде», – дим. Кешенең күлмәге, атлавы, аяк киеме исемдә кала. Миңа кешенең исемен истә калдыруы авыр, әмма кеше нәрсә әйткән, ул вакытта нәрсә кигән, ничек хәрәкәт иткәне онытылмый. Мин кешенең характерын, гадәтләрен хәтерлим. Бу – шагыйрьлек өчен бик кирәк, – дип аңлатты ул.

Икенче билге – тиз уйлау. Рифә апа үзенең кызу кеше булуын, бер утыруда бик күп шигырь язып куя алуын да ассызыклый.

«Озаклап шигырь язган кеше минем өчен – «ясаучы». Шагыйрьдә уй җитезлеге булырга тиеш. Шигырь – хис һәм фикер берлегеннән туган әсәр. Хис һәм фикер ул прозада да бар. Минем өчен иң матур билгеләмәсе – ситуациядән чыккан тезмә әсәр. Ситуациядән үстерелеп киткән хис һәм фикер булырга тиеш», – ди шагыйрә.

Димәк, гашыйк булдың – яздың, югалту кичердең – яздың гына түгел. Артык хискә бирелеп, дөньяны онытып йөрү дә бик үк дөрес хәл түгелдер. Гәрчә Рифә апа үзен шундый ди.

Тагын шундый гадәт тә бар: берәр шагыйрьнең иҗат җимешен укыгач, анда язылганның барысын да турыдан-туры диярлек шагыйрьнең үзенә күчерәләр. Имеш, барысы да аның белән булган. Шигырь бит уйлап чыгарып, «ситуацияне үстереп» язылган булырга да мөмкин.

«Күргәнне генә язып утырырга ярамый. Миңа физик, математик ачышлар кызыклы. Көн саен шундый яңалыклар карыйм: Марста нәрсә булган, самолет төзелешендә нинди яңалыклар бар. Бу ачышларны шигырьгә кертеп җибәрәсе килә, әмма ул укучыга кызыклы түгел», – дип сөйләде язучы апа.

«Гашыйк булдың – яздың дигәннән, мәхәббәт темасын да «әйләнеп чыктык». Мәхәббәт темасына шигырь язгач, язучыдан: «Гашыйк булдыңмы әллә», – дип сорыйлар икән. Рифә апа гашыйк булуын беркемгә сиздермәү яклы.

– Шагыйрьләр гашыйк булгач яза. Ә сорашсаң, «фантазия җимеше» диләр. Берсе дә әйтми кемгә багышлаганын... Мәхәббәт шигырьләренә килгәндә, мин Һади Такташның аерылышкан хатынына булган мәхәббәтенә ышанам. Аны укыганда елыйм. Ул аны гомер буе онытмый. Хәсән Туфанныкы күпмедер ышандыра. Муса Җәлилнекенә ышанмыйм. Башкаларныкы тәэсир итми. Тукай фәләнне яраткан, төгәнне яраткан, дигәнгә ышанмыйм. Уйдырма! Һәр шагыйрьнең иҗатында йөзләгән кешегә багышланган шигыре бар. Ул аларның барысына да гашыйк булган дигән сүз түгел...

Рифә апа Рүзәл Мөхәммәтшинга зур өметләр баглый, проза өлкәсендә исә Рөстәм Галиуллинны аерып әйтә.

– Рүзәл шигырьләрне дә гаҗәеп матур итеп укый. Ул начар шигырь укыса да, залда утырган кеше тоймаячак. Гомумән, талантлы кеше матур укый. Элек тә шулай булган. Мөдәррис абый матур укый иде, Роберт Әхмәтҗанов, Газинур Морат шәп укый, Ркаилны әйтә торасы да юк. Талант ул бер генә өлкәдә була алмый. Талант бар икән, бөтен өлкәдә бар. Кайсыдыр өлкәсе басылып калган булырга мөмкин. Кеше шигырьне яхшы яза икән, ул, һичшиксез, яхшы рәссам була ала. Рәсем ясый алмыйм, шигырь генә яза алам, дип әйтә икән, аның шагыйрьлеге миндә шик тудыра, театр артисты була алмый икән – шулай ук ышанмыйм.

Рифә апа җырлауны үзендә басылып калган талант дип саный, бөтен нәселе җырлый икән. Иҗат юнәлеше килеп чыкмаса, физика-математика өлкәсенә китәргә уйлаган булган. «Шагыйрь физика, математиканы белми икән, ул – бик йомшак шагыйрь», – дип тәкърарлый ул.

– Шигырь язу ни өчен җиңел түгел? Чөнки татарда рифма табуы бик авыр. Тукайлар чорында шигырь язу җиңелрәк булган, чөнки анда фарсы изафәләре кулланылган. Ирекле формалар шулай ук бик кирәк, чөнки фикер киңлеге бирелә. Шулай да йөгерек рифма булырга тиеш. Бүгенге халыкның гарәп сүзләрен аңламавы, фарсы изафәләрен кулланмавы шигырьне рифма һәм образлылык ягыннан бик ярлыландырды.

Әдәбиятның киләчәге өчен борчылу бар. Яшьтәрләрме бездән соң? Яңа Рөстәм Галиуллин, яңа Рүзәлләр булырмы, дигән уй белән борчылып яшим. Элеккеге халык әдәбияты камилләшеп, чарланып беткән иде. Хәзер теләсә кайсы халык җырында җитешсезлек бар, рифмалы сүзләрне икенчесенә алмаштыралар. Халык шулай бозып җырлый башлый, – ди шагыйрә.

Аның фикеренчә, «Үзгәреш җиле» кебек бәйгеләр текстларга, көйгә зур зыян салган. Нәтиҗәдә, иң камил җырлар камилсезлек дәрәҗәсенә төшкән.

Рифә апага халык гел шигырьләр җибәреп тора икән. Үзе: «Ничек миңа шул шигырьләрне җибәрергә кирәк?!» – дип гаҗәпләнә. Галимә кабул итә алмаса да, халык арасында үз укучысын таба ул шигырьләр.

– Үзенең начар язганын да аңламаган кешегә аптырыйм. Халыкның начар әйберне кабул итүе нәрсәдән килә? Әдәбият бик үсте, төрләнде, әмма яхшы итеп укытырлык, аңлатырлык, үзе дә яза алган укытучылар юк. Укытырга сәгатьләр юк, яхшыны укымагач, аны яманнан ничек аерсыннар? Программа авыр, дип, ата-ана җиңеләйттерде. «Әпипә»не генә укып үскән бала шуны гына ярата, катлаулы әсәрне укымый.

Ата-анага билге кирәк. Нигә руска баласының тирән белемле булуы мөһим дә, ә татарга кирәк түгел? Бу – мине гаҗәпләндерә... Ә менә инглиз теле кирәк татар ата-анага. Аны катлаулы итеп бирүне сорыйлар, ә татар телен җиңеләйтергә телиләр.

Игътибар итсәгез, читтә яшәүчеләр татарча сөйләшми, әмма җырлый. Бөтен кеше җырлый башлый, шоуларга игътибар арта. Халык шуны гына ярата башлый икән, милләт бетә. Шоу да кирәк, әмма ул бүгенге көндәге кебек төп чир булырга тиеш түгел. Театр янында, су буенда, күпер төбендә бию – хәзер шул нәрсә китте. Мин бу күренешкә каршы, дия алмыйм, әмма аның алгы планга чыгуы, әдәбият турында мәгънәле сөйләшүләрнең кимүе кызганыч.

Бу күренеш кайчан башланды? Элегрәк концертлар барышында җырның сүз авторын һәм көй авторын әйтәләр иде. Иң элек шагыйрь төшеп калды, хәзер композиторын да әйтмиләр. Җырчы өчен ул да мөһим түгел. Сикереп йөрүче җырчы гына мөһим булып калды. Җырны дөньяга китергән кеше югала. Әкрен генә культурасызлыкка барабыз. Җырчы уйлый башлый: карале, текстын үзем язып карыйм әле. Аннан: көен язып карыйм. Тыңлыйлар. Ул үзен «шагыйрь, җырчы, композитор» дип белдерә башлый. Югыйсә һәр эшнең үз остасы булырга тиеш, – ди Рифә апа.

– Яңа шигырьләрнең «шундый гына дәрәҗәдә» булуы нидән килә соң?

– Яшьләрнең тормышы бертөсле, – диде ул. – Ике егет булган, бер кыз өчен талашкан, берсе үлә... Шул бер сюжет йөри. Әти-әниегездән сорап языгыз әле, дим, шәп әйбер язып киләләр! Чөнки аларның тормышы бай. Эротик түгел, порнографик әсәр язучылар күбәеп китте. Алар аны «эротика» дип саный, әмма эротика порнографиядән бик ерак тора. Билгеләмә биреп аеруы авыр. Шигырь җенси якынлыкны турыдан-туры акт буларак күз алдына китертә икән, ул инде – порнография. Бу чирне әдәбиятка уздырырга ярамый.

Яшьләр «интим» дигән сүзне аңламый. Интимны эротика дип уйлыйлар. Интим ул – нечкә күңел кичерешләре, шәхси, дигәнне аңлата. Әнигә язган шигырь дә интим булырга мөмкин, – ди Р.Рахман.

«Без 40 яшьтә дә Язучылар берлеге бинасына керергә курка идек. Хәзер 20 яшендә берлеккә килә. Иң беренче килүгә – бүләк, премия сорый. Бу – тиешеннән артык мактау нәтиҗәсе. Бик каты тәнкыйть итү дә, мактау да кешене үсештән туктата», – ди ул.

Яшь язучылар өчен бәйгедә билгеләр ни дәрәҗәдә гадел куелуы турында сөйләштек. Ул, нигездә, «Илһам» яшь язучылар бәйгесенә таянып бәяли. Рифә апа үзе дә – жюри әгъзасы.

– Бәйгедә билгене дөрес кую өчен авторга сорау бирәсең, аны залда утыручылар да, катнашучылар да дөрес аңламый. «Ул миңа каныкты, бәйләнде», – дип сөйләп йөриләр. Бөтен балага хас әйбер. Сорау биргән өчен бик күп шикаять килә. Сорау биргәнгә сөенергә кирәк, димәк, әсәр кызыклы, димәк, ул бала белән сөйләшәсе килә.

Ә иң ышанмаган әйберем – мәктәп олимпиадалары. Безнең бер күршенең малаена мәктәптә физикадан гел «4»ле чыгаралар иде. Олимпиадага барып, Россия буенча беренче урын алды, укытучы шуннан соң гына «5»ле чыгарды. Гаделсезлек укытучыдан башлана. Бала бәйгедә җиңү-җиңмәүгә дә түзә, ә гадел булмаган билгегә чыдавы авыр. Бәйгенең гаделсез булуына 100 процент укытучылар гаепле, чөнки әсәрләрне алар язып бирә. Беренче сайлап алуда «иң яхшысы» дип табылган эшләрнең авторлары соңыннан гап-гади сорауга да җавап бирә алмый. Кем аларны ялганларга өйрәтә? Укытучы.

Намуссыз рәвештә билге кую бөтен җирдә бар. Олыларны алдыйлар да алдыйлар инде. Олылар арасында уздырылган бер бәйгегә дә ышанмыйм. Үзем җиңгәннәремә дә ышанмыйм, – ди Рифә апа.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА.
intertat.tatar

ШӘҺӘР УРАМЫНДА ПЕЧӘН ИСЕ...

Кояш уянганчы авыл торган,
Олы-кече иртүк басуда.
Печән өсте кызу эш көне дә...
Куанычлы көн бит асылда.

Күрше белән күрше сүз алыша:
“Куе печән быел, шәп, уңган!”.
Сөенә-сөенә халык печән җыя,
Сәнәк-тырма төшерми кулдан.

Көн кызуы бераз тына төшкән,
Җилләп тора, ахры, яңгырга...
Борыннарны чеметеп хуш ис килә,
Яңа печән кайткан ындырга.

Чаба-чаба халык печән ташый,
Ут капкандай кызу эш өсте...
Минем хәтер шул көннәргә кайтты,
Вакыт бер тын тукталган төсле.

Туктап, басып печән исен исним,
Аһ, шәп исе, нәрсә дисәң дә!

ЙӨРӘГЕМДӘ СЫЗЛАУ БУЛЫП ТОРА...

2021 елның 11 маенда Казанның 175 нче мәктәбендә вәхши кулыннан һәлак булган балалар рухына

Май аеның матур көне иде,
Бар табигать ап-ак чәчәктә...
Җан кыючы вәхши үтеп керде,
Мылтык тотып тыныч мәктәпкә.

Кара рухлы явыз тарафыннан
Җиде сабый терәп атылды.
Җан кителде минем, җан әрнеде,
Биләп алды хәсрәт акылны.

Сабый күз яшедәй таң атканда,
Чәчәк чукларына чык элгән...
Ул хәвефле төнне күз йоммыйча,
Таң аттырган идек уй белән.

Өзелә-өзелә җаннар алҗыганда,
Авыр хәбәр илләр иңләде.

Фирдәүсә БИКМӘТОВА

Хатын йөри лап-лап атлап,
Палас таптап, кояш каплап.
Уйлап ятам, карап ятам,
Миллионнарны санап ятам...
Харам хакны бүлә белсәм,
Ришвәтләрне бирә белсәм,
Хөкем йомшак, хөкем ярый.
Котылырмын мин, пожалый.

ПЕРСОНАЛЬ ШАЙТАН

(Шаяру)

Тату чакта сыпырып торам,
Җай туганда – үбеп кенә.
“Синнән башка чын сөю юк,
Бел, кадерлем”, – диеп кенә.

Ни әйтсәм дә уңай әле,
Көлә ирем гөрелдәтеп.
Мин дә кеткелдим кушылып,
Иңсәләрне дерелдәтеп.

Мин авылны ташлап киттем күптән, Авыл китми миннән һаман да...

Күңел күге яшел канат куя,
Дөнья баскан чандыр иңсәмә.

Шәһәр урамында печән исе,
Печән исе талгын һавада.
Мин авылны ташлап киттем күптән,
Авыл китми миннән һаман да.

ҖӘЙ

Һәр арышка яшел таҗ кидергән.
Табигатьнең гүзәл бер чоры.
Талгын җилгә сылу билен бөгеп,
Көйли арыш иминлек җырын.

Басу юлын чыгып, иңкүлектә
Җиләк җыеп каптым бер учлап.
Борчак басуында кузак җиткән,
Авыз итеп чыктым берочтан.

Өйләгәчә кызу, кич авышкач,
Яңгыр яуды кинәт, ишелеп.
Колачымны җәеп басып тордым,
Ачкан төсле бәхет ишеген.

Салмак җилдә аккан ак болытлар
Кояш баешында алланды.
Юеш күлмәк кибәр әле өстә,
Көйләп туймас җырдай калганы.

Нинди матур чор бит, кара әле,
Кабатланмас гүзәл чак тора.
Кызудан соң яңгыры да тансык,
Мондый көннәр өмет арттыра.

ШИГЫРЬ ЯЗАМ

Хис һәм акыл көче кушылганда,
Шигырь туа минем күңелдә.
Җырым калсын кәгазь битендә, дип
Каләм алдым кулга бүген дә.

Тирә-юньдә бөтен нәрсә җанлы,
Йолдызлар да, җил дә, чишмә дә.
Алар җырын ничек эчтә саклыйм?
Шигырь язам, ямьле кичләрдә.

Күңел сызласа да, җырласа да,
Йөрәк еласа да тын гына,
Йөрәгемә салып куйган хисне,
Шигырь итәм үреп моңыма.

Хурлыйммы мин, зурлыйммы мин аны?
Катлаулымы тормыш, җиңелме?
Шигырь язам, миннән соң буынга
Җырым калсын, җиңеп үлемне.

Уңга-сулга сугылып сабый җаннар,
Җәннәткәме юллар эзләде?

Елдан артык гомер үтеп киткән...
Әллә җанны кинәт моң баса.
Тетрәндергеч көннең кайтавазы
Шул мәктәпкә барып тоташа.

Узып барам мәктәп тирәсеннән,
Кемдер үкси, ярсый – ишетәм...
Зур аюын кочып егет елый,
Оялып торыр чакмы кешедән?

Мәктәп коймасына терәлгән дә,
Башын учларына төшергән...
Берәрсенең туган көне микән?
Истәлекле көнме... кем белгән...

Кургаш-кургаш уйлар әле һаман,
Сулгып-сулгып ярам канап тора.
Әйтерсең лә күзъяшькә буылып,
Шул сабыйлар күзгә карап тора.

* * *

Сүз – күңелнең күлмәге.

Дөньяда кодрәтле көч бар,
Ул да булса – сүз көче.
Сүз җәза да, сүз дәва да,
Сүз белән асыл кеше.

Сүз – уй-фикер калыбы,
Эчке дөнья күлмәге.
Сүз алышу зур нигъмәт ул,
Сүз – Ходайның бүләге.

Кайда аклый, кайда яклый,
Битараф була кайда.
Саксыз кагылса зыян күп,
Сөеп тисә – зур файда!

Сүз кешене даһи итә,
Күтәреп чөя күккә!
Газиз итә чайкаганда
Пычракта, тетә-тетә.

Ул байрак биреп кулларга,
Сафны яуга күтәрә.
Аңны яулый, тәнне саулый,
Җанны сатып җибәрә.

Сүзе белән кеше үзе
Богау сала кулына.
Сүзен сөзеп сөйләмәгән
Йөз абына юлында.

Усал сүздән, яман сүздән
Тормыш тәме китәдер.
Хыял канатын сүз киссә,
Бәхетеңә киртәдер.

Кошны – орлык, кешеләрне
Сүз төшерә тозакка.
Авыздан чыккан сүз – кош ул,
Бикләп тотыйк йозакка.

Заманалар үзгәргәндә,
Сүзгә нинди төс керми.
Үтемле сүз мәңге телдә,
Гыйбрәтле сүз искерми.

ЙӨРӘКЛӘР ҮРЕЛГӘН

Шалтырау сыкратты дөньямны.
Онытып бетердем дигәндә,
Кабындың җемелдәп еракта,
Син юкка күңегеп килгәндә.
Исемә төшердең үзеңне,
Уела башлагач күңелдән.
Җилкенгән йөрәкне юмалыйм,
Син түгел мин белгән, мин сөйгән.
Уйларым йөгердә таралып,
Эзләрең җанымда бик тирән.
Бер суга кералмам яңадан,
Сөюем сүрелгән, сүрелгән.
Ашкынган хисләрне йөгәнлим.
Тормышлар ялгышка күмелгән.
Кайтаваз башымда яңара,
Йөрәкләр үрелгән, үрелгән.

КОТЫЛЫРМЫН...

(Памфлет)

Киң кабинет, имән өстәл,
Куш канәфер, кәчтүм өстә.
Вак-вак атлап сәркәтиб кыз,
Йөреп тора алда тыз-быз.
Әледән-әле кызны кочып,
Утырам түрдә коньяк эчеп.
Имза – уңга, имза – сулга,
Кереп торса банкнот кулга.
Караклыкның чиге нәзек,
Кидерделәр кулга беләзек.
Өстә халат, кәчтүм чөйдә,
Ашыгып ни бар, арест өйдә.
Әвеш-тәвеш диван таптап,
Төкереп ятам күккә карап.

Телләре дә көйләп куйган,
Назлап, сөеп эндәшергә.
Күгәрченнәрдән уздырып,
Гөлдер-гөлдер гөрләшергә.

Ну, кой китсә алай-болай,
Аждаһадай ут чәчәм мин
Телне чарлап куйганмыни?
Сүзләр белән чәнчешәм мин.

Эт-мәчеле булган чакта,
Беркемне дә сөйми җаным.
Араларны бутап йөри,
Ахры, персональ шайтаным.

“Сөясеңме? Сөям инде!”.
“Сөйгәнеңне беләм инде”.
“Синнән башка тора алмыйм,
Мин дә сине сөям инде”.

Тора-бара җайланабыз,
Уй-фикерне уртаклашып,
Элемтәне яңартабыз,
Яшь парлардай кочаклашып.

Караттыра, яраттыра,
Юк бер кеше ирем төсле.
Үзе шаян, үзе булган,
Киң күңелле, көләч йөзле.

Кайгыларны, шатлыкларны,
Кичерәбез бергә-бергә.
Шулай җиңел, шулай уңай,
Тормыш йөген күтәрергә.

Бик дус әле, булмаганда
Бутап йөрүче араны.
Ничек куып җибәрергә
Теге персональ шайтанны?

ЯРАТЫРМЫН

Уйнап-көлеп кенә гомер кичермәдем,
Сөюдән дә булды берчак исергәнем.
Йөргән чакта күзләремнән сөю чәчеп,
Син башканы якын иттең, үчекләшеп.
Хисләремне күрсәтергә кыймый йөрдем.
Мин сөйгәнне, сантый, тоймый йөрдең.
Сукыр идең, ир-егетне, әйдә, аклап була,
Сөюне бит бергә генә саклап була.
Син сөймәсәң, мин дә сөймим, дидем.
Хисләремне төен итеп төйним, дидем.
Сөю килсә, ефәк итеп таратырмын,
Яратканны ялындырмам, яратырмын.

Фотосурәтләрдә –

Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Рәссам-графиклар берлеге, Россиянең Журналистлар берлеге, Журналистларның халыкара конфедерациясе, Россия Фоторәссамнары берлегенең шәрәфле әгъзасы ул Фәрит Гобәев. Иҗатчы май аенда үзенең саллы хезмәте, ике йөздән артык фото тупланган «Искусство присутствия» исемле иң беренче фотоальбомы белән куандырды. Август-сентябрь айларында «Хәзинә» милли сәнгать галереясында аның шәхси күргәзмәсе дә узды. Анда йөздән артык фото экспозицияләнде.

Үз фотоальбомын талант иясе кадерле әнисе Бибинурга һәм кызы Дарияга багышлаган. Анда останың соңгы илле ел эчендәге, 1972 елдан алып 2022 елга кадәр төшергән, фотохезмәтләре тупланган.

Фәрит Сәит улының исеме республика фотосәнгате белән тыгыз бәйле. Аны күп кенә чит илләрдә дә яхшы беләләр. Фәрит aклы-каралы фотоларга өстенлек бирә. Менә бу альбомда да вакыйгалы фоторепортаж кадрлары, портретлар, фотонатюрмортлар, шәһәр пейзажлары... һәммәсе дә монохром. Арада моңа кадәр нәшер ителгән күпсанлы китапларга, альбомнарга кергәннәре дә җитәрлек. Әйтик, 2015 елгы фотодагы ветеранга сурәткә төшкән көнне 100 яшь тулган, аның күзләрендә бер гасырлык ил тарихы чагыла төсле... 2015 елда Ф.Гобәев «Җиңүнең 70 портреты» фотопроектында 3 ай эчендә 45 районга барып, йөздән артык сугыш ветеранын һәм тыл хезмәткәрләрен сурәтләргә җитешкән иде. Аннары ул бу серияне дәвам итеп, Җиңүнең 75 еллыгына багышлап нәшер ителгән фотоальбомга 150 ветеран сурәтен урнаштырды.

«Фотолар белән танышуым 60 ел элек башланды, – дип язган ул альбомындагы кереш сүзгә. – Кечкенәдән үк рәсемнәр, сынлы сәнгать, фотолар белән кызыксындым. Беренче сыйныфта укыганда, бик йөдәткәч, әнием миңа «Смена» сатып алды. Ул чор өчен бу бик кыйммәт бүләк иде. Шул көнне минем язмышым хәл ителгәндер. Хәтердә: беренче фотоларымны төшерергә күршебезнең, фото сөюче ир-атның, ничек эшләвен күреп өйрәндем. Мәктәптәге стена газеталарын фотолар кушып бизи башладым. Фототүгәрәккә йөрдем һәм бу шөгыльемне көннән-көн күбрәк ошата төшкәч, әниемне «Зоркий» фотоаппаратын алырга күндердем. X нчы сыйныфта укыганда «Волга» фотоклубын эзләп таптым. Андагы коллегаларым белән гәпләшүләр үзе бер мәктәп булды. Тормышымны иҗат белән бәйләү өчен, 1971-1976 елларда Казан дәүләт университетының журналистика бүлегендә читтән торып укыдым. Эш урыннарым да редакцияләр белән бәйле булды, җирле телевидениедә телеоператорлар төркемендә дә эшләп алдым. КПСС сафына керүдән баш тарткач, Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда хезмәт куйдым. Бу чорда рәссамнар белән дә аралаштым... 1991 елда Мәскәүгә, яңа гына оешкан «Россия» газетасына эшкә чакырылдым. Мәскәүдәге эшчәнлегемдә «Обозреватель» журналының бильдредактор вазыйфаларында да, Россия Журналистлары берлегенең «Фотоүзәк» берләшмәсендә фотокүргәзмәләр бүлеге җитәкчесе вазыйфаларында да булырга туры килде. Фотосурәтләремне Казан, Мәскәү, Ленинград, Вильнюс, Рига, Таллин, Париж, Амстердам, Вашингтон, Нью-Йорк, Кобург, Кельн тамашачылары да күрде. 2001 елда «Интерпресс-фото» Халыкара жюри эшчәнлегендә дә катнаштым һ.б.

Үзебездә дә, чит дәүләтләрдә дә: «Синең шәхси фотоальбомың бармы?» – дип еш сорыйлар иде. Чөнки күбесе бит унар фотоальбом нәшер итә. Ниһаять, мин дә эшләремне тупларга керештем. Моның өчен ике ел вакыт таләп ителде һәм бу альбомның макетын Мәскәүдә дә күрсәттем, абруйлы кураторларның, танылган сәнгать белгечләренең дә фикер-бәяләмәләрен тыңладым».

Фәрит Гобәевка күп тарихи вакыйгаларны да фотосурәтләргә алырга насыйп булган. Тик аның хезмәтләрендә сәясәт лидерлары гына түгел, аларда халкыбыз вәкилләре дә, шул ук вакытта мәшһүр иҗатчылар да байтак. Әйтик, Б.Урманче, Х.Якупов, С.Гобәйдуллина, Р.Нуриев, Д.Вишнева, А.Тарковский, И.Зарипов һ.б. Фотограф, Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы буларак, бүгенге көннәрдә һөнәри рәссамнарны фотога төшерә. Бу серия дә соңрак аерым күргәзмә итеп күрсәтеләчәк.

Ул Франция, Голландия, Германия, Швейцария, Австрия, Польша, Канада кебек дәүләтләргә дә барып, анда да фотога төшерү белән мәшгуль булган.

«Гомерем буе үземнең яраткан һөнәремдә. Узган гасыр уртасында без, фотографлар, француз фотографы Анри Картье-Брессон сәнгатенә, аның эш рәвешенә тартылдык, ул безнең өчен чын үрнәк иде. Миңа уңыш елмайды: 1995 елда Парижда чакта аны Magnum күргәзмәсендә очраттым. Билгеле, ул үз дуслары белән иде. Шушы агентлыкта эшләгән фотограф Г.Пинхасов: «Биредә зур шәхес янына болай гына килеп сөйләшеп китү кабул ителмәгән», – диде. Шуңа да карамастан мин, инглиз телен начар белсәм дә, танылган шәхес янына ук килдем һәм Казан, аның фотографлары хакында, аларның аны яратуы хакында сөйли башладым, үзен фотога төшерергә рөхсәт итүен дә үтендем. Ул бераз уйланып торды да риза булды. Иҗат багажымда аның портретлары булу белән чиксез горурланам. Ул бит XX гасырның реалистик фотографиясе остасы, фотожурналистикасы атасы, 1947 елда коллегалары белән «Magnum Photos» агентлыгын оештырган, 1954 елда, Сталин үлгәч, Советлар Союзына беренче булып килгән чит ил фотографы. 1966 елда агентлыктан китеп, Прованс таулары янында яши башлаган, Альп табигатен ясау белән шөгыльләнгән, 1908 елда туып, 2004 елда – 95 яшендә генә дөнья куйды», – дип искә ала Фәрит Сәит улы. Аннан узган гасырда дөньякүләм мәшһүр балет артисты, хореограф Рудольф Нуриевны 1992 елда ничек фотога төшерүе хакында да сорашам. «Бу Р.Нуриевның соңгы язы иде, – диде Фәрит. – Ул Казанга дирижёр буларак килде бит. Тамаша тәмалангач, Рудольф Хәмит улы бик арган килеш утырып тора иде. Мин аны, аның белән гәпләшмичә, бер сүз дә сөйләшмичә генә фотога төшердем. Фотога төшерергә рөхсәт иткәннәре өчен рәхмәт!»

«Шәхси күргәзмәләрем – чын

ил тарихы



бәйрәм. Бу чаралар аша тамашачыларым белән якыннан аралашам, аларның бәяләмәсен тыңлыйм. Үз гомеремдә утыздан артык шәхси күргәзмәмне ачтым, күмәк экспозицияләрдә дә катнаштым, китаплар нәшер итүгә үз өлешемне керттем, күп күргәзмәләрнең кураторы булдым, осталык дәресләре үткәрдем... Ләкин барыбер дә тамашачыларымны фотоархивым белән тулырак таныштырырга өлгермим әле. Миңа – 71 яшь. Әмма мин бүген дә ерак юлга кузгалырга әзер, бу дөнья минем өчен гаять кызык, бер урында гына утырып тора алмыйм, холкымның нәкъ шундый булуы кемнәрнеңдер ачуын да чыгара торгандыр... Яшем үзен сиздерә шул, авырып яки арып китүләр миңа да хас. Әмма шушы күргәзмәләрем үтү, фотоальбомнарым дөнья күрү, аларның яңалары өчен цифрлаштырылган фотоәсәрләремне папкаларга туплап утыру да мине шатландыра!» – ди сәләт иясе бүгенге көннәре хакында.

Әйе, Фәрит Гобәев фотога төшергәндә хәлиткеч мизгелләрне тотып алып кына калмыйча, аларны нәфис эстетика кануннары буенча сайлап та алырлык дәрәҗәдә иҗат иткән һәм хәзер дә шундый югарылыкта. Моның өчен кешегә феноменаль сиземлелек тә хас булырга тиеш һәм фотографтан кадр эчендәге мохит геометриясен яхшы белүе таләп ителә. «Янәшәдә булу сәнгате» күргәзмәсе ачылу тантанасындагы чыгышларында Фәритнең башка фотоальбомнарын да көтеп калачаклары хакында да ассызыкладылар.

Күргәзмәне Казан башлыгы Илсур Метшин да карады. «Сезнең фотоларны беренче тапкыр 1983 елда күргән идем, шуннан бирле иҗатыгызга мөкиббәнмен», – дигән ул Фәриткә. Ул София Гобәйдуллина фотосын да бик ошаткан һәм мәшһүр композиторыбызның сурәтләре яңартылган П.И.Чайковский исемендәге 1 нче музыка мәктәбе диварларын да бизи алуын искәрткән. София Әсгать кызы шул мәктәптә белем дә алган бит. «Бернинди видео да картина тирәнлеген күрсәтеп бирә алмый. Күргәзмә искиткеч матур килеп чыккан! Эшләр Казан, республика, ил тарихын чагылдыра», – дип ассызыклаган җитәкче.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Тарихка бәя үзгәреп тора

Россиядә Икенче бөтендөнья сугышы тәмамланган көн 2020 елга кадәр 2 сентябрь дип билгеләп үтелде. 2020 елның апрелендә, Владимир Путин карары белән, дата 3 сентябрьгә күчерелде. Тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев бу дата һәм Икенче бөтендөнья сугышының нәтиҗәләре хакында фикерләре белән уртаклашты.

Датаны үзгәртү ул – бары тик формаль нәрсә генә. Аны үзгәртүдән бернәрсә тормый. Бу вакыйга булган, сугыш тәмамланган – иң әһәмиятлесе шул, бер-ике көн аерма... Тәгәл дата тарихка гына кирәк, ә гади кеше өчен, тарихны бәяләгәндә, ул датаның бер-ике көнгә күчүе бернинди әһәмияткә ия түгел. Бу – бер.

Сугышның әһәмиятенә килгәндә, ул «дөнья сугышы» дип юкка гына аталмаган. Ул бөтен дөньяны кузгаткан, бөтен дөньяны челпәрәмә китергән. Бигрәк тә Европа, Азия илләрен һәм Американы колачлаган сугыш. Нәкъ әнә шуннан соң, чын мәгънәдә система барлыкка килеп, алар бер-берсенә каршы тора башлый. Бер яктан Советлар Союзы җитәкләгән социализм системасы, икенче яктан Америка Кушма Штатлары җитәкләгән капитализм. «Кайнар сугыш»тан соң озак та үтми «салкын сугыш» башлана – сәяси, хәрби, икътисади, идеологик каршы тору. Болар бөтенесе дә – Икенче бөтендөнья сугышы нәтиҗәсе: бер яктан НАТО системасы, икенче яктан Варшава килешүе килеп чыга. Һәм ул проблема берничә буынга җитә. Дөньяда тынычсызлык ахыр чиктә «Кариб кризисы» дигән нәрсәгә дә китерә – Америкага каршы торуның иң югары ноктасы, турыдан-туры атом бомбасы куллану ихтималы барлыкка килә.

Беренче бөтендөнья сугышы 4 империя бетүенә китерде: Австро-Венгрия, Госманлы империясе, Россия империясе, Германия империясе.

Ә Икенче бөтендөнья сугышы, бөтен дөньяны әйләндереп, ике системаның бер-берсенә каршы торуына китерә. Минемчә, иң әһәмиятлесе шул.

Әлбәттә, корбаннар саны коточкыч инде, анысын берничек тә үлчәрлек, санарлык түгел.

«Әгәр сугыш булмаса, Россия халкы шулкадәр булыр иде...»

Андый фаразларны ясамыйк. Тарихта моңа охшаш фаразлар ясау бер дә дөрес түгел. Әгәр дә шулай булган булса, без 350 млн га җитәр идек, әгәр Горбачев булмаса, Советлар Союзы тагын да яшәр иде һәм тагын әллә нәрсәләр – урынсыз.

Тарихны ничек бәяләргә кирәк? Тарихтагы бу хәлгә без хәзер нинди бәя бирәбез, дип фикер йөртү зарур. Сугыш булган, без ул сугышка аек акыл белән үзебез өчен гамәли нәтиҗәләр ясап, аны бәяләргә тиешбез. Ә нииндидер фаразлар кылу ул тарихчы эше түгел.

Сугышка бәя үзгәрү

Бәя үзгәрү – ул сугыш нәтиҗәсе түгел, ә кешенең үзгәрүе нәтиҗәсе. Һәрбер җәмгыять тарихны үзгәртә, һәрбер шәхес тарихны үзенчә аңлата. Конкрет тарихи вакыйгалар бар, аларны без берничек тә үзгәртә алмыйбыз. Без аларга бәяне генә үзгәртә алабыз. Һәм бәя үзгәрә! Үзгәрәчәк тә. Бәя ул – субъектив нәрсә, объектив түгел. Тарих ул – объектив, булган хәл, ә бәя бирү инде ул кешедән тора, кешенең субъективлыгыннан, карашыннан, идеологиясеннән тора, монысы ошыймы, тегесе ошамыймы – шуннан тора.

Күпме вакыттан соң Икенче бөтендөнья сугышы сәяси төсмерләргә кертелүдән туктар?

Беркайчан да туктамый. Наполеон сугышына да төсмерләр бирү туктамады, чөнки Наполеон сугышын французлар бер төрле бәяли, ә без – башкача. Ул бәя һәрвакытта да үзгәреп торачак.

Бәлки, 50 елданмы, 100 елданмы аның актуальлеге югалыр, чөнки башка вакыйгалар булачак. Ләкин бәя барыбер үзгәрәчәк, чөнки кеше тарихны бәяләгәндә беркайчан да субъективлыктан арына алмый, бу – аксиома. Тарихны һәрвакытта да файдаланганнар һәм файдаланачаклар. Тарихны сәясәттә һәрвакытта да инструмент иткәннәр һәм ул гомер буе шулай булачак. Һәрбер ил тарихны үзенчә аңлатачак.

intertat.tatar

Хисаметдин ИСМӘГЫЙЛЕВ

Хуш, кызым...

(«Зимагурлар» повестеннан өзек)

Нурзияне гомум палатадан реанимация палатасына кертеп салдылар.

Үткән ел аңарда яман шеш авыруы таптылар. Хәзер менә ничәнче мәртәбә дәвалана. Ике тапкыр операция дә ясап карадылар, ничә тапкыр химия алды. Ул “инде терелеп булмас, ахрысы” дип, күңел төшенкелегенә бирелеп, уйланып ята иде. Кызын, Зәлифәсен генә аякка бастыра алмады. Унҗиде яшьлек кыз ялгыз кала инде. Үги әтисе бөтенләй бозылды. Ничә тапкыр хастаханәгә кереп ятты, ичмаса, бер килеп хәл белсә. Ярый әле, кызы бар. Ул шәфкать туташлары әзерли торган, хәзергечә әйтсәк, көллияттә икенче курста укый. Кемнәр кулына гына калыр икән? Ничек укып бетерер икән дә, нинди генә кияүгә тап булыр?

Үзенең хәле көннән-көн начарая шул, бер дә алга таба түгел. Барча гәүдәсе кипте. Чыкмаган җаны һәм уйланып бетмәгән уйлары гына калды. “Их, кызым, кызым Зәлифәм. Юньле кешеләрнең генә улына кияүгә чыгып, исән-сау балалар үстереп, тормыш итеп китә алсаң ярар иде дә бит”, – дип уфтанды ул. Бар уе шул турыда булып, гел кызын исенә төшереп ятты. Әллә нишләп соңгы көннәрдә шулай уйлады, зарыгып кызын көтте. Кызыма бер-бер киңәш, үгет-нәсихәт бирермен дип өметләнде.

Әллә сизенеп, әллә Ходай эшкәртүе булды, шушы көнне Зәлифә әнисе янына килде.

Килеп керү белән, әнисенең сөяк тә тире генә калган тәннәрен йомшак юеш чүпрәк белән сөртеп алды. Әнисе канәгать калып, зәгыйфь кенә елмаеп, риза булып ятты. Менә хәзер әйтәм, менә хәзер әйтәм кызыма кирәкле сүзләрне дип, нәрсәдер көтте. Кызының шулай аны иркәләгәнен бүлдерәсе итмәде. Үз балам үз балам инде. Нинди йомшак итеп тотына бит, теге килбәтсез шәфкать туташы кебек кыланмый, дип уйлады. Мөгаен, терелермен дә әле, Ходай насыйп итсә, дип, хыялларга да бирелеп алды. Әйтәсе сүзләре турында уйлап, әйтсәм, кызыма кыен булмасмы икән, дип тә икеләнде. Шулай да, җайлап кына сүз башлап:

– Кызым, ничек кенә кыен булса да мин терелеп чыкканчы, өйдә кунма. Тулай торакка күч. Директорыгыз Әхмәт абыеңа кер. Ул бик кешелекле кеше, хәлеңә керер. Берәр бүлмәдә урын да табып бирер мотлак. Үги әти үги инде ул, кызым. Үз әтиең хәбәрсез югалды. Шул БАМга барам дип әллә нигә ашкынды. Күрәсең, маңгаена язылган язмыш-әҗәле тарткандыр. Үги әтиеңнең юне чамалы. Сак бул. Киемгә ябышкан сырганак кебек сарылды шул. Әллә ни үзем дә йомшаклык күрсәттем, – дип, барча шик-үкенүләрен кызына белдерде. Зәлифә, әнисенең үзе өчен борчылуына хафаланып:

– Әнием, бәгырем, һич борчылма, барысын да син әйткәнчә эшләрмен, – дип, аны юатырга тырышты. Әнисенең бөтенләй коелып, урыны-урыны белән тырпаеп торган чәчләрен хуш исле кубекле су белән юып алды. Муен-җилкәләрен юды. Озак урында ятудан калак сөяге һәм янбашындагы тиресе уелган урыннарны әйбәтләп тазартып, табибләр биргән дарулар белән эшкәртте. Аңа әнисенең болай ук хәлсезләнеп, ярдәмсез ятуын күрү бик тә авыр иде. Күршеләре биреп җибәргән мәтрүшкә, кура җиләге яфраклары һәм юкә чәчәкләреннән ясалган чәй кайнатып, пешереп алып килгән ләвәш-бөккәннәр белән әнисен чәй эчереп сыйларга уйлаган иде дә барып чыкмады. Әнисе ләвәшнең бер читен чеметеп әллә капты, әллә юк. Ә хуш исле үлән чәен бер чынаяк тутырып, өрә-өрә мактый-мактый эчте. Хәтта ап-ак йөзенә чак кына алсулык та йөгерде. Маңгаена тир бөртекләре калкып чыкты. Һәм ул, кызына карап, елмая биреп:

– Рәхмәт инде, кызым. Чәең бик тә тәмле булды. Кичкә тагы шушы чәйне ясарга кушармын инде караучы туташларга. Ә син бар, балам, хәзер кайтып китсәң дә була. Укы, тырыш. Күрше-күләнгә, ага-туганнарга миннән сәлам әйт, – дип, кызы белән хушлаша башлады. Ә Зәлифәнең аны берүзен бу дару исе сеңеп беткән бүлмәдә калдырып чыгып китәсе килмәде, тагы чак кына әнисенең янында утырасы килде.

Нурзия бик тә хәлсез. Әле кызы белән сөйләшеп тә нык арыды. Шуңа да моңсу гына:

– Кызым, синең яныма килеп хәлемне белүең күңелемә бигрәк тә рәхәтлек, бер ямь өстәде бит. Бөтен тәнемә җиңеллек таралды. Мөгаен, укый башлаган хикәямне дә укырмын әле, сине озаткач. Нишләптер, бу арада хәлем тиз бетә, шуны укыганчы да арыйм, – дип сөйләнде.

Зәлифә әнисенең баш очындагы тумбочкадан Галимҗан Ибраһимовның китабын тартып алды. Китапның бите “Кызыл чәчәкләр” әсәренең уртасында бөкләнгән.

– Ярар, әнием, син тыныч кына ятып тор, әле автобуска чаклы ике сәгать вакыт бар. Мин укыйм, ә син тыңла, яме, әнием, – дип, әнисенең күзләренә карады. Нурзия бик тә моңсу елмаеп:

– Алайса, кызым, мин күзләремне йомып кына тыңлыйм, ә син укы, кызым, укы, – дип, күзләрен йомды. Зәлифә җай гына укый башлады.

Нурзия әүвәл кызының укыганын тыңлап ятты. Җайлап кына аны йокы баса башлады. Чөнки кызы аңа, әйтерсең лә, китап укымый, ә бишек җыры җырлап тибрәтә иде. Нурзия күзләрен әз генә сирпеп кызына карап алды, кызы шундый матур, ягымлы тавышы белән хикәяне укуын дәвам итте. “Кызым әтисенә охшаган, бәхетле булыр әле, иншалла”, – дип, тагы күзләрен йомды, үзен бишектә яткан кебек хис итте. Менә аның алдына кайдандыр пәйда булып әнисе килеп басты. Әнисен күреп, Нурзия

аптырап куйды. Яшь чагында кия торган матур бизәкле ак күлмәген киеп, елмаеп балкып тора.

– Исәнме, кызым. Менә син дә безнең янга килдең. Әйдә, бергәләп әтиең, картәтиләрең янына очып кына барыйк, – дип, кулларын сузып, үзе янына чакыра башлады. Нурзия бер китап укып утырган кызына, бер әнисенә карап, икеләнеп калды. Әнисе үтемләрәк итеп: “Әйдә, кызым, әйдә, һич курыкма. Кызың китабын укый торсын. Аның өчен һич борчылма, ул үскән бит инде. Кызыбыз бик тә яхшы кешегә очрап, тормышын шул кеше белән бәйләп, бәхетле озын гомер кичерәчәк. Ышан миңа, мин, әниең, сиңа гел дөресен әйтәм” – дигәч, Нурзиянең, ризалыгын белдереп, әнисенә кулын сузып омтылуы булды, аны ниндидер бер җылы йомшак җил җиңел генә күтәреп әнисенә таба алып та китте. Нурзиянең күңеле тәмам тынычланды. Өстән, әнисе белән очып йөргән җиреннән, кире кызы янына килде. Кызы янәшәсендә яткан, үзенең бик тә ямьсезләнеп картайган гәүдәсенә игътибар да итми: “Хуш, кызым, сау бул. Тырышып укы. Мине онытма”, – дип, кызының башыннан сыйпарга әйткән иде дә, кулы кызының чәчләренә, аннан кызы укыган китап битләренә тиеп китте.

Шушы мизгелдә Зәлифә укыган китапның битен кузгатып һәм аның чәчләрен селкетеп, җил исеп киткән кебек булды. Зәлифә сискәнеп әнисенә карап алды. Әнисе тыныч кына ята. Елмая да әле. Аның елмаюлы йөзен күреп, тынычланып, Зәлифә китап укуын дәвам итте. Ул татарча чиста укый. Саф татарча сөйләшә. Моңа әнисе бала чагыннан ук өйрәтте. Кызы телен шомартсын өчен җәйге ялларда һәрвакыт авылга кайнатасы-кайнанасы, күршедә генә гомер кичергән картәнисе янына кайтарды. Алар әнисе белән өйләрендә дә гел татарча сөйләштеләр. Ә бит Зәлифәнең күргәне бар: яшьтәшләренең татарча бер авыз сүз белмәгәннәре дә җитәрлек.

Зәлифә үзе китап укыды, үзе шушы мәлдә әнисенең:

– Хуш, кызым. Сау бул, тырышып укы. Мине онытма, – дип кычкырган тавышын әллә ишетте, әллә үзе генә шулай уйлады. Ул тагы әнисенә күтәрелеп карады. Әнисе ничек елмая, шул килеш ята, тик иреннәре генә әзрәк ачылган. Ул шулчак аның тын алмый ятканын күреп, таштай катып калды. Зиһененә барып җитми торды. Үрелеп, әнисенең яңагыннан үбеп алды. Яңаклары җып-җылы иде әле. Ниндидер сиземләү белән одеял өстендә яткан бармакларын тотасы итте. Бармаклар сап-салкын һәм саргайганнар. Тагы әнисенең битен учлары белән сыпырып алды. Әни кеше дәшмәде. Ул үлгән иде. Зәлифә көллияттә шәфкать туташы булырга укыгач, әнисенең бу авыру белән озак яши алмаячагын аңлады. Тик бу кадәр тиз һәм кинәт булыр дип башына да китермәгән иде.

– Әнием, бәгырем, – дип сыкранып, бер аһ-зар чыгарып әнисенә дәште дә күзләреннән атылып чыккан яшьләрен тыя алмый, әнисенең үле гәүдәсен кочаклап, елап җибәрде. Озак елады ул, хәтсез елады. Әнисе белән үткән бөтен тормышын энәсеннән җебенә тиклем, бәйнә-бәйнә күз алдыннан үткәрде. Бераз бушанып, әзрәк тынычлангач, палатадан чыгып, кизү торган шәфкать туташына:

– Әни үлде, – дип чак әйтә алды. Һәм тагы ихтыярсыздан елап җибәрде. Шәфкать туташлары әле тегеләй, әле болай чабыша башлады. Кайберләре килеп, бу яшь кенә кызны юаткан булды.

Нишләсен инде унҗиде яшьлек кыз бала. Кая барырга да, кемгә дәшәргә дә белми коелып төште. Уфада әнисе ягыннан туганнан туган Рәйхана апасы бар иде Зәлифәнең. Телефоннан аңа хәбәр җибәрде. Озак көттерми, ул да килеп җитте. Олы кеше олы кеше инде. Төрле-төрле киңәшләр биреп, әзрәк акча тоттырып:

– Бар, хәзер ук үги әтиеңә кайтып әйт. Берәр җаен тапсын, – диде. Үги әтиең дигәнгә ниндидер басым ясап әйтте. Чөнки Рәйхана апасы Нурзиянең ул ирне фатирына кертүенә бер дә риза түгел иде. Шуннан, дәвам итеп:

– Әниеңнең элек эшләгән урыннан, йә үзе берәр машина табып алып килсен, җирләү хәстәрен күреп куйсын. Иртәгә иртән ук монда булыгыз! Кара аны, матри, – дип кисәтеп куюны да артык күрмәде.

Зәлифә Стәрлетамакка ничек кайтып җиткәнен дә, ничек үзләренең фатирларын ачып кергәнне дә хәтерләми. Тик үги әтисенең бер чит хатын белән шапшәрә ятканнарын күреп, югалып калды. Ялгыш чит фатирга кердемме әллә, дип уйлады. Үги әтисе бу вакытта эштә булырга тиеш иде түгелме соң? Зәлифә аптырап идән-түшәмнәрне, диварларга эленеп торган келәмне һәм кием шкафын күзеннән кичерергә өлгерде. Юк, бу чит фатир түгел, шул үзе үскән, әнисе төзелештә ничәмә еллар, ал-ялны белми эшләгәне өчен бирелгән фатир иде. Кызыкай катып калды. Кире ишекне шапылдатып япты да урамга чыгып йөгерде. Уфада Рәйхана апаларының ишеген шакыганда урамда ярты төн иде. Бөтен күргәннәрен апасына чак сөйләп бирә алды. Нурзияне Уфа кырындагы Алексеевка бистәсенең зиратына куярга булдылар. Чөнки Уфада, йә булмаса Стәрлетамакка алып кайтып җирләү күпкә кыйммәткә төшәчәк икән. Аңа каян акча җиткерәсең дә, ничек башка кирәк-яракларын әзерлисең? Зәлифәнең ризалыгын алу кыен булмады, Рәйхана апасы аны тиз күндерде. Апасы бераз икеләнебрәк:

– Шундый үги әти белән, әлбәттә, бергә яшәмәячәксең. Фатирыңны алыштырып, йә булмаса бүтән җаен табып, укып бетерүгә, Уфага күчеп килерсең. Эшен дә табарбыз. Үзем урнаштырырмын. Ул сасып беткән калагызда нәрсә калган. Мөселманнары да бит телләрен сындыра-сындыра урысча сөйләшә. Үзебезчә бер сүз ишетермен димә. Уфага җитәмә соң! Хет башкортча, хет татарча авыз тутырып сөйләш, сиңа беркем аптырап карамас. Ю-у-к, кызым, укып беткән көе монда алып киләбез. Әниеңнең зираты да якын булыр. Былтыр ук карап куйган идем әни янында буш урынны, үземә дип. Нишлисең, күрәсең, Нурзиягә насыйп булгандыр инде, – диде.

Үлгән кеше үлә дә китә. Аны бу тормыш кыенлыклары борчымый. Үлгән артыннан үлеп булмый, дөньяның бөтен-бөтен калган мәшәкатьләре Зәлифәнең берүзенә өелеп торды да калды.

Рамил КУРАМШИН: «Мин хәзер дә сәхнәгә чыгып уйнарлык хәлдә идем»

(Дәвамы. Башы 38 нче санда).

– Озак еллар буе филармониядә эшләгәнсез, кызыклы вакыйгалар булмыйча калмагандыр...

– Хәзер шуларны искә төшерәм. Ул вакытта оҗмахта булганмын икән мин, дим. Филармония оешканнан алып (1937 ел) 1990 еллар башына кадәр аның эстрада бүлеге милли җыр-музыка сәнгатебезне халыкка ирештерә торган төп үзәк иде. Анда бит халкыбызның иң күренекле артистлары эшләде. Тик, ни аяныч, 1994 елда нәкъ менә шул бүлекне тарату башланды. Моның бөтен нечкәлекләрен белмәгән хәлдә, нindидер катгый нәтиҗәләр ясарга җыенмыйм. Әмма артистларның монда бернинди гаебе булмавын әйтә алам.

Бәлки, киләчәктә дөньялар үзгәреп, филармония элекке эзенә кайтыр әле, чөнки бүгенге эстрада сәхнәләрендәге башбаштаклыкларга, зәвыксызлыкка каршы торган бер үрнәк концерт оешмасы булырга тиештер бит?! Һәрхәлдә, мин үзем шундый теләктә калам, чөнки җыр-музыка – ул күңел ачу чарасы гына түгел, ә милләтнең рухын саклый торган милли идеология дә.

– Истә калган вакыйгаларны сөйләп үтсәгез...

– Башыңа төшсә, башмакчы буласың икән.

1970 еллар. Барлык район үзәкләрендә дә яшәрлек кунакханәләр булмау, барып-кайтып йөрергә рәтле юл, транспорт юклык аркасында, филармония артистларына авылдан-авылга күчеп, кеше өендә яшәп эшләргә дә туры килде. Фатирларда да бик иркен түгел, шуңа күрә хуҗабикәләр йокларга урынны ике кешегә бергә җәю ягын карады. Ул вакытта мин өйләнмәгән идем әле. Уйладым да, бу уңайсызлыктан котылу әмәлен таптым:

«Апа, зинһар, безгә урынны аерым җәймәссез микән, кеше белән ятасы булыр дип, менә шушы яшемә кадәр өйләнмичә дә йөрим инде!» – дигәч, хуҗабикәләр, көлә-көлә, ничек булса да, аерым урын хәстәрләү җаен тапты.

Икенче бер вакыйга:

Артистлар фатирга керүгә үк, билгеле, йорт хуҗалары күренекле җырчылар, музыкантлар турында кызыксына. Алдан сөйләшенгән диярсең, көн саен шул бер үк сораулар: «Фәлән артист өйләнгәнме?», «Фәләннең ничә баласы бар?» һ.б. Юлдан арып-талып килгәч, вакыт, бу бетмәс-төкәнмәс сорауларга җавап биреп торасы да килми. Шуңа да концерттан соң, бер төнне җәлләмичә, зур кәгазьгә иң еш бирелә торган сорауларга җавап яздым һәм, фатирга төшүгә, шул кәгазьне диварга элеп куйдым: «Безгә сорауларыгыз булса, менә монда җавапларын табарсыз», – дидем һәм бераз ял итеп алу ягын карадым. Хуҗалар бу кәгазьне көлешә-көлешә укыды һәм артист халкын сораулар белән бимазаламады.

Артистларга фатирның, әлбәттә, төрлесе очрый. Яхшылап кунак итүчеләр дә бар иде, ярым ач йөргән көннәр дә булды. Күнеккән инде без. Бер авылның клуб мөдиренә: «Кичә ураза тоттык инде, бүген бераз сыйларлык фатир булмасмы икән?» – дидек. «Була, була, кичә генә тана суйган абыйларда кунарсыз!» – диде ул.

Фатирга кереп урнашкач, хуҗабикә апа безнең алга бер кәстрүл пешкән бәрәңге китереп куйды һәм, «артистлар бәрәңге ярата бит» дип сөйләнә-сөйләнә, мич артына кереп китте. Шунда мин бәрәңге ашап утырган иптәшемә күз кыстым да: «Апа, белмәсәң, белеп кал: артистлар кичә суйган тана бавырын да үлеп ярата!» – дидем.

«Әле шулаймыни?» – дип, апа мич каршында кыштыр-кыштыр килде һәм, 20-25 минут үтүгә, майда кыздырылган, телеңне йотарлык бер таба бавырны китереп куйды.

– Атказанган, халык артисты исемен алу җиңел булдымы, күп эшләргә туры килдеме? Хәзер бит җиңел юллар белән генә алалар...

– Ул вакытта баянчыларга мактаулы исемнәрне бик бирмиләр иде. Беренче буын баянчылардан атказанган исемен алучы булмады. Шундыйрак замана иде. Миннән торса иде ул... Мин иң элек Мөхтәр Әхмәдиев белән Рокыя Ибраһимовага атказанган исемен бирер идем, чөнки алар – табигый профессионаллар.

Әйе, күп эшләдем. Ләкин мин бит ул исемнәрне нәкъ менә тир түгеп эшләп алдым! Бөтен баянчылар белә бу хакта. Аңлаган кеше аңлый: мин баянда исем алу өчен уйнамадым, менә бу көйне эшкәртәм дә, ул «кеше» булып китәр, аны уйнарлар, дип эшләдем. Баштан 16 ел эшләп – «атказанган» исемен, аннан соң тагын 16-17 ел эшләп, «халык артисты» исемен бирделәр. Шунысын әйтим: миңа бу исемнәрне бирделәр, мин сорап алмадым.

«Училище, консерваториядә укыганда шул, шул әсәреңне уйнадык», – диләр. Күңел күтәрелеп китә. Бервакыт Бауман урамыннан барам, бер рус, бер мари малае мине танып алды да яныма килде: «Сезнең әсәрләрне уйныйбыз. Бигрәк тә «Әпипә»не. Сезнең әсәрләрдә баянда уйнау ысулларының бөтен алымнары бар», – диләр.

Анысы да монысы: мин эшкәрткән «Әпипә» бөтен Идел буеннан алып Себер якларына кадәр таралды. Чөнки аны профессионал да, үзешчәннәр дә уйный ала. Ул искелек калдыгы түгел. Бер трио шул «Әпипә»не чит илдә уйнаган. Кабул ителәрме, дип сорагач, «бис»ка уйнадык, диделәр. Димәк, ул заманча да һәм бүгенге көн тыңлаучысына да туры килә. «Әпипә»не бөтен СССР уйнады. Менә ничек эшкәрттем мин аны!

Ленинградта бер баянчы белән танышкан идем. Ул телевидениегә трансляцияләнгән концертында минем берничә әсәрне уйнады. Бөтенсоюз телевидениесендә: «Татар халык җыры «Әпипә», Рамил Курамшин эшкәртүендә», – дип игълан иттеләр. Шуннан соң мине ил күләмендә таный башладылар.

Сүзем шул: халык көйләрен бик матур эшкәртергә була, һәм мин аны булдырдым да. Аның тәмен, «изюминкасын» табарга кирәк. Табасың икән, аны татар да, чуваш та, мари да уйный алачак. Шулай булды да ул.

Бөтенсоюз телевидениесенә эләгү – әлеге дә баягы тырышлык нәтиҗәсе. Ягъни яхшы, сыйфатлы материалны бүтән халык та кабул итә. Шуңа күрә Бөтенсоюз телевидениесендә татар баянчыларыннан беренче булып мин чыгыш ясадым. Мәскәүдә үземнең әсәрләрне уйнадым. Аны радиодан да игълан иткәннәр иде. Дөресен әйткәндә, бу –минем өчен каһарманлык булды. Чөнки татарны анда якын да җибәрмиләр иде…

– Рамил абый, ә сез ничек итеп көйләр яза башладыгыз?

– Мин бит гел уйнап торам. Уйнаганда фантазия дә эшли, башка матур көйләр килә. Аны вакытында теркәп куярга кирәк, алайса онытыла. Баян өчен әсәрләр язу эшенә чумдым мин. Караламаларым бик күп. Аны аннан-моннан гына эшләп булмый. Үзебезнең музыкантлар, теге яки бу әсәремнең чыкканын күреп, гел хуплый иде. «Начар» дигәннәре булмады.

Укыган елларда ук мин баян өчен пьесалар яздым һәм шуларны радиога барып уйнадым. «Чәчтем бодай», «Бишле» бию, «Сирәк-мирәк», «Җәйге авыл урамында», «Ташлар аттым Болакка», «Күңелле гармунчы», «Эрбет», «Баек», «Авыл яшьләре», «Бию», «Киндер сукканда», «Әпипә», «Гармун-патефон» һәм «Җаек күгәрчене» кебек әсәрләрем баянчылар арасында зур популярлык казанды.

Музыка училищесында укыган елларда ук инде мине «бер зур күләмле әсәрне оркестр белән бергә уйныйсы иде» дигән уй-хыял биләп алган иде. 1975 ел башында шушы хыялны Рөстәм Яхинга әйттем. Рөстәм абый тыңлап торды да: «Рамил энем, син бит үзең дә баян өчен әйбәт кенә әсәрләр язасың. Тырышып кара! Миңа калса, бу эшне дә үзең үк булдыра алырсың», – диде. Композиторның жылы сүзе миндә ышаныч тудырды, һәм мин, тәвәккәлләп, эшкә тотындым.

Шул елның апрель-май айларында «Баян белән оркестр өчен концертино» дип аталган әсәрнең клавирын тәмамладым. Соңрак оркестр өчен партитурасын яздым. Баянда уйнау өчен язылган беренче зур күләмле әсәрем иде бу. Казан дәүләт мәдәният институтының халык уен кораллары оркестры белән берлектә бу әсәремне радио һәм телевидение фондына яздырдым. 80нче еллар уртасында бу әсәр СССР телевидениесенең 1нче һәм 2нче программаларында күрсәтелде.

1987 елда тагын бер күләмле әсәремне – «Баян белән оркестр өчен концерт»ны тәмамладым. Җыр яратучыларга минем «Өй артыгыз гөлбакча», «Кичер, болыным», «Кайтса әгәр яшь чагым», «Хушлашмый китәм», «Аерылулар бигрәк авыр», «Җырларым җылытсын», «Балачагым чыккан каршыма», «Җомга азаны» һ.б. җырлар билгеле. Әзер шигырьгә дә көй иҗат иткәнем булды. Матур, эчтәлекле шигырь булса, үзеннән-үзе көй язарга этәрергә мөмкин. Мәсәлән, «Җырларым җылытсын» җыры шулай язылды. Нинди матур җыр! Әнә шул җырны радиодан бирмиләр, кызганыч. Мин ул җырны үзем башкарган идем: баянда да уйнадым, җырладым да.

«Тәртип» радиосыннан да җырларымны ишетәсе килә, җырларымны башка җырчылар җиренә җиткереп башкарса, сөенер идем. Баянда уйнаган язмаларым бар, аларны әйтмим дә. Ишеттерсеннәр иде шушы язмаларны. Бирмиләр бит. Радиодан яңгырамагач, кеше дә белми, тыңламый.

– Халык хәзер моңлы җырларга тартыла, дип әйтеп буламы?

– Була. Чөнки бүтән юлы юк. Ул кешенең халәтеннән дә тора. Якын кешеңне югалтканда яисә күңелсез вакыйга була икән, син көлеп йөри алмыйсың, ул чакта кеше моңая, күңелен юатырга дипме, моңлы җырлар тыңлый. Мин моңлы җырларны үлеп яратам. Шул җырларны тыңлаганда яшисе килә башлый, шундый рухи байлыгыбыз милли горурлык хисләре уята. Менә шул җырларыбыз яшәсен, онытылмасын дип, булдыра алган кадәр аларны башкарырга, пропагандаларга тырышырга кирәк.

Мәсәлән, татар яшьләре җыела торган «Калеб» хәрәкәтен беләм. Шунда күбрәк яшьләрне тартырга, шуны үстереп җибәрергә генә кирәк.

– Хәзер шундый мода китте: элекке җырларны заманчалаштыралар, яңартып җырлыйлар...

– Бу күренешкә уңай карамыйм. Дөрес әйбер түгел бу. Чөнки, гадәттә, аларны бозып җырлыйлар. Ул вакытта бит җырларны тавышы булган әйбәт җырчылар башкарды. Ул җырны йә шул дәрәҗәдә, һичьюгы, шул җырчыга охшатып җырла, йә бөтенләй җырлама.

(Ахыры киләсе санда).

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.
intertat.tatar

ЛИЛИЯ ДИГӘН

Татар театры дөньясында Мәхмүтовлар династиясе үзгә бер дәрәҗәле урын тота. Бу гаилә, бу династия актерлары – халык мәхәббәтенә ия бәхетле затлар. Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовлар корган җылы оядан канат ярган ике талантлы кыз баланың берсе – бүген «Мәдәни җомга»ның кунагы. Бу көннәрдә Татарстанның атказанган артисты Лилия ханым Мәхмүтова үзенең күркәм юбилеен бәйрәм итте. Лилия үзенең сәхнә мөлаемлыгы, нурлы сабырлыгы, әнкәсеннән күчкән йомшак моңы белән озак еллар тамашачыны куандырып яши. Аның белән артист баласының сабый чакларын искә алдык, сәхнәдә балкып үткән тансык елларны, меңнәрнең күңелләрен яктырткан, йөрәк аша үткән рольләрне искә алдык.

Дәү әни кочагында

Мине 8 айлык чагымда әнинең туган авылы Югары Әлкигә кайтарып куйганнар. Әти-әни – яшьләр, әлбәттә, аларның эшлисе килгән, рольләр, гастрольләр... Дәү әни мине 8 айдан 4 яшькәчә үстерде. Әни бушаган көннәрендә сагынудан йөгереп кайта торган булган. Иртә сөйләшергә, җырларга өйрәнгәнмен. Мин дәү әни белән дәү әтигә «әти-әни» дип дәшә башлагач, баланы югалтабыз бит, безне онытачак, дип борчылып, мине алып китеп, бакчага урнаштырдылар. Тик барыбер әти-әни белән үсү эләкмәде – Күчмә театр артистлары гастрольләрдән кайтып керми иде. Мин Рузия апа (Мотыйгуллина – ред.) белән калам, ул театр училищесында укый. Кайвакытта мине дә үзе белән ала. «Башыңны күтәрмә, парта астында гына утыр!» – дип мине алдан кисәтеп куя. Тик алай тыныч кына утыра алмыйм, баш чыга башлый. Марсель абый берсендә мине күреп: «Кем бар анда?» – дип кычкырмасынмы?! Минем кот чыкты. «Кемне алып килдең?» – дип сорый Рузия ападан. «Минә Исламия апалар гастрольгә китте дә, бакча эшләми, алып килдем инде», – дип аклана апа. «Чыксын, минем янда утырсын! Нигә парта астында утыра ул бала?» – дип үз янына утыртып куйды. Дөресен әйткәндә, мине карамаган кеше калмады бугай. Рузия апа үзе ала алмаганда, аның курсташлары – Ләлә апа, Фирая апалар мине бакчадан ала иде. Алар хәзер күренекле артистлар инде. Шулай үстем. Миңа җиде яшь тулгач, әни миңа сеңелкәш алып кайтып бирде. Беренчегә укырга кергән елны әни безнең белән өйдә торды.

Талантлы нәсел

Әнинең, Рузия апаның сәнгать юлыннан китүе тиктомалдан булмагандыр. Безнең бабай бик матур җырлый иде, авылда аны «җырчы Һидиятулла» дип йөртәләр. Әниләр алты бала үскән. Әни дә, апасы Роза да бик матур җырлый, ә Рузия апа бик тә биергә ярата. Әнинең күлмәклек материалларын һинд киемнәре, сарилар тегү өчен тураклап бетерә. Әнинең Фоат абыйсы исә гармунда бик шәп уйный. Сания апасын исә «гармунчы Сания» дип кенә йөртәләр. Дәү әни үзе безне җыеп, мөнәҗәтләр, бәетләр сөйләп, авызына каратып утыра иде. Әкиятләр сөйләргә бик ярата. Әни белән Рузия апа артистлыкка киткәч, Роза апа да шул юлдан китәргә сорап караган. Тик дәү әни ике баламны Казанга җибәрдем, сине җибәрмим, дип, ризалык бирмәгән. Ул гомере буе фармацевт булып эшләде. Рим җизни белән бергә үзешчән сәнгатьтән һич аерылмады.

Сеңелкәш турында

Сеңелкәш тууны мин бик көттем. Әнине гел сеңелкәш сорап йөдәтә идем. Алар гел өйдә юк, мин берьялгызым булмас идем, дип уйлый идем. Әти, әлбәттә, малай булыр дип өметләнеп көткән, ләкин, Аллага шөкер, Ләйсән туды. Минем бәхетемәдер дим, чөнки минем Ләйсәннән дә якын кешем юк. Сеңлем белән без бик тату, бер-беребезгә терәк булып, серләребезне сөйләп, киңәшләр бирешеп яшибез. Икәү генә сөйләшә торган сүзләребез дә бар.

Музыка һәм мин

Беренче сыйныфны гадәти мәктәптә укыдым. Химиклар мәдәният йортына музыка дәресләренә йөрим. Шундагы укытучым ишетү сәләтем бик яхшы икәнне сизеп алды да, консерватория каршындагы музыка мәктәбенә барырга киңәш итте. Үземнең фортепианога өйрәнәсем килгән иде, әниләр кредитка фортепиано да сатып алды, ләкин мине скрипкага өйрәнергә алдылар. Мондый абсолют ишетү сәләте йөз елга бер генә очрый, диделәр. Әниләр гел гастрольдә, мин көн саен ике транспортка утырып, Ирек мәйданы янындагы мәктәпкә килим. Хәзер беркемнең дә 7-8 яшьлек баласы алай йөрми. Иртәнге 7 дә чыгып китәм, кичке 9 да гына кайтып керәм. Дәресләрне шунда әзерләп кайтам. Ул мәктәптәге балаларның күпчелеге интернатта яши, ә мин Казанныкы булгач, интернат тиеш түгел.

Безгә кышын әнинең әбисен, Сабира әбине, алып киләләр иде. Әби мине иртән озатып җибәрә, кичен каршы ала. Өйгә кайткач та инструментта уйнарга кирәк, ә әби нишләптер минем скрипка шыгырдатканны яратып бетерми, шуңа күрә мин бәдрәфкә кереп уйный идем. Кемнең бәдрәфтә иҗат итәсе килсен инде? (Көлә.) Мин азрак уйнаган булып утырам да, чыгам, әлбәттә... Өч ел буе шулай укып йөрдем, дүртенче класста әниләргә Киров районыннан фатир бирделәр. Мәктәпкә йөрү тагын да кыенлашты һәм мин гадәти мәктәпкә күчтем. Ә музыка белемен Фрунзе урамындагы 4 нче музыка мәктәбендә алып чыктым.

Сәхнәгә урау юл

Башта ук театр училищесына бармадым мин. Әни болай диде: «Кызым, сиңа кирәкми ул. Безнең ничек гастрольдән кайтып кермәгәнне күрәсең. Ирең дә булмас, балаң да булмас, яхшылап уйла». Математика белән физикадан әйбәт бара идем, университетның физика факультетына укырга кердем. Анда дүртенче курска җиттем, һаман «театральный»га барасы килә. Әнигә гел зарланам, син теге вакытта җибәрмәдең, монда миңа ошамый, дим. Авылга кайтып, дәү әнигә дә еладым, әни «театральный»га җибәрми, дип. Ул әнигә әйтте: «Кызым, мин

авыл хатыны була торып та ике баламны артистлыкка җибәрдем, теләкләренә каршы килмәдем. Син исә үзең театрда эшләп тә, баланңы ник хыялыннан мәхрүм итәсең? Баланың теләге зур бит». Әни чыдый алмады: «Кызым, артыңнан йөрмим, Илдар абыең (Хәйруллин. – ред.) икенче курсны алып бара, шигырьләреңне әзерлә дә, үзең барып сөйләш. Ул сине кабул итсә, керерсең, кабул итмәсә, университетыңны укып бетерерсең», – диде. Мин әсәрләремне әзерләп, шатлана-шатлана, Илдар абый янына чаптым. Бу икенче семестрның башы иде. Илдар абый янына берничә артистны җыйды да, мине тыңлап карадылар. Шатлар. Иртәгә документларыңны алып кил, диделәр. Мин кая басканымны да белмичә, тиз генә университетка барып документларымны алдым да, театр училищесына илтеп бирдем. Икенче курска килеп кушылдым. Ренат Шәмсетдинов, Энҗе Шиһапова, Мәхмүт Фатыйхов, Илсөяр Сафиуллина, Җәвит Шакировлар белән укыдым. Курс җитәкчебез Илдар абый Хәйруллин иде. 1991 елда Тинчурин театрына эшкә җибәрделәр. Инде 32 нче ел китте, шушы театрда хезмәт итеп ятабыз.

Дуслыктан – мәхәббәткә

Ренат белән театр училищесына килгәч таныштым. Кинәт кенә кабынып киткән мәхәббәт түгел бу. Башта дуслашып йөрдек. Ренат курайда бик матур уйный, Мөршидә исемле кызыбыз баянда, мин фортепианода уйныйм, без уйный башлауга, бөтен группа янибызга җыела. Бергәләп җырлашып, биешеп күңел ачабыз. Аннары Ренатның Киров районында туганнары тора, Ренат аларда яшәде, укырга бергәләп бара, кайта идек. Шулай дуслашып киттек. Ел ярым йөргәч, өйләнештек. Икебезне дә Тинчурин театрына эшкә алдылар.

Сәхнә бәхете

Театрның стационарга күчкән вакыты гына, репертуар әллә ни бай түгел. Күбрәк читкә чыгып йөрергә туры килә. Әйтик, майда сезонны яба идек тә, берәр айга районнарга чыгып китәбез. Без килгәч тә, Илдар абый «Безнең эти мировой» (И.Юзеев) дигән спектакль куйды. Андагы апалы-сеңелле кызларның мин – апасын, ә Илсөяр Сафиуллина сеңлесен уйнады. Бу минем театрдагы беренче ролем булды. Аннары башка спектакльләргә кертә башладылар. Тиздән әни «Резидәкәй»не (И.Юзеев, Ш.Мәҗитов) чыгарды, бу әсәрне ул махсус минем өчен һәм Ренат өчен куйды. Ренат Габделхәйне, Илдус Фәиз Зөфәрне уйнады, мин – Резидәкәй. Шушы спектакльдән соң мин тамашачының безне ничек кабул иткәнен аңлый башладым. Халык бу тамашаны бик яратты. Кызлар Ренат белән Илдуска мөкиббән китеп, спектакль беткәч, автограф алырга дип артларыннан чабып йөри иде. Аннары «Гашыйклар тавы» (И.Юзеев) чыкты, мин анда Мөнирәне уйнадым. Аннары башка рольләр... Мине тамашачы әнинең дәвамы итеп кабул итте.

ЧӘЧКӘ...



Бердәнбер улыбыз...

Мин театрга соң килдем, 24 яшь иде. Дүрт ел университетта вакытымны үткәреп килгәннән соң, минем бик тә сәхнәдә уйныйсым килде. Декретка киткәч, әлбәттә инде, спектакльләрдән төшеп каласың. Һаман театрда кирәкле кеше булып йөрисең дә бер мәлне обоймадан төшеп каласың, авыр булып китә. Шәхсән миңа шулай тоелды. Ришатны авыррак та таптым. Өлгерермен әле, вакытым бар әле дип йөри торгач, бер бала белән утырып та калдык. Мин уйлаган вакытта инде соңга калган булып чыктык. Улыбызга быел 27 тула. Өйләнмәгән әле. Йөргән кызы да юк. Берсендә ул миннән: «Маржага өйләнсәм, ничек карыйсың?» – дип сорады. «Юк!» – дидем. Мин милләтче түгел, әмма һәрбер кеше үз милләте белән гаилә корырга тиеш дип уйлыйм. Улыбыз династия юлын дәвам итмәде. Бәлки, ул бик әйбәт артист та булыр иде, һәр яклап сәләте бар. Гитарада уйнап җырлый, музыка мәктәбе тәмамлады. Флейтада уйный, төрле конкурсларда җиңде. Тик ул иҗат юлын сайламады, компьютер белән мавыгып китте, программистлыкка укыды. Укып бетергәч, армиягә барып кайтты. Хәзер ул Росгвардиядә хезмәт итә. Мультфильмнарны тавышландыру белән дә шөгыльләнә.

Ялагайлыкны белмәдем

Улыбызның театр өлкәсенә китүен үзем теләмәдем, дөресен әйтим. Чөнки артист кеше ул бик нык режиссерга бәйле. Әгәр син аның күзенә мәхәббәтле булып күренәсең икән, ул сине һәр спектакльгә алырга мөмкин. Ләкин еллар буе рольсез йөргән актерлар да бар. Үзем режиссерларга беркайчан да ялагайлана белмәдем. Үземә режиссерлардан җитәрлек игътибар бирелде, дип тә санамыйм. Яшь вакытта күп уйныйсы килде, әлбәттә. Кайчагында спектакль карап утырганда, «миңа бу роль миңа туры килгән булыр иде», – дип уйлап куям. Үкенечләр бар, әлбәттә, яшь чакта уйныйсы килеп калган рольләр... Тик минем яшькә җиткәч, тегене уйнар идем, моны уйнар идем, дип хыялланып утырмыйсың. Нинди роль бирсәләр, шуны башкарасың. Әни дә гомере буе гаделлек белән яшәде. Дөрес, беркайчан да эшсез тормадым. Ләкин беркайчан да театр юлын сайлавыма үкенмәдем! Себер якларында гастрольләрдә йөрергә туры килде. Көн саен икедә торабыз, өчтә автобуска утырып чыгып китәбез. Унышар сәгать барабыз юлда. Шәһәр аралары ерак – 800-1000 км. Барып җитүгә, һәркем эшкә керешә: кем үтүкли, кем сәхнә кора... Спектакльне уйныйсың, әйберләрне җыясың. Кунакханәгә илтеп ыргыталар. Биш сәгать йоклыйсың да, икенче көнне тагын шул ук хәл башлана. Егерме бер көн буе шулай йөреп кара әле син! Спектакльләргә киләләр, татарча аңлыйлар иде әле. Хәзер инде ул якларда яшь буын татарчаны гомумән аңламыйдыр... Чөнки утыз биштән яшьрәкләр ул чакта ук наушник белән тәрҗемәдә тыңлый иде.

Безнең гаилә тамашасы

Гаиләбез, династиябез белән бер спектакльдә уйнарга туры килмәде. Үзебезгә генә атап берәр пьеса алып, Мәхмүтовлар уйный дип халыкны чакырып... Режиссерыбыз никтер мондый проектка алынмады... Югыйсә, тамашачы кассада элек гел сорый иде: «Исламия апа уйныймы бүген? Кызлары, кияүләре уйныймы?» Нәкъ менә безнең гаиләне карарга йөрүче тамашачы бар иде. Ләйсән шуңа күрә: «Бер сәхнәдә уйный алмадык, телевидениедә булса да, барыбыз бергә төшик әле», – диде. Сценарий язды да, барыбыз да исән-сау чакта төшеп калыйк, дип безне оештырды һәм «Уеннан уймак» телевизион комедиясе туды. Ул бик юморлы, кызык булып чыкты, халык җылы кабул итте. Аннары рухланып, икенче өлешен дә эшләдек. Ләйсән ул бик талантлы, тик сәләтенең яртысын да кулланмый шул.

Бакчамнан илһам алам

Минем хобби – бакча. Берәү генә дә түгел, ике бакча. Түбән Осланда 4 сутый җирдә бөтен нәрсәне үстерәм. Салмачыда йортыбыз бар. Әни төзәтә башлаган иде ул йортны. Алмагачлар, чия, слива, кара миләш, бөрлегән, кура җиләге, крыжовник, грушам бар. Бөтен нәрсә үсә. Кайберәүләр миңа: «Ике бакчаны каравы авырдыр, ник сатмыйсың?» – ди. Авыр, килешәм. Ләкин ул бит минем балам кебек! Баланы 24 ел буе карап үстер, буй җиткез дә чит кешегә сатып җибәрәсеңмени? Табигате искиткеч! Һавасы ук үзгә. Идел якында гына. Тау астында аккан чишмәнең челтерәп акканы ишетелеп тора. Шул матурлыкка карап хозурланып, илһам алам. Ә язларын, барлык бакчалар чәчәккә күмелгәндә, мондагы матурлыкны әйтеп-аңлатып бетерерлек түгел!..

Эльмира СИРАҖИ әзерләде.

Гимн – язмышны сайлау

(Дәвамы. Башы 38 нче санда).

СҮРИЯ ГИМНЫ

Моннан чирек гасыр элек Чаллыга кунакка килеп киткән Валерия Порохова – Коръәннең рус теленә шигъри тәрҗемәсе авторы. Хәзер инде гүр иясе. Тормыш юлдашы Сүрия кешесе белән Димәшкътә яши иде. Валерия ханым безгә Сүрияне чыннан да җир җәннәте һәм ислам диненең тоткасы дип сурәтләде. Бүген бу ил – «бихисап дөнья халыкларын мәңгелек көтүлектә тоту» турында хыялланучы көчләр алып бара торган «ахыр заман сугышы»ның үзәгендә...

ВАТАН САКЧЫЛАРЫ

1. Ватан сакчылары, сәлам сезләргә!
Горур җан юл куймас кимсетүләргә.
Гарәпчелекнең бу изге оясы,
Кояш тәхете – гел азат буласы.
Биек манаралар – Шам түбәләре,
Җиде кат күк белән аңгәмәләре.
Биек манаралар – Шам түбәләре,
Җиде кат күк белән аңгәмәләре.
Юнәлткән гүзәл йөзен ул кояшка,
Безнең ил охшаш күктәге оҗмахка.
2. Байрагыбыз – илне бердәм итүче,
Өметләр бишеге һәм йөрәк тибеше,
Түгелме аңарда күзләрнең бәбәге,
Түгелме шәһит канының мидәде?
Бабалар мирасы – шанлы юлыбыз,
Дәһшәтле сакчыбыз –
кодрәт-рухыбыз.
Бабалар мирасы – шанлы юлыбыз,
Дәһшәтле сакчыбыз –
кодрәт-рухыбыз.
Бездән – әл-Вәлид, һәм бездән –
әр-Рәшид.
Нигә хөр яшәүгә илтмәс бу нәшид?

ӘФГАНСТАН ГИМННАРЫ

Әфганстанда гимннар еш алмашынып тора. Кем хакимиятькә килсә, шул үзенекен көчләп тага. Биредәге текстларның беренчесе – бүгенге талиплар нәшиде. 2006-2021 елларда рәсми рәвештә яшәгән, милләтара татулыкны һәм Әфганстанның демократик үсешен алга сөргән «Милли жыр» гимнына алмаш булып килде. Гәрчә 1991-2006 еллардагы сынауны үтә алмаган булса да.

Бу – кыюлар Ватаны

(1991-2006, 2021-...)
Кушымтасы:
Кан коеп саклыйк аны, бу –
шәһитләр Ватаны!
Бу – кыюлар Ватаны, бу –
батырлар Ватаны!
1. Гүя кызыл якутлар – тау-ташлар
һәм куаклар.
Чәчәкләргә тамган ул –
Ватан уллары каны.
Арысланнар Ватаны –
аны җиңеп буламы?
Бу кыюлар Ватаны,
бу батырлар Ватаны!
Кушымтасы.

●Фикердәшләр, дуслар: Зиннур Әһлиуллин, Фәһим Җиһаншин һәм Илисә Ганиева.

2. Гомеребез барында –
без азатлык сагында!
Гомеребез барында –
без тарих кочагында!
Бөркетләр тота аны, бу –
бөркетләр Ватаны!
Бу кыюлар Ватаны,
бу батырлар Ватаны!
Кушымтасы.
3. Минем газиз Ватаным,
аңарга фида җаным!
Гүзәл болын-кырларым,
барысына фида җаным!
Инглиздән иттек азат,
урыска кордык зират!
Бу кыюлар Ватаны,
бу батырлар Ватаны!
Кушымтасы.
4. Урыс калдырган, күрче,
– баш сөякләре күче!
Барча дошман җиңелгән,
өметләре өзелгән!
Барысының хәтер-аңы:
бу – әфганнар Ватаны!
Бу кыюлар Ватаны,
бу батырлар Ватаны!
Кушымтасы:
Кан коеп саклыйк аны,
бу – шәһитләр Ватаны!
Бу – кыюлар Ватаны,
бу – батырлар Ватаны!
Бу – кыюлар Ватаны...

Милли жыр (Әфганстан)

(2006-2021)
Бу ил – безнең Әфганстан,
Һәр илдәшкә гыйззәт вә шан;
Солых җире, кылыч җире,
Һәр улы аның каһарман.
Күп кавем илгә ватандар:
Һәм бәлүҗләр, һәм үзбәкләр,
Һәм пуштуннар, һазаралар,
Һәм таҗиклар, һәм төркмәннәр.
Бердәй гарәпләр, гүҗҗарлар,
Памирлылар, нурстанлылар,
Кызылбашлар, браһүиләр,
Дүрт аймак һәм пәшәиләр.
Балкыр ил дөнья күгендә
Галәмдәге Кояш кебек,
Азиянең иң түрендә
Ватаныбыз – ул мәңгелек!
Әйт: «Илаһым – Хак вә Рәһбәр;
Тәкрарым: Аллаһы әкбәр!

ҮЗӘК АФРИКА ҖӨМҺҮРИЯТЕ ГИМНЫ

1960 елда бәйсезлек алыр алдыннан, илнең беренче президенты һәм француз этнографы-көйязары иҗат итеп калдырган гимн. Бүген Африка үзәгендә халыкара бандитлар оя тота. Ләкин мәңгелек түгелдер бит аларның биредәге шабашы!

Янарыш

Үзәк Африка, бантулар бишеге!
Шәрәфле тормыш – бу ихтыярың!
Күптән көлкегә калган, изелеп,
Золым богавын ватып ташлавың.
Хезмәт һәм тәртип аша – мәртәбә,
Хокуклар яулап, бердәм буласы.
Бу яңа авыр юлны үтәргә! –
Ата-бабаның гозер нидасы.
Кушымтасы:
Бердәмлек белән тырыш хезмәттә
Яула хокуклар, иреш хөрмәткә;
Бетсен фәкыйрьлек, золым һәр җирдә,
Ватан байрагы, горур җилфердә!

Житешле илләрдә ничек җырлыйлар?

– Азиянең иң алга киткән иле дип саналган Көньяк Корея һәм федератив Алманиянең икътисадый вә милли-дәүләти тоткасы булган Байар Иле (Бавария) гимннары.

КӨНЬЯК КОРЕЯ ГИМНЫ

1. Шәрекъ диңгезе кибегеп,
Пәктусан уалып
Беткәнче хакла,
Тәңребез,
безнең милләтне.
Кушымтасы:
Өч мең ли гөлчәчәкле
тау, гүзәл елгалар –
Мирас итик оныкларга
изге бүләкне!
2. Йөзләп еллар Намсан-тауда
җилләр-давылларга
Бирешмәгән нәратлар күк,
без дә куәтле.
Кушымтасы.
3. Биек аяз көзге күкләр һәм
ай сипкән нурлар
Һидаятькә өнди безнең
чыдам йөрәкне.
Кушымтасы.
4. Рәхәттә дә, михнәттә дә
тугрыбыз Ватанга –
Безнең халык көчле рухлы,
батыр йөрәкле.

Кушымтасы.

БАЙАР ИЛЕ ГИМНЫ

1. Ходай Байар
Илен яклый,
Алман нәселе
Ватанын,
Киң җирләребез
сагына
Җәеп кодрәт калканын!
Иминлектә ил-көнебез,
Шәһәрләр төзелеше,
Безнең ак-зәңгәр байракта –
Изге күкләрнең төсе.
2. Ходай Байар халкын саклый,
Без – бабалар мирасын,
Бердәмлектә, татулыкта
Корып бәхет оясын.
Байар халкы, алман нәселе!
Ходай биргән байлыгың:
Борынгы даның сурәте –
Ак-зәңгәр төс байрагың!

Ерактагы якын дөнья

– Океания – дөньяның«җәһәннәм тишегендәге» һәм әлегә чын тарихы язылмаган иң серле төбәге ул. Ни өчен Һавайя, Таити, Яңа Зеландия һ.б. кебек, Тын океан эчендә берсеннән-берсе меңнәрчә чакрым ераклыкта урнашкан, җирле кешеләре гасырлар буе бер-берсе белән аралашмаган утрауларда җирле халыклар телләре бүген дә шулкадәр охшаш?! Хәтта мәҗүси аллалары да уртак аларның – Atua! Бу табигый сорауга бер генә галимнең дә ышандырырлык итеп җавап биргәне юк.

ФРАНЦУЗ ПОЛИНЕЗИЯСЕ (ТАИТИ) ГИМНЫ

Беренче биш юлы һәм соңгы өч юлы аерым-аерым икешәр тапкыр башкарыла.

Тәңрем минем илне
барлыкка китергән,
Гүзәл утрауларны
Ул бәйләмләп үргән,
Мәңгелеккә дип, бәҗра әйләгән,
Гөлләргә күмеп, хуш ис бөркегән.
Бүген мин илне данлыйм
һәм мактыйм.
Һәм балаларның гозерен тыңлыйм:
«Сөюең синең җирләргә сеңсен,
Бөек Таити яшәсен өчен!»

ЯҢА ЗЕЛАНДИЯ ГИМНЫ

Кануни рәвештә бертигез дип саналган маори һәм инглиз телләрендәге куплетлар бер-бер артлы башкарыла. Маори телендә нибары 60 меңләп кенә кеше сөйләшә һәм тагын 100 меңе бу телне аңлый, ләкин актив куллана алмый. Аотеароа – Яңа Зеландиянең маори телендәге атамасы, «озын ак болыт иле» дигән мәгънәдәге сүз.

Әй Тәңребез, Аллабыз,
Тик Сиңа табынабыз,
Таң иле милләте без –
Сиңа мәхәббәтебез.
Илне муллыкта яшәт,
Кайгырт һәм ярдәм күрсәт,
Сакла гел иминлектә
Аотеароаны.

«Релаксация гимннары»

Берничә илнең милли гимны бик салмак, тыныч, ягымлы һәм йөрәккә ятышлы көйгә һәм шундый ук эчтәлекле текстка ия. Мин аларны элегрәк... Ирландия бишек җыры көенә үзем «Әллүки»гә ияреп язган көйдән соң, кече онығымны йоклатканда да тыңлата идем. Хәзер инде боларны көн саен ял итү һәм көндезге мәшәкатьләрдән соң үземне тиешле халәткә кайтару өчен тыңлыйм. Бу гимннар – чын «җан дарулы».

ЯПОНИЯ ГИМНЫ



Галиҗәнап хакимлеге
Мең еллар Сез
тәхеттә;
Хаким булыгыз
бәхеттә –
Вак ташлар
Кодрәтле тау-кыя булып киткәнче,
Өсләрендә мүк үскәнче.

ЧЕХИЯ ГИМНЫ

Кайда минем
туган йортым?
Кайда минем
туган йортым?
Сулар ага болыннарда,
Урман шаулый
тау-кыяда,
Шау чәчәктә ул язын –
Оҗмахлар кайда тагын?!
Гүзәллектә туган йортым,
Чех җирендә учагым.

МАҖАРСТАН (ВЕНГРИЯ) ГИМНЫ

1. Йа Ходаем, маҗарны
Саклагыл, ярлыкагыл,
Суз ярдәмчел кулыңны,
Дошманнарын гаҗиз кыл.
Язмыш, өз золым көчен,
Бәхетле ит барчасын,
Үткән һәм алдагы өчен
Күрде халык казасын.
2. Юл сыздың Карпат аша
Маҗар бабаларына,
Бирдең Ватан-гөлбакча
Бәндәгуз улларына.
Тиса, Дунай сулары
Үтә тауларны урап, –
Батыр Арпад уллары
Анда мул тормыш кора.
3. Кун иле җирләрендә
Чайкала тук башаклар,
Токай тәлгәшләреннән
Тама татлы шәраблар.
Безнең ту еш балкыган
Төрек кирмәннәрендә,
Матьяш явы сыкраткан
Вена түрәләрен дә.
4. Гөнаһларыбыз үче
Кысты Синең күкрәкне:
Аттың болыттан яшен,
Күкрәттең безнең күкне.
Баскын монголлар угы
Очты баш өстебездә,
Аннан төрек коллыгы
Йөк булды җилкәбездә.
5. Күпме торды яңгырап
Кыргый госман гаугасы,
Яугир җәсәден таптап
Җиңүләр тантанасы!..
Күпме сине улларың,
Гүзәл ил, күкрәгеңә
Басып изде, кыйнады,
Әйләндереп кабергә!..
6. Эзәрләүдән капланып
Утырмасын кай өндә,
Сыеныр җир тапмады
Үз Ватанында бәндә.
Менсә тау түбәсенә –
Ут диңгезе өстендә,
Һәркайда кайгы-хәсрәт,
Кан үзәне бар җирдә.
7. Кирмән иде – таш өеме,
Хозур, бәхет югалган,
Афәт, үлем сөреме
Ватанны чолгап алган.
Аһ, мәетләр каныннан
Азатлык чәчәк атмый,
Илсезләр елавыннан
Шатлык күз яше акмый.
8. Кызган, Ходай, маҗарны
Дөнья михнәтләрендә,
Суз ярдәмчел кулыңны
Газаплар диңгезендә.
Язмыш, өз золым көчен,
Бәхетле ит барчасын,
Үткән һәм алдагы өчен
Күрде халык казасын.

И туган тел!..

Милли телләргә багышланган дәүләт гимннары күп түгел. Тәрҗемә ителгәне берәү генә – Молдова гимны. Молдаван теле бу илне... «Бөек Румыния»гә кереп китүдән саклый.

МОЛДОВА ГИМНЫ



1. Безнең тел –
бакый хәзинә,
Бик тирәндә тамырлары,
Җиребез буйлап сибелгән
Энҗеләр, асылташлары.
2. Безнең тел –
дөрләгән учак:
Халкым үлем йокысыннан
Уянсын тормышка сусап –
Әкияттәге батыр сыман.
3. Безнең телебез җырлары,
Дойналардагы сагышлар
Ача якты офыкларны,
Тарала кара болытлар.
4. Безнең тел – ул икмәк теле,
Җәен җилләр сызгырганы,
Бабалар, җиргә тир түгеп,
Мөбарәк иткәннәр аны.
5. Безнең тел – ул яшел яфрак,
Кодру урманнары шавы.
Нистру бормалары качыра
Йолдызлар яктысы явын.
6. Һич ачынып зарланмагыз,
Ярлы дип телегез бигрәк,
Сайланган тел ул, аңлагыз, –
Тора илебезне бизәп.
7. Безнең тел – ул тарихи тел,
Борынгы хәлләр дастаны.
Өйрән аны һәм танып бел
Хакыйкатьнең ни булганын.
8. Безнең тел ул билгеләнгән
Күкләрне мактау йөзеннән –
Өйдә, чиркәүдә бәндәләр
Тайпылмас дип Хак сүзеннән.
9. Безнең тел – изгелек нуры,
Аңарда ата-бабалар
Елый-елый, җырлый-җырлый
Өйдә гыйбадәт кылганнар.
10. Чыгарыйк телне хәяткә,
Коткарып заман явыннан,
Пакьлик пычрак-күгәректән,
Онытылу аһ-зарыннан.
11. Җыйыйк кояш нурларыннан
Очкын алган чакматашын, –
Ургылыр тел байлыгыннан
Яңа сүзләр булып ташкын.
12. Яшәячәк бу хәзинә,
Бик тирәндә тамырлары,
Җиребез буйлап сибелгән
Энҗеләр, асылташлары.

Фәһим ЖИҺАНШИН.

Тәкъдир

Газиз анабыз Әминә Габделкаюм кызының мондый шигъри юлы бар иде: «Тәкъдир каләмнәре бездә булса, язмас идек болай тәкъдирне». Анабызның сүзләре сорау тудыра. Һәркемнең тәкъдир каләме үзендә булса, киләчәге нинди булыр иде икән? Тукаебызның «әхлак, вөҗдан, инсафлыкларны сөреп чыгардык», – дигән сүзләре яшәештә чынбарлыкка әверелсә, иртәгәбез нинди булачак? Моңа җавап – тик Раббыбызның карамагында...

Сентябрьнең бер кичендә Айгөл Бариевага багышланган «Әй язмыш, язмыш!» тапшыруы булды. Җырчы үз язмышын – Аллаһы Тәгалә бүләге, дип кабул итә. 25 ел бергә гомер иткән ире Линарның китеп баруын да Аллаһы Тәгалә сынавы дип нәтиҗә ясаган. Ул Линар белән бергә яшәвен бүген дә бәхет дип саный һәм Раббыбызның мәңгелек җәннәтендә янә бергә кушылуларын ялвара. Моңа охшаш язмышлар күп. Имчәктәш туганым Энгельнең кызы Ләйсәннең кияве Ринат та, ике баласын калдырып, якты дөньядан китте. Ләйсән дә ялгызлык хисләрен кичерә, Аллаһы ярдәм итсен үзенә!.

Берәү дә мәңгелеккә килмәгән. Ялгыз калу, нинди яшьтә булуыбызга да карамастан, беребезне дә читләтеп үтми. Яшел Үзәндә яшәүче туганыбыз Гөлчирә дә, ире Индус дөнья куйгач, ялгызлыкта ачынулы гомер кичерә.

Беренче президентыбыз Минтимер Шәймиев тә, хәләл җефете Сәкинә ханым дөнья куйгач, шундый ук рухи ялгызлыкта. Аңа, көчле рух иясенә, Аллаһы Тәгалә бу хисләрдән арынырдай юлны милләтебезнең киләчәген кайгыртып, бертуктаусыз изге эшләр эшләп яшәве белән ача тора.

Яшермим, үзем дә 55 ел бергә гомер кичергән Люциямне мәңгелеккә озаткannan соң бәхетемне югалтканымны тою хисләре белән яшим. Аллага шөкер, янымда улыбыз Илдар, киленем Нурия бар. Миңа ярдәмне энем Энгель, аның хәләл җефете Венера ирештерә тора.

Гомерләр, шагыйрь Роберт Миңнуллин язганча, үтә дә китә, яна да бетә икән. Ләкин кылган гамәлләребез югалмый, актык көннәребезгә кадәр хәтер капчыгында саклана. Тарихыбызга зур өлеш керткән Рәмзи Вәлиев, Алексей Литвин, Хатип Миңнегулов, Разил Вәлиев, Римзил Вәлиев, Ренат Харис, Марсель Бакиров, Вахит Имамов кебек кордашларыбыз белән сирәк кенә булса да уртаклашып, яңартып торабыз. Кеше китә, ә тарихта эзләре кала. Иң зур теләкләрнең берсе: эзләребез тарихта ак булып, пакь булып саклана күрсен иде.

Малай чагымда 95 яшенә җиткән бабабыз Шәйхетдиннең «Без бу дөньяда өч көнлек кунакта гына» дигән сүзләрен исем китә иде. Ничек инде аның шушы кадәр озын гомере өч көнлек кунак кына икән, дип аптырый идем. Ә ул дөрес икән. Шактый гомер кичергән булсам да, кеше гомеренең чикле икәнлегенә көннән-көн инанам. Язмыш – ул Аллаһы Тәгалә билгеләгән тәкъдир, аннан узмыш юк.

Аерым адәм баласына караганда милләтебезнең язмышы, татар язмышы күпкә кадерлерәк. Милләтебез сикелтәле юллар аша, бөеклегеннән коллык упкынына төшеп, аннан зур авырлыклар белән чыгып, бүгенге көнгә кадәр килеп җитте. Еллар югалтуларсыз булмады. Динебезгә, телебезгә, гомумән милли яшәешебезгә куркыныч тудырган еллар кичердек. Ләкин яртылаш зәгыйфьләнеп-имгәнеп булса да, алардан чыга алдык һәм югалтканнарны торгызу юлына бастык. Бүген дә алдыбызга биек киртәләр өстәлеп тора. Зур авырлыклар белән барлыкка килгән республикабызга юкка чыгу, аны гадәти губернага әверелдерү куркынычы яный. Әмма республикабызны мөстәкыйль хокуклар белән яшәүче дәүләт рәвешендә аякка бастыру бурычы онытылмый. Моны дошмани көчләр Россиядән читкә китү юлы дип куркыта. Юк, һич тә алай түгел. Татарларның күпчелеге, Татарстаннан тыш, әле Россия төбәкләрендә дә яши. Шунлыктан милләтебезне бербөтен рәвештә яшәтү өчен Россиянең бөтенлеге кирәк. Татарлар аны һәрвакыт саклау юлында булды, бүген дә шул юлда. «Рус белән тормыш кичердек сайрашып, тел, лөгать, гадәт вә әхлак алмашып»,- дип язган Тукай. Хәзер бурычыбыз – Россияне чын мәгънәсендә федератив дәүләткә әверелдерү.

Әмма кайбер югары даирәләрдә телебезгә карата кизәнүләр һаман дәвам итә. Бу хакта күп язылды, кабатлап тору артык. Ләкин милләтебезгә карата басым көчәя баруын күзәтү яман, ул бик гарьләндерә. Телебезне саклау – җитәкчеләрнең генә түгел, киң җәмәгатьчелекнең дә зур бурычы. Телне саклау өчен көрәш Татарстанда гына түгел, ә элеккеге советлар иленең барча киңлекләрендә тантана итә. Төрле рәвештәге конкурслар, Олимпиада кебек чаралар үткәрүләр балалар бакчасыннан башлап урта уку йортларында кадәр гадәти хәлгә әйләнеп бара. Татар телен өйрәнү курслары арткаnnan-арта. Хәтта Мәскәүдә дә телебезне гамәлләштерү эшләре җәелде. Андагы «Муравейник» курсларына руслар да йөри. Эшнең башында татарлар һәм төрки халыкларның Конгрессы тора.

Бу – юл башы гына. Дини челтәр дә бу изге гамәлдән читтә калмады, республиканың 100 дән артык мәчетендә татар теле курслары эшли. Татарстаннан читтәге мәчетләрендә дә шундый ук хәл. Ульян шәһәренең «Нур» мәчетендә хәтта балалар һәм олылар өчен аерым ике курс эшли. Удмуртия, Чувашстанда, Төмән, Самара, Саратов өлкәләрендәге мәчетләрнең дә шушы көрәшкә кушылуы сөенеч.

Индүс ТАҺИРОВ.

Атнаның сәяси мизгелләре

ТАБЫЛМЫЙ ТОРГАН ӘМӘЛ

23-27 сентябрь көннәрендә Украинаның дүрт төбәгендә үткәрелгән "референдум" нәтиҗәләренә таянып, узган атнада Мәскәүдә аларны Россия составына кабул итү мәрәсиме үткәрелде. 30 сентябрьдә РФ президенты В.Путин әлеге төбәкләрнең (ДНР, ЛНР, Запорожье һәм Херсон өлкәләре) Россия составына керүләре турында килешүләрне имзалады, ә соңрак инде алар РФ парламентында ратификацияләнде һәм президент тарафыннан да имзаланды. Иң мөһиме – РФ Конституция суды бу гамәлләрнең Төп Законга туры килүен белдерде. Ә бу инде үзе үк зур күрсәткеч булып тора. Әмма фронттагы хәлләр аңа карап кына үзгәрмәде.

Рәсми хәбәрләргә ышансак, киресенчә, бу чорда Россия гаскәрләре Украинада байтак кала вә салаларны калдырырга мәҗбүр булган. Әйтик, РФ Саклану министрлыгының рәсми вәкиле генерал-лейтенант И.Конашенков сүзләренә караганда, чолганышта калу куркынычы янау сәбәпле, 1 октябрьдә союздаш гаскәрләр, Кызыл Лиман каласын калдырып, отышлырак позицияләргә чыгарылган. Охшаш хәбәрләр инде бу атнада да булды. Рәсми вәкил һәр көнне Украинаның бик күп сугышчысы һәм хәрби техникасы юк ителүе турындагы хәбәрләрне дә ирештереп тора. Тик фронттагы хәлләрне бу да үзгәртә алмый.

Ә тактик максатлы атом-төш коралын Украинада куллануга ишарәне Көнбатышта җитди кабул иткәннәр. Вашингтон андый очрак өчен конкрет гамәлләр планы да булдырган һәм, Мәскәү белән туры элемтәгә чыгып, нәтиҗәләр аның өчен котны ала торган булачагы турында кисәткән. Атом-төш янаулары Украинадагы хәлне тагы да катлауландырачагы турында хәтта Кытай да белдергән. БМО Генераль секретаре А.Гутерриш исә андый коралны теләсә нинди куллану да "гуманитар армагеддон"га китерәчәге турында искәрткән. Хәлбуки, "Референдум" һәм төбәкләрне кушуга карата реакция дә үзенчәлекле күренә: Киев тизләтелгән режимда НАТОга керү өчен гариза биргән һәм Россия лидеры В.Путин белән сөйләшүләр үткәрүнең мөмкин түгеллеген раслый торган указ чыгарган; күпләр (АКШ, Бөекбритания, Канада, Япония һ.б.) Россиягә каршы яңа санкцияләр дә керткән һ.б.

Игътибарны БМО КШның 1 октябрьдә үткән утырышы да җәлеп итә. КШ каравына анда әлеге референдумнарны танымау турында АКШ һәм Албания әзерләгән резолюция проекты чыгарылган. КШдагы 15 әгъзадан унысы аны хуплап тавыш биргән, 4 есе (Бразилия, Габон, Кытай һәм Һиндстан) – битараф, Россия исә вето хокукын кулланган. Документ шул сәбәпле кабул ителмичә калган. Әмма быел апрельдә БМО Генераль Ассамблеясе (ГА) кабул иткән резолюция буенча, КШның 5 даими әгъзасыннан кем дә булса вето хокукын кулланган очракта, ун көн эчендә ГА үз утырышына җыелып, мәсьәләне анда тикшерергә тиеш була. Димәк, мәсьәлә инде тиздән анда каралачак.

Фоат УРАЗАЙ.

Замандашның гыйбрәтле китабы

1936 елның маенда җиһанга аваз салган Индус Ризак (Риза углы) Таһиров – соңгы ярты гасырда Татарстанда, татар дөньясында гына түгел, ә ил күләмендә, халыкара мәйданда да шактый танылган шәхес. Ул – күренекле тарихчы, сәясәтче, остаз-педагог, җәмәгать эшлеклесе, профессор, академик. Аның балалык һәм үсмер, мәктәптә уку еллары Шөгер, Түбән Чыршылы, Әлмәт кебек кала-салаларда уза. Әнисе Әминә Каюм кызы – укытучы, мәктәп директоры, мәгариф бүлеге хезмәткәре. Әтисе Ризак Шәйхетдин углы – авыл советы рәисе һәм колхоз җитәкчесе. Бөек Ватан сугышы башлангач, хәрби хезмәткә алына. Рота белән командалык иткән өлкән лейтенант дәрәҗәсендәге бу зат 1944 елның ноябрендә һәлак була, Латвия туфрагында җирләнә. Әтисез калган өч бала әниләре тәрбиясендә үсә. Аларның икесе зур галим булараk таныла. Индус әфәнденең энесе Энгель Таһиров (1940 елгы) – шулай ук тарих фәннәре докторы, профессор, академик, җәмәгать эшлеклесе.

Индус Ризак углының соңгы 60 елдан артык гомере Казан белән бәйле. 1958-1963 елларда – Казан университетының тарих-филология факультеты студенты. Алга таба ул шушы уку йортының аспиранты, укытучысы. 1979 елда тарих фәннәре докторы дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була. 1980-1995 елларда тарих факультетының деканы, 1983-2013 елларда Ватан тарихы кафедрасы мөдире. 30 елдан артык докторлык һәм кандидатлык диссертацияләре яклау советының рәисе. 10 ел буена (ягъни 2000 нче елның 29 августына кадәр) Бөтендөнья татар конгрессын җитәкләде.

И.Таһиров – күп санлы гыйльми басмалар, монография-җыентыклар авторы. Аларның шактые XX йөздәге ил тарихын, Октябрь инкыйлабын, милли революцион хәрәкәт тематикасын яктыртуга багышланган.

Миңа Индус әфәнде белән бер үк елларда диярлек университетта укырга, эшләргә туры килде. Очрашкалап, аралашып тордык. 1980 елда тарих-филология факультеты икегә аерылгач та, элемтәләр өзелмәде. Бер үк бинада янәшә генә катларда эшләдек. Шактый гына уртак чаралар да булып торды. Индус Таһиров мин белә белгәннән бирле бик тә актив, тырыш булды. Җәмәгать, укыту-тәрбия эшләренең үзәгендә кайнады. Татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен яхшы белде. Ул аеруча Мөхәммәт Мәһдиев, Мостафа Ногман, Нургали Булатов, Зөфәр Шәйхетдинов кебек укытучылар, студентлар белән дустанә мөнәсәбәтләрдә иде. Аның төрле мәҗлес-кичәләрдә оста сөйләве генә түгел, матур итеп җырлаулары да истә калган.

Фәнни яктан бик тә хәзерлекле, милли-азатлык тарихыннан яхшы хәбәрдар булган И.Таһиров илдәге үзгәртеп кору хәрәкәтенең, демократия өчен көрәшнең алгы сафында булды. Берничә мәртәбә Татарстан парламентына депутат итеп сайланды, җөмһүриятебезнең, халкыбызның хокуклары өчен фидакярләрчә эш-гамәлләр кылуның күркәм бер үрнәге иде. Шунысы мөһим: ул бу юнәлештәге эшчәнлеген хәзер дә дәвам итә. Аның матбугаттагы, радио-телевидениедәге төрле конференция-җыелышлардагы чыгышлары һәрчак зур кызыксыну белән кабул ителә.

Кулымда профессорның 2021 елда дөнья күргән "Воспоминания" китабы (К:-Логос-Пресс.-218 с.) Анда авторның шәхси тормышына, иҗтимагый рухи ышәешебезгә мөнәсәбәтле шактый гына фоторәсемнәр, документ-материаллар бар. Китап киң катлам укучылар да аңларлык үтемле тел белән язылган. Кызыклы, гыйбрәтле эпизодлар, фактмәгълүматлар дә күп.

Бездә хатирә-истәлекләр элек тә, хәзер дә шактый язылган. Бу жанрдагы әсәрләр укучыны аерым затларның тормыш-яшәешләре, холык-фигыльләре, уй-кичерешләре, тирә-юньгә, чынбарлыкка мөнәсәбәтләре белән таныштыра, төрле кешеләр, вакыйга-хәлләр белән очраштыра. Истәлекләрнең тәэсир көче, иң беренче, авторның шәхесенә, аның язу осталыгына бәйле.

Ә И.Таһиров – билгеле, кабатланмас зат. Бу факт үзе үк укучыны алдан ук кызгатып, кызыксындырып куя. Ул тәүге сәхифәләреннән үк күңелне биләп ала. Берничә фикер әйтү, гомуми күзәтү ясау белән генә чикләнәм.

Китапның тәүге бүлекләре авторның балалык, үсмер чорларын, мәктәптә уку елларын тасвирлауга багышланган. Биредә без булачак профессорның әти-әнисе, туган-тумачалары, классташлары белән очрашабыз.Тормыш юлындагы аерым вакыйга-хәлләргә тап булабыз. Алга таба университеттагы студентлык, аспирантлык, укытучылык еллары бәян ителә. Бер чорда, бер үк коллективта эшләгәч, автор язганнарының күбесе шәхсән минем өчен аеруча кызыклы. Шунысын да әйтим: Индус укыган студентлар төркеме бик тә көчле иде. Юкка гына алар арасыннан халкыбызның Рәмзи Вәлиев, Миркасыйм Госманов, Әзһәр Мөхәммәдиев кебек затлар чыкмагандыр! Автор алар һәм кайбер башка курсташлары хакында белешмә-аңлатмалар да биреп бара. Гомумән, бу принцип, ягъни бергә укыган, эшләгән, аралашкан затлар турында кыскача сыйфатламалар бирү аның бөтен китабы өчен хас.

Андый шәхесләр арасында И.Таһировның остазлары (И.М.Ионенко, Г.Н.Вульфсон...), хезмәттәшләре (С.И.Даишев, Н.А.Гуляев, А.М.Ахунҗанов, Х.Госман, А.И.Данилов, А.Литвин, Р.И.Нафиков, М.Х.Фарукшин...), дәүләт эшлеклеләре (Ф.Р.Газизуллин, М.Г.Сабиров, Г.Бурбулис...) һ.б. бар. Болардан ул Евгений Бусыгинны аеруча җылылык белән шактый тулы яктырта. Без фәкыйрегезгә дә бу күренекле этнографның чыгышларын, скрипкада гаять оста итеп уйнауларын берничә мәртәбә тыңлау насыйп булды. Шунысын да искәртик: "Хатирәләр" авторы үзгәләр хакында язганда аларны, гомумән, уңай яктан тасвирларга ярата, тәнкыйтьләгәндә дә кешеләрне рәнҗетмичә, такт белән генә үз мөнәсәбәтен белдерә.

И.Таһиров тормышының, иҗтимагый-сәяси эшчәнлегенең иң характерлы чоры, әлбәттә, XX йөзнең ахры – XXI гасырның тәүге еллары. Шуңа нисбәтән ул "Хатирәләр"дә дә төп урынны били. Автор – Татарстан суверенитеты өчен көрәш хәрәкәтен оештыручыларның һәм идеологларның берсе, Татарстан һәм Россия арасындагы рәсми сөйләшүләрнең даими әгъзасы. Күрер күзгә кечкенә генә гәүдәле бу зат бу еллардагы эш-гамәлләре белән көчле рухлы, алыптай батыр зат рәвешендә күзаллана. Китапта илебездәге ике гасыр аралыгындагы сәяси-иҗтимагый вәзгыять, Мәскәү һәм Казан Кремльләре арасындагы катлаулы, вакыты-вакыты белән бик тә киеренке мөнәсәбәтләр киң катлам укучыларны дулкынландырырлык, уйландырырлык төстә бәян ителә. Китапта бу драматик процессның үзәгендә кайнаган М.Шәймиев, Ф.Мөхәммәтшин кебек төп фигураларга шактый тулы характеристика бирелә.

Милли-демократик хәрәкәт дулкынында 1992 елда барлыкка килгән Бөтендөнья татар конгрессы турындагы бүлекләрдә бу оешманың татар халкын барлауда, туплауда һәм оештырудагы күп кырлы һәм игелекле эш-гамәлләре турыдан туры да, аерым шәхесләр эшчәнлеге аркылы да шактый җентекле яктыртыла.

Мәгълүм ки, соңгы дәвердә, бигрәк тә 2022 елда, һәм илдә, һәм халыкара масштабта иҗтимагый-сәяси, игътисади тормыш аеруча катлауланды. Милли мөнәсәбәтләрдә, милли-мәгариф өлкәсендә дә проблемалар җитәрлек. Аларны чишү, хәл итү тарихи тәҗрибәне белүне таләп итә. И.Таһиров китабында хәзерге чынбарлык ихтыяҗларга авазлаш яклар шактый. Аның белән очрашу укучының тарихи һәм сәяси офыкларын киңәйтәчәк, үткәннәрдән гыйбрәт алып, нәтиҗәле эш-гамәлләр кылырга булышачак.

И.Таһиров – бай һәм катлаулы тормыш юлын узган олуг шәхес. "Воспоминания" китабында авторның әле бер өлеш хатирә-истәлекләре уйланулары гына теркәлгән. Аны тагын да тулыландырып, камилләштереп, үзебезнең газиз татар телендә дә бастырырга иде.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы.

Хыялга юл кайдан башлана?!

Актаныш – бик күп әдәбият-сәнгать талантларын үстергән район. Бүген әдәбият мәйданында каләм белән яңадан-яңа үрләр яулаучы якташ әдипләребез, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге ияләре: Гамил Афзал, Лена Шагыйрьҗан, Вахит Имамов, Илфак Ибраһимов, Ләбиб Лерон кебек шәхесләребезне бөтен татар дөньясы таный. Алар артыннан килгән буын язучылары Айгөл Әхмәтгалиева, Ленар Шәех, Эльмира һәм Гөлнара Җәлилова, Лилия Гыйбадуллина, Фидаил Мәҗитов яңадан-яңа уңышлары белән сөендереп тора. Иске Теләкәй авылында туып үскән, Казан технология университетын тәмамлаган, бүген «Шәһри Чаллы» газетасында хезмәт куючы Айзирә Имамова (Бадикова) да үзенең өметле каләме белән әдәбият мәйданына юл сала. Шушы көннәрдә Айзирәнең Татарстан китап нәшриятында «Хыялыма таба барам» атлы китабы басылып чыкты.

Китапка «Таң нурында яңа шигырь туа» дип исемләнгән кереш сүзне күренекле шагыйрәбез Лилия Гыйбадуллина язган. Ул Айзирәне өметле каләм иясе буларак бәяли: «Иң мөһиме – гамьле, уйлы шәхес ул. Шигырьләрендәге гадилек белән кызыклы уй-фикерләр, төсле җанлы чагыштыруларның янәшәлеге игътибарны җәлеп итә. Күңел күзен үзенә тартып торган нечкә тоемлау, тансык ятылык бар аларда. Ихласлылык бар! Әлеге җыентыкта тәкъдим ителгән әсәрләре – Айзирәнең зур шигърият дөньяга ихлас, ышанычлы тәүге адымнары».

Әйе, Айзирәнең шигъри каләменнән тамган әсәрләре күңелдә өмет уята. Үзенә генә хас табышлары киләчәктә арабызда тагын бер талант иясенең киң мәйданда урын алачагына ышандыра. Башкача була да алмыйдыр. Актанышта туганнарның җанында шигырь уты кабынса, ул сүнмәячәк. Тумыштан бирелгән сәләт өстенә үҗәтлек, тырышлык та хас аларга. Яшь шагыйрә шундыйлардан.

Яшь кенә булуына карамастан, ул инде яшәү мәгънәсен төшенгән. Тормыш авырлыклары булганда да бирешми яшәргә тиешлеген белә.

...Яшәү мәгънәсен мин сабыемның
Нәни кулларында табармын,

– дип үзенә сүз биргән Айзирәнең күңел тәрәзәсен инде хәзер дөнья гаме шакый. Ул гамь аны сискәндерә, уйландыра, дөнья белән үз телендә сөйләшә башлый:

Җир дөньясы шундый тере,
әйтерсең лә
Туганнарның Сабантуйда гөрләшүе.
Ток тоттымы, дисәм, –
кызыл кырмысканың
«Үз мәйданы» өчен икән көрәшүе.
Бер мизгелдә дөнья тып-тын кала менә.
Болытлар да эленгәндәй элмәгенә.
Күз дә алмый куккә карап ятам әле –
Дөнья белән сөйләшүем үз телемдә.

Хатын-кыз ана булганнан соң өр-яңадан яши башлый. Айзирәбез дә - ике бала анасы. Күңелендә гаиләсе, балалары өчен җаваплылык йөрткән Айзирәнең җанында ярату яши, ул аны кешеләргә өләшә. Җаннары яргаланганнарның күңелен ярату белән дәвалый һәм үзе дә дәвалана.

...Синең бераз җаның
яргаланган,
Ярчыклары минә түгелә.
Ямау балчык алып
Ябыштырдым
Синең күңелгә.
«Сине көттем», –
Дип әйтмәдем.
Үзең сизеп
Алып киттең.
Яклау тойдым,
Җаным телми,
Саклау тойдым.

Яклау һәм саклау тоеп яшәгәндә, күңелдә ышаныч туа. Айзирә Имамова ышаныч белән яши.

Дөрес түгел, бар да ялган,
Утырамын карап ярдан.
Мең әйтсә дә әни алдан,
Туры карап нигә барам?
...Дөрес түгел, бар да ялган,
Кычыткannar чага яман.
Ансы дөрес!
Тик дөньяга да ышанасы килә һаман.
Һаман, һаман!

Дөньяга, кешеләргә ышанып яшәгәндә генә бәхеткә юл табыла. Бәхетле иҗат юлы сиңа, Айзирә!

Әлфия СИТДЫЙКОВА.

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

7 октябрь – Татарстанның халык артисты Фирая Әкбәрованың юбилей кичәсе.
8 октябрь – «Сагынырсызмы?» (А.Шәйдуллин).
9 октябрь – Зур залда – театр оркестры концерты. Кече залда – «Томан» (Г.Сәгыйтова).
10 октябрь – 13.00, 19.00 – «Мәхәббәт FM» (И.Зәйниев).
11 октябрь – Шәрык клубы бинасында – «Искән җилләр көенә» спектаклен экран аша күрсәтү (З.Хәким).
13 октябрь – «Бию пәрие» (И.Зәйниев).
14 октябрь – «Миркәй белән Айсылу» (Н.Исәнбәт).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

8, 9 октябрь – «Коппелия» (Л.Делиб).
12, 13 октябрь – «Набукко» (Дж.Верди).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

7 октябрь – 18.30 – «Беренче театр» (Г.Камал). 19.00 – «Кияү урлау» (С.Юзеев әсәре, Х.Ибраһим инсценировкасы).
8 октябрь – «Мәдинә» (И.Зәйниев).
9 октябрь – «Өч аршын җир» (А.Гыйләҗев).
11 октябрь – «Туй алдыннан» (Х.Вахит).
12 октябрь – «Шах...Мат!» (Л.Сәләхетдинова).
13 октябрь – «Акча биздә бер букча» (З.Хәким).
14 октябрь – «Хан кызы Турандык» (К.Гоцци әсәре буенча).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

7 октябрь – «Корт» (Ф.Галиев).
8 октябрь – 13.00 – «Минем бәхетле көнем» (Е.Гороховская). 18.00 – «Алтынч[ае]ч» (Л.Янсуар, Р.Гарипова).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

7 октябрь – 11.00 – «Принцесса Крапинка» (А.Шмидт). 15.30 – Театр буенча сәяхәт. 19.00 – «Әлдермештән Әлмәндәр» (Т.Миңнуллин).
8 октябрь – 11.00, 13.00, 15.00 – «Русалочка» (Г.-Х.Андерсен).
9 октябрь – Фойеда – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). Зур залда – «Теремок» (С.Маршак). Кече залда – «Сертотмас үрдәк» (А.Алиш).
13 октябрь – «Су анасы» (Г.Тукай).
14 октябрь – 11.00, 13.00 – «Кәҗә белән Сарык» (Г.Тукай). 15.30 – Театр буенча сәяхәт.

Г.ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕНЕҢ КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

7, 9 октябрь – «Лебединое озеро» балеты (П.Чайковский).
8 октябрь – «Спящая красавица» балеты (П.Чайковский).
13 октябрь – Татарстан Республикасы халык музыка уен кораллары дәүләт оркестры һәм Е.Южинның «Магомаев, Мартынов, Ободзинский» дип исемләнгән концерты.

С.СӘЙДӘШЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ЗУР КОНЦЕРТ ЗАЛЫ

7 октябрь – Кыллы музыка уен кораллары квартеты башкаруында хәзерге заман композиторлары музыкасы концерты.
8 октябрь – А.Сладковский җитәкчелегендәге дәүләт симфоник оркестрның «Бетховен-тур» дип исемләнгән концерты.
9 октябрь – 11.00, 13.00 – Балалар өчен «Lego music» дип исемләнгән музыкаль интерактив уен. 17.00 – Татарстанның атказанган артисты, орган остасы Лада Лабзинаның юбилей кичәсе.
12 октябрь – ILUGDIN TRIO башкаруында джаз концерты.
13 октябрь – Виолончель остасы А.Князев композитор И.С.Бахның сюиталарын уйный.

Айга карап

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

8 октябрь (шимбә). ***Рабигүл әүвәл аенын 12 нче көне. 14 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында,16.59 сәгатьтә калка, 4.54 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.02 сәгать.***

Иң әһәмиятле эшкә тотыну өчен уңайлы көн. Бүген башланган эш бик яхшы тәмамланачак. Теләсә нинди вак-төяккә игътибарлы булу сорала. Эчәклек һәм тирене чистарту уңай нәтиҗә бирә. Ашказаны асты бизе зәгыйфь. Балан, фасоль, борчак, арпа ашау файдалы.

Сөялдән – миләш

Пешкән кызыл миләшне бераз изеп, сөялгә куялар, өстеннән пластырь ябыштыралар. 3-4 тапкыр шулай миләш япканнан соң, сөял бетә. Кышын исә кипкән миләшне кайнар суда җебетеп ябарга була.

9 октябрь (якшәмбе). ***Рабигүл әүвәл аенын 13 нче көне. 15 нче Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 17.07 сәгатьтә калка, 6.20 сәгатьтә бата. 23 сәгать 54 минуттан тулы Ай. Көн озынлыгы 10. 57 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Тыелгысыз хисләр күңелсез вакыйгага китерергә мөмкин. Тәэсирләнүчән кешегә аеруча кыен. Балан, мүк җиләге ашау файдалы.

Начар холестеринны киметү

Организмдагы начар холестеринны киметү өчен, махсус диета тотарга кирәк: майлы ит һәм сыр, атланмай, майлы эремчек һәм сөтне, тавык йомыркасының сарысын чамалап кына куллану зарур. Көненә 3-4 тапкыр 5 әр кызыл миләш ашау файдалы. 4 көн рәттән миләш белән сыйланганнан соң, 10 көн ял итәләр. Аннан соң дәва курсын тагын ике тапкыр кабатлыйлар. Фасоль яки борчак ашау да файдалы.

10 октябрь (дүшәмбе). ***Рабигүл әүвәл аенын 14 нче көне. 16 нчы Ай тәүлеге. Ай Кучкар йолдызлыгында, 17.15 сәгатьтә калка, 7.46 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.53 сәгать.***

Тыныч, иҗади, уңышлы көн. Һәрнәрсәдә гармониягә омтылу, җан тынычлыгын саклау мөһим. Килешүләр төзү уңай нәтиҗә бирә. Кан авырулары кискенләшә. Беркемгә дә үпкә сакларга ярамый.

Ангинадан – прополис

Ангинадан иң шәп дәва чарасы – яңак белән аңкау арасына төнгелеккә прополис кисәге кыстырып яту. Прополис югары сыйфатлы булып, телне беразга гына оетырга тиеш. Ангина вакытында ашаганнан соң прополис чәйнәү дә булыша, көненә 5 г китә. 2 көндә ангина үтә.

11 октябрь (сишәмбе). ***Рабигүл әүвәл аенын 15 нче көне. 17 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 17.24 сәгатьтә калка, 9.11 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.48 сәгать.***

Мәхәббәт, иҗат, яшәү шатлыгы көне. Бернәрсә дә планлаштырмыйча, теләгән нәрсәне генә эшләү яхшы. Күзгә игъти-

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карап кырын карама

барлырак булу сорала. Үпкәләшкән кешеләр белән дуслашыр вакыт. Яшелчәләрне күбрәк ашау файдалы.

Чөгендер куасы

Бөердәге һәм үт куыгындагы ташлардан кызыл чөгендер куасы коткара ала. 3-4 чөгендернең кабыгын әрчеп, юка телемнәргә турыйлар, 3 литрлы банкага 3 бармак калынлыгында тутыралар. Кайнатып суытылган су яки салкын чишмә суы салып, өстен марля белән бәйлиләр. Көнаралаш агач кашык белән болгаталар. 7-8 көннән куас әзер була, сөзеп, суыткычта саклыйлар. Эчәсе килгән саен алып эчәләр (бераз җылытып). 5-6 ай буе эчсәң, ташлар әкренләп эреп, авыртусыз чыгып бетә, тик болай дәвалана башлаганчы, һичшиксез табиб белән киңәшү зарур. Гипертоникларның кан басымы түбәнәя, эч тә кипми.

12 октябрь (чәршәмбе). ***Рабигуль әүвәл аеның 16 нчы көне. 18 нче Ай тәүлеге. Ай Үгезбозау йолдызлыгында, 17.35 сәгатьтә калка, 10.36 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.44 сәгать.***

Алдашу, ялганга бай көн. Бизләр системасы, бил, бөер, тире, сукыр эчәк зәгыйфь. Мунчага бару, массаж ясату, ач тору файдалы. Кәеф төшәргә мөмкин.

Салкын тисә

Суык тиюдән 1 көндә котылып була. 1 аш кашыгы вакланган бөтнекне 1 стакан кайнар суга салып, сүрән утта 5 минут пешерәләр, суытып, сөзәләр. Шуңа 1 чәй кашыгы бал, чирек лимон согы һәм издерелгән 1 бүлем сарымсак кушып болгаталар да, җылы килеш йоклар алдыннан эчеп бетерәләр, яхшылап тәренеп яталар.

13 октябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигуль әүвәл аеның 17 нче көне. 19 нчы Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 17.51 сәгатьтә калка, 11.56 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.39 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн. Күп аралашмаска, күз тиюдән, чит тәэсирләрдән сакланырга кирәк. Бурычка алырга да, бирергә дә ярамый. Нерв системасы, эчәклек, арканың өске өлеше зәгыйфь.

Аритмиядән – өрек төше

Йөрәк ритмы бозылганда, ярты килограмм лимонны кыргычта кырып, шулкадәр үк бал һәм 20 өрекнең төелгән төшен кушалар. Көненә 2 тапкыр, ашар алдыннан, 1 әр аш кашыгы кабалар.

14 октябрь (җомга). ***Рабигуль әүвәл аеның 18 нче көне. 20 нче Ай тәүлеге. Ай Игезәкләр йолдызлыгында, 18.15 сәгатьтә калка, 13.07 сәгатьтә бата. 3 нче фаза. Көн озынлыгы 10.35 сәгать.***

Үз-үзеңне танып белү, уйлану, кичерү көне. Өйдә булырга тырышырга, гаиләгә игътибарны арттырырга кирәк. Тәкәбберлек күрсәтергә ярамый. Яңа белем җиңел үзләштерелә. Нерв белем җиңел... Нерв системасы, сизү әгъзалары, кан тамырлары, ашказаны зәгыйфь. Ит ашауны чикләү хәерле.

Кетчуп

3 кг кып-кызыл помидорны иттарткычтан чыгарып, 150 г чистартылган көнбагыш мае кушалар һәм 1 сәгать 45 минут томалап пешерәләр. Аннан соң 2 шәр аш кашыгы тоз һәм шикәр өстәп, тагын 10 минут кайнаталар. Издерелгән 3 бүлем сарымсак, 1 аш кашыгы ачы кызыл борыч кушып, тагын кайнатып чыгаралар. Стериль банкаларга кайнар килеш бүлеп, тимер капкач белән ябалар.

Кәгъбәне Аллаһ саклый

Аллаһ Тәгаләнең әмере белән корылган Кәгъбә һәрвакыт илаһи яклау-саклау астында булыр. Тарихта «Фил вакыйгасы» буларак билгеле очрак – моны ачык күрсәткән гыйбрәтле мисаллардан берседер.

Йәмән идарәчесе Әбрәһә Рим императорының ярдәме белән Санада чиркәү төзетә, тик бу гыйбадәтханәгә үзе теләгәнчә игътибар күрсәтелмәгәнен күргәч, Әбрәһәнең бик нык ачуы кабара. Шуннан соң гарәпләр электән үк изгелеген танып, зиярәт кылган Кәгъбәне җимерергә карар бирә. Хәзерге заманның танкларына тиң филләре дә булган гаскәр әзерләп, Мәккәгә юнәлә. Шул рәвешле ул, янәсе, кешеләрне үзе төзеткән чиркәүгә каратачак.

Әбрәһәнең күзе шулкадәр тонган була ки, талап алынган дөяләрен кире сорап килгән Габделмотталибкә: «Мин Кәгъбәне җимерергә килдем, ә син дөяләрең турында уйлап йөрисең!» – дип бакыра.

Габделмотталибнең Кәгъбә турында: «Аның хуҗасы бар! Ул аны саклаячак!» – дигән сүзләренә каршы, кызып: «Аны миннән саклап калачак һичкем юк!» – дип, юләрләнүен дәвам итә. Әбрәһә Мәккәгә якынлашкан гаскәргә Кәгъбәгә һөҗүм итәргә әмер бирә. Ләкин Мина белән Мүздәлифә арасындагы Мухассир үзәнлегенә килгәч, филләр шып туктап, йөри алмас хәлгә килә. Күк йөзе тау карлыгачлары белән тула. Алар яндырылган балчыктан ясалган ташларны аякларына эләктереп алып килеп, аларны Әбрәһә гаскәре өстенә чәчә башлый. Бу ташлар кемгә эләксә, шуны һәлак итә. Мәккә алды бер мизгелдә кешеләр һәм филләр каберлегенә әйләнә. Бу дәһшәтле илаһи могҗиза булган елны «Фил елы» дип атыйлар.

Аллаһ Тәгалә әлеге вакыйганы Коръәни-Кәримдә түбәндәгечә бәян итә: «Раббыңның фил иясләренә ниләр кылганын күрмәдеңме? Аларның әшәке ниятләрен юкка чыгармадымы? Өсләренә өер-өер кошлар җибәрде. Бу кошлар аларга янган балчыктан ташлар аталар иде. Ниһаять, аларны ашалган-чәйнәлгән иген саламына әйләндерде» («Әл-Фил», 1-5).

Чөнки Кәгъбә Җәнабел-Хакның илаһи әмере белән төзелгән «Ханәи Бирр» булып тора. Ул җир Аллаһка коллык урыны буларак изге һәм мөбарәк кылына. Шуңа күрә Аллаһ тарафыннан саклана.

Әбрәһәнең гыйбадәтханәгә карата хөрмәтсезлек күрсәтүенә бирелгән җәза исә кыяматкәчә шул рәвешле кылынырга мөмкин башка гамәлләр өчен куркытып тору сыйфатына ия.

Башка бер аяти-кәримәдә болай диелә: «Аллаһның мәсҗидләрендә Аның исеме зикер ителүенә каршы булган һәм аларны харап итәргә тырышканнардан да залимрак кем булыр? Аларның мәсҗидләргә бары курка-курка гына керүләре тиеш. (Башкача керергә хаклары юк.) Алар өчен дөньяда хурлык, һәм янә алар өчен ахирәттә бик зур газап бар» («Әл-Бәкара», 114).

Золымын шактый көчәйткән Әбрәһә нәтиҗәдә үзендә чиксез көч-куәт һәм бөеклек бар дип уйлап бутала. Моңа каршы Аллаһ Тәгалә аны чүлләрдәге арыслан, каплан яки агулы елан кебек дәһшәтле, куркыныч мәхлуклар белән түгел, ә бик көчсез һәм зәгыйфь тау карлыгачы ташлаган, ногыт борчагыннан да ваграк ташлар белән һәлак итте. Шулай итеп, Аллаһ Тәгалә, Фиргавен, Нәмрут һәм Җалут кебек тәкәбберләрне алардан кечкенә һәм көчсез күренгән мәхлуклар тарафыннан һәлак иттерел, бу затларның чынлыкта никадәр мескен, зәгыйфь җан ияләре икәнлекләрен һәм горурлыкларының мәгънәсезлеген ачып сала.

Әбрәһә дә, бик зур бөеклек тоеп, тәкәбберлек белән чыккан явыннан Йәмәнгә, бик түбәнлеккә төшерелгән һәм мескен кыяфәттә, телем-телем вакланган гәүдәсен сөйри-сөйри генә кайтып егыла. Аның бу хәле тәкәбберләрнең хәтта дөньяда вакытта ук хурлыкка төшерелүенә бик ачык гыйбрәт булып тора.

Пәйгамбәр Әфәндебезнең исемнәре

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең күп кенә мөбарәк исеме бар. Боларның иң беренчеләре – Коръәни-Кәримдә телгә алынган «Мөхәммәд» һәм «Әхмәд». «Мөхәммәд» күп итеп макталган, «Әхмәд» исә күп итеп хәмд әйткән дигәнне белдерә.

Коръәни-Кәримдә Мөхәммәд исеме дүрт тапкыр, Әхмәд исеме бер тапкыр искә алына. Инҗилдә бу исемнәр белән бер үк мәгънәне белдергән «Фараклит» сүзе кулланылган.

Пәйгамбәр Әфәндебез галәйһис-саләтү вәссәләм бер хәдис-шәрифендә болай дигән: «Мин Мөхәммәд һәм Әхмәд. Мин ул Маһи (юк итүче) ки, Аллаһ минем нәбилегем белән кәферлекне бетерәчәк. Мин ул Хәшир (туплаучы) ки, (кыямәт көнендә) кешеләр миңа ияреп җыелачак. Мин Гакиб (арттан баручы), Хәтемүл-Әнбия (ахыр пәйгамбәр), миннән соң һичкем нәби булмаячак» (Бохари, «Мәнакиб», 17; Мөслим, «Фәдаил», 125)

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең мөбарәк исем һәм сыйфатлары берничә хезмәттә телгә алына. Мәсәлән, «Дәлаили Хайрат» исемле хезмәттә ике йөзгә кадәр исем аңлатыла. Бүген Пәйгамбәрләр бакчасының кыйбла ягы диварын нәфис һәм матур рәвештә бизәгән әлеге мөбарәк исем һәм сыйфатларның кайберләре мондый: Әхмәд, Мәхмүд, Мөхәммәд, Хәмид, Бәшир, Нәзир, Борһан, Әмин, Әүвәл, Ахир, Духа, Хәбибуллаһ, Һади, Хәтем, Мохтар, Мостафа, Мотаһһар, Мөҗтәба, Нәби, Нур, Рәүф, Рәхим, Рәсүлуллаһ, Рәсүл әс-Сәкаләйн, Рәхмәтән ли әл-Галәмин, Сәййидүл-Мүрсәлин, Сәййидүл-Кәвнәйн, Имам әл-Хәрәмәйн, Имам әл-Мүттакыйн, Шәфиүл-Мүзнибүн, Шәмс, Та-һә, Өмми, Йә-син...

Көтүчелек серләре

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм, агасы Әбү Талиб исән чагында, сәүдә эшенә керешкәнче, күпмедер вакыт көтүчелек белән шөгыльләнә. Бу һөнәр гарәпләр арасында гади, түбән нәрсә түгел, ә хөрмәтле һәм бай кешеләрнең балалары да башкара торган эш була. Әстәвенә бөтен пәйгамбәрләр дә көтүчелек белән көн күргән. Шул рәвешле Аллаһ Тәгалә аларда, дингә өндәү вазифасын йөкләгәнче, идарә эшендә кирәкле төрле сыйфатларны булдыра.

Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм бер көнне: «Аллаһ Тәгалә җибәргән һәр пәйгамбәр, һичшиксез, көтү көткән», – дип белдерә.

Моңа каршы сәхабәләре: «Сез дә сарык көтеп йөрдегезме, йә Рәсүлуллаһ?» – дип сорый.

Галәмнәр сәрвәре галәйһис-саләтү вәссәләм Әфәндебез: «Әйе, түләү бәрабәренә мәккәлеләрнең сарык көтүләрен көттем», – дип хәбәр итә. (Бохари, «Иҗарә», 2, «Әнбия», 29; Ибне Мәҗә, «Тиҗарәт», 5)

Башка бер хәдис-шәрифтә Пәйгамбәребез болай дип сөйли: «Муса галәйһиссәлам пәйгамбәр итеп җибәрелгән иде, үзе сарык көтүе көтә иде. Давыт галәйһиссәлам пәйгамбәр итеп җибәрелгән иде, ул да сарык көтүе көтә иде. Мин дә пәйгамбәр итеп җибәрелдем һәм Әҗьядта гаиләмнең сарыкларын көтеп йөрдем». (Ибне Сәгъд, I, 126)

Пәйгамбәргә ул вакытларда егерме яшьләр була. «Иң хәерле яшәеш юлыннан баручыларның берсе – бер тау башында яки үзәнлектә сарыкларын ашатып йөрүче. Бу зат намазын укыр, зәкятен бирер, үлгәнче Раббысына гыйбадәт кылыр һәм кешеләргә яхшылык эшләр», (Мөслим «Имарәт», 125; Ибне Мәҗә, «Фитән», 13) – дип, Рәсүлуллаһ көтүчелекнең күркәм һөнәрләрдән берсе булганлыгын белдерә.

Көтүчелек белән шөгыльләнгән кешеләрдә фикер киңлеге, сабырлык һәм мәрхәмәт хисе үсә. Аллаһ Рәсүле шуңа ишарә итеп болай дигән: «Җитдилек һәм вәкарь – сарык асраучыларда». (Бохари, «Мәнакиб», 1; Мөслим, «Иман», 84/52)

Сарыкларны күчереп йөртеп һәм җитәкләп ерткыч хайваннардан сакларга тырышу кешедә сабырлык һәм сакчыллык хисен үстерер. Чөнки яратылган һәр мәхлукка мәрхәмәт күрсәтү, аларның тупас һәм аңлаешсыз хәл-гамәлләренә сабыр итү – пәйгамбәрләрдә булырга тиешле иң мөһим сыйфатлардан.

Урмандагы Саба галиме

● Азат Әхмәдуллин, Җәүдәт Фәйзи, Ләбиб Айтуганов.

Һәр төбәк, иң элек, үзенең данлыклы, игелекле шәхесләре белән ат казана. Азат Гыйльмулла улы Әхмәдуллин да Сабаның абруен күтәрүгә үзеннән лаеклы өлеш кертеп яшәде. Ни кызганыч, туксанынчы яшенә чыккач, бакыйлыкка күчте. 13 октябрьдә аңа 90 яшь тулган булыр иде.

Кешенең озын гомере кендек каны тамган урыннан башлана. Азат өчен мондый кадерле җир, әлбәттә, Байлар Сабасы авылы. Әтисе – район советы башкарма комитеты сәркәтибе. Бер үк вакытта каләмле зат. Шуңа күрә аны район газетасына мөхәррир итеп тәгаенлиләр. Бу эш аңа гомере буена диярлек ябышып кала. Кызыл Армия, Кукмара, Тархан районнарына күчә-күчә, ул шушы хезмәтне башкара. Бу – сугыш алды еллары. Сәяси эзәрлекләүләрнең кискенләшкән вакыты да. Азатның әтисен дә, Кукмарада эшләгәндә, берничә ай рәшәткә артында тотып чыгаралар.

Шунысы мөһим, әтисенең матбугат мәйданында булуы кечкенәдән үк Азатның басма сүзгә, китапларга булган кызыксынуын барлыкка китерә. Олы Тархан, Саба мәктәпләрендә укыганда китапка тартылу көчәя. Мәктәптәгеләрне генә түгел, китапларның әтисе эшли торган редакциядәгеләрен дә укып барырга өлгерә. Әлбәттә, мондый бала мәктәп программаларын да җиңел үзләштерә. Азат та укуда әйбәт өлгереш күрсәтә. Шуны күреп, аны җәмәгать эшләренә җәлеп итәләр. Яшүсмерлек вакытында аңа колхоз атларын көтү, элеваторга ашлык ташу, ашлык суктыру эшләрендә катнашырга туры килә. Гармунда, курайда уйнарга өйрәнә. Концертларда, спектакльләрдә катнаша. Әтисе генә түгел, әнисе Дилшатбану апа да аның бу мавыгуларына шатлана. Аңа кечкенә аккордеон сатып алып бирәләр. Мондый уен коралы бөтен Сабасына бер генә була. Ә Азатның шушы могҗизада уйнавы яшьләрне аеруча кызыксындыра. Уналты яшендә аны комсомолның район комитетына әгъза итеп сайлыйлар. Сабада оешкан тынлы оркестрда аңа трубада уйнауны үзләштерергә кушалар. Аңа танылган җырчы Рокыя Кушловская җитәкчелегендәге драма түгәрәгендә М.Фәйзинең «Ак калфак» әсәре буенча куелган спектакльдә мәхәббәт каһарманы ролен башкару да насыйп була. Аттестат алгач, Шекше мәктәбенә математика-физика укытучысы итеп җибәрүләре дә аның шушы яшьтә үк җитди эшләрне ышанып тапшырырлык егет булып җитлегеп килүен раслый.

Ниһаять, 19 яшьлек егет 1951 елда Казан университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты була. Азат стипендия өстенә, уку йортындагы оркестрда трубада уйнап, беraз акча да эшләштергәли. Тулай торакта да, авылларга ярдәм итешергә баргач та кулында гармуны була, үзедәй яшьләр чараларының үзәгендә кайный. Әмма төп шөгыле уку икәнен онытмый. Биш ел буе югары стипендия алып укый, 4 нче курста Г.Тукай стипендиясенә лаек була. Өченче курста мәкаләләрен матбугатка да тәкъдим итә башлый. Булачак язучы Х.Хәйруллин белән берлектә язылган бер мәкаләсе хәтта «Совет әдәбияты» журналы битләренә менә (1953, № 9). Әдәби тәрҗемә мәсьәләләренә караган әлеге тикшеренүгә М.Әмир дә уңай бәя бирә. Соңгы курста И.Нуруллин җитәкчелегендә «Ф.Әмирхан иҗатында реализм мәсьәләләре» дигән диплом эше яза. Анда әдибебезне «буржуаз милләтче язучы» дип тамгалаудан арындырырга кирәк дигән фикер үткәрелә. Азатның болай раславы кафедра мөдире Х.Госман тарафыннан да яклау таба. Ул үзе белән бер елларда укучы М.Хәсәнов, Р.Нәфыйгов, М.Зәкиев, Х. Курбатов, Н.Юзиев, Ф.Хатыйповлар белән фикердәшләр булып китә.

1956 елда КДУдагы татар бүлегенең пединститутка күчерелү ихтималы бар дигән хәбәр таралә. Бер төркем студентлар, болай эшләргә ярамавын дәлилләп, ил җитәкчелегенә күмәк хат яза. Алар арасында Азат та була. Аны инде эшкә китап нәшриятына урнаштырган булалар. Шуның өстенә аспирантурага керү хыялы да яши. Ләкин, бу «ярамаган» эше өчен, аңа карата тискәре караулары беленә. Аңа хәтта Казаннан ук китеп торырга киңәш итәләр. Ул, үзе теләп, Себергә – Тубыл пединститутына эшкә китә. Андагы кафедра мөдире Габделхәй Әхатов аны эш белән күмә, егет әдәбият тарихын да, укыту методикасын да алып барырга тиеш була. Ул өметне аклый, укытуын яраталар. Бер елдан соң өлкән укытучы итеп билгелиләр. Биредә дә, драмтүгәрәк оештырып, К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл» әсәрен сәхнәләштерүгә җитәкчелек итә. Үзе Булат ролен башкара. Ул вакытта шунда ук эшләгән Гомәр Саттаров исә Җиһанша ролендә була. Аннан соң Азат тагын да зуррак эшкә алына – шәһәр күләмендә җыр һәм бию ансамбле оештыра.

1957 елда Тубылда татар телендә газета басу мәсьәләсен дә әлеге кафедра әгъзалары күтәреп чыга. А. Әхмәдуллинны укытучылыгына өстәмә рәвештә әлеге басманың җаваплы сәркәтибе итеп билгелиләр. Аннан бу эшне Ф.Хатыйпов үз өстенә ала. Ни өчен дигәндә, Казан кызы Фираяга өйләнгән Азат туган якларга кайтырга ашкына. Себердә йөреп «акылга утырган» А.Әхмәдуллинны Казанның Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирант итеп алалар. Фәнни җитәкче итеп атаклы профессор Мөхәммәт Гайнуллинны билгелиләр. Тикшерү темасы итеп теге елларда гомере чикләнгән, хәзер генә гаепсез булган, дип аклаган Фәтхи Бурнаш иҗатын өйрәнүне алалар. Язучының энесе Вафа Бурнашев аңа күп кенә материаллар белән ярдәмгә килә. Тагын кирәкләрен Казан, Мәскәү, Ленинград архивларыннан эзләп таба. 1964 елда кандидатлык диссертациясе язылып бетә. А. Әхмәдуллинга филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирелә. Әлеге хезмәтне аерым китап итеп чыгарырга тәкъдим итәләр. «Фәтхи Бурнаш әдәбият һәм сәнгать турында» дигән китабы (1980) әдәбият тарихын һәм татар эстетик фикерен өйрәнүдә мөһим чыганак санала. Татарстан радиосында сәнгати тапшырулар редакциясенең баш редакторы булып эшләү дә аңа зур тәҗрибә бирә, ул инде театр, музыка сәнгате кебек тармакларда да үз карашлары булдыра. Композиторлар Җ.Фәйзи, И.Шәмсетдинов, Ф.Әхмәтов, Л.Айтуганов белән берлектә күп кенә тапшырулар эшләнә. Г.Камал, Г.Коләхмәтов, К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, Н.Исәнбәт, Р.Ишморат, Х.Вахит һ.б. әсәрләре буенча радиоспектакльләр әзерләнә. Нәкъ ул эшләгән вакытта А. Ключаревның «Туган җирем – Татарстан» әсәреннән бер музыкаль фраза Татарстан радиосының «позывное» булып кулланыла башлый.

Шулай да, А.Әхмәдуллин үз урынын фән даирәсендә таба. Аны Г. Ибраһимов исемендәге Институтның гыйльми сәркәтибе вазифасына тәкъдим итәләр. Биредә ул институтның башка җитәкчеләре белән берлектә фәнни тикшеренүләрне оештыруда, аларның нәтиҗәләрен китап хәлендә чыгаруда, оешманың матди ягын үстерүдә колачлы эш алып баручыларның берсе була. «Татар әдәбияты тарихы», «Әдәбият баскычлары», «Татар совет театры» һ. б. китапларны язуны башлап җибәрүдә, бастыруга аның да хезмәте керә. Татар әдәбияты классикларының күптомлыкларын дөньяга чыгару эше җайга салына.

Аны 1981 елда КДУга татар әдәбияты кафедрасы мөдире итеп күчерәләр. Чөнки Х.Госман ялга киткәч, биредә шактый катлаулыклар килеп чыга, эш йомшара, галим-голәмәгә карата мөнәсәбәтләрдә ялгышлыклар җибәрелә. Эшлекле, гадел, башкалар белән уртак тел таба белгән А.Әхмәдуллин биредә дә коллективны уртак бурычларны хәл итүгә туплауда әйбәт нәтиҗәләргә ирешә. Иң әүвәл, ул үзе 1988 елда Алма-Атадагы гыйльми советта докторлык диссертациясен уңышлы яклый. Тора-бара КДУның үзендә шундый диссертация яклау советы төзелә.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы буларак та, ул җаваплы хезмәтләр башкарды: идарә әгъзасы, Г.Тукай премиясен бирү буенча комитет әгъзасы, әдәби фондның Татарстан бүлеге рәисе. Корылтайларда ясаган докладлары киң колачлы һәм фәнни нигезле булуы белән хәтердә калды. 1994 елда Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир әгъзасы итеп сайлануы да аның фәнни табышларына бирелгән зур бәя иде.

А.Әхмәдуллинның фәнни эшчәнлеге берничә юнәлештә барды. Иң әүвәл ул, әлбәттә, драматургия буенча белгеч. Ф.Бурнаш иҗатын өйрәнүдән башланган кызыксыну аны зур күзәтүләргә алып керде. Мәгърифәтчелек чоры драматургиясе турындагы хезмәтләре әдәбият фәне өчен бер ачыш булды. М. Әл-Казаныйның, Ф.Халидинең кайбер әсәрләре аның хезмәтләре ярдәмендә фәнни әйләнешкә керде. Соңгырак чор авторлары Г.Ниязбаевның «Беренче таң», Ф.Бурнашның «Язмыш», К.Тинчуринның «Ач гашыйк», Н.Исәнбәтнең «Портфель» әсәрләре турында да шуны ук әйтергә кирәк. Бу эшләрдә шәкерте Назим Ханзафаров та актив катнашты.

А.Әхмәдуллин матур әдәбиятның гомуми мәсьәләләре белән дә даими шөгыльләнде. Әдәбиятның методологик мәсьәләләре белән кызыксынды. «Татар әдәбияты тарихын өйрәнүнең актуаль мәсьәләләре», «Татар драматургиясе тарихын яңача өйрәнү» кебек мәкаләләрендә, дәреслекләрдә галим сүз сәнгатен хәзерге идея-эстетик таләпләр югарылыгыннан торып бәяләү үлчәмнәренә күп кенә фикерләр өстәде. Боларга тагын «Гареб-Шәрекъ контекстында татар әдәбияты тарихы» дигән мәкаләсен дә өстәргә кирәк.

Аның эшчәнлегенең тагын бер мөһим тармагы – мәктәпләр өчен дәреслекләр, уку әсбаплары язу, шул юнәлештә эшләүче галимнәргә һәм методистларга җитәкчелек итү булды. Башта ул, Х.Госман, Г.Халит, Г.Кашшаф, Х.Хәйри, А.Сайгановлар белән эшләп, бу өлкәдә бер мәктәп үтте. Үзгәртеп кору елларында исә аңа бу тармакка җитәкчелек итәргә туры килде. М.Хәсәнов, И.Нуруллин, Н.Юзиев, Т.Галиуллин, Ф.Галимуллин, М.Җәләлиева, Ф.Ганиева, Д.Сибгатуллина һ.б. галим-методистлар белән берлектә барлык дәреслекләр өр-яңадан язылды, алар озын гомерле булды. Чирек гасыр дәвамында укучылар шушы дәреслекләр, әсбаплар ярдәмендә әдәбиятыбыз хакындагы белем белән коралланды. Моның өчен А.Әхмәдуллинга К.Насыйри исемендәге бүләк тә бирелде.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.

Җиһан байый

Швейцариянең Credit Suisse банкы белгечләренең чираттагы Global Wealth Report докладында 2021 елда дөнья-күләм байлыкның 9,8 процентка артуы күрсәтелгән. Узган ел нәтиҗәләре буенча дөньядагы байлыкның тулай күләме 463,6 триллион доллар тәшкил иткән, миллио-нерлар саны 62,5 миллионнан арткан. Халыкның байлыгы җан башына уртача 87 489 долларга җиткән, бу аннан алда-гы елдагыдан 8,4 процентка югарырак. Credit Suisse билгеләп үтүенчә, 2021 елда муллык җиһанның бар төбәкләрендә дә арткан. Бигрәк тә зур үсеш Төньяк Америкада һәм Кытайда теркәлгән. Долларның кыйммәтләнүе исә Европа, Африка, Һиндстан һәм Латин Америкасында байлык-ның артуын бераз киметкән. Җан башына туры килгән уртача байлык күләме буенча беренче урында Швейцария бара (696,6 мең доллар), икенче урында – АКШ (579 мең доллар), аннары – Гонконг (552, 9 мең доллар). 2021 елда халыкның җан башына күчереп санаганда иң зур бай-лык туплаган илләр егермелегенә тагын Австралия, Яңа Зеландия, Дания, Канада, Нидерланд, Швеция, Бельгия, Сингапур, Норвегия, Франция, Бөекбритания, Тай-вань, Израиль, Германия, Ирландия, Ав-стрия һәм Япония кертелгән. Россиядәге байлык күләме хәзер Америкадагы 1908 елгы күрсәткечкә тиң һәм 2026 елга кадәр АКШта 1908 елдан 1912 елга кадәрге кебек үк үсәчәк. 2000-2021 елларда Кы-тайда муллык арту динамикасы АКШ та 1925 елдан алып 80 ел эчендә арткан кадәр үк булып чыккан. Банк фаразлавы буенча, Кытай якындагы биш елда Аме-рика артыннан куалавын уңышлы дәвам итәчәк һәм тулаем байлыгы күләмен 119 триллион долларга җиткерәчәк. 2022 ел фаразларына килгәндә исә, Украинада-гы хәрби конфликт дөньякүләм муллык артуын якындагы берничә елга акрынай-тачак. Хәер, 2026 елга җиһандагы байлык күләме тагын 169 триллион долларга артачак (2021 ел белән чагыштырганда 36 процентка). Биш елдан соң миллионерлар саны 87 миллионга җитәчәк.

(**“Die Presse”**).

Җирдә бер көндә...

Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата... Җир планетасының 5 кыйтгасында-гы 193 илдә яшәүче якынча 7,97 миллиард кешенең кайсы уяна, кайберләре инде, киресенчә, йокларга ята... Һәр яңа көндә Җиребездә якынча 360 мең бәби туа... 18 миллионнан артык кеше Туган көнен билгеләп үтә... Тәүлек эчендә күктә 8,6 миллион тапкыр яшен ялтырый, бу кадәр энергияне эшкә җиксәң, зур бер шәһәрне яктыртырга җитәр иде. Көн буена плане-тадагы һәр инсанга 1414 әр тапкыр дущта коенып чыгарга җитәрлек яңгыр һәм кар ява... Бер агач бер тәүлектә ике кешегә җитәрлек кислород бүлеп чыгара... Бер көндә 142 мең яңа автомобиль җыела... Азиядә һәркем бер савыт тутырып, ә Европада – бер аш кашыгы дөге ашый... Җиһандагы һәммә кеше бергә бер көндә 800 миллион әфлисун, 1 миллиард алма, 1,5 миллиард банан ашап бетерә... Кытай-лар бер көндә 510 мең тонна дөге җыеп ала... Бөтен дөньяда барлыгы 1 700 000 тонна җиләк-җимеш җыела... Планетада-гы тавыклар барлыгы 190 миллион данә йомырка сала... Дөньяда 339 миллион кеше симезлектән, ә моннан өч тапкыр артыграк кеше ачлыктан интегә. Җиһан халкы бер көндә барлыгы 570 мең телеви-зор, 3,4 миллион телефон, 540 миллион(!) газета сатып ала һәм товар өчен 182 төрле валюта белән түли... Көн буена барлыгы 2753 китап басыла... Һиндстанда һәр кич-не 10,7 миллион кеше кинотеатрда фильм карый... 24 сәгатьтә Җир халкы өчен Кояш бер тапкыр чыга һәм бер тапкыр бата, ә менә Халыкара космик станциядәге кос-монавтлар шул ук вакыт эчендә аның 16 тапкыр чыгып, 16 тапкыр батуын күрә...

(**“Интересно.cc”**).

Чама белү кирәк

АКШтагы Джорджтаун университеты медицина үзәге тикшеренүчеләре, 40-65 яшьлек 76 мең хатын-кызның сәламәтле-леген күзәтеп, төрле ризыкларның буыннар-га тәэсирен өйрәнгән. Сынау җитәкчесе профессор Кристофер Коллинз әйтүенчә, әлегәчә иң файдалы эчемлек, иң куәтле антиоксидантлардан саналган кара чәйне көненә 4 чынаяктан күбрәк куллану ха-тын-кызларда ревматоид артрит башлану ихтималын күпкә арттыра. Әмма профес-сор кара чәйдән баш тартырга өндәми, чөнки анда файдалы матдәләр дә бик күп. Шунлыктан иң яхшысы – кара чәйне көненә 1-2 чынаяк эчеп, калган вакытта яшел чәй белән сыйлану, анысының буын-нарга зыяны юк.

(**“The Guardian”**).

Кесә тулы ...алмаз

Җирдә табигый алмазлар бары тик бер урында гына – вулкан авызында гына табыла. Алар йөзләрчә чакрым тирәнлек-тә гаять зур басым астында бик югары температурада ясала, вулкан атылганда исә җиргә ыргытыла. Шулай булса да, безнең планетада алмаз шулкадәр күп ки, ул Җир шарындагы һәрбер кешегә берәр кесә туры килер иде.

(**“NEWS ru. com”**).

Кокаин короле

Ул Колумбиядә бик фәкыйрь гаиләдә туган, әмма тора-бара дөньяның иң бай һәм йогынтылы кешеләреннән берсенә әйләнгән. Пабло Эскобар тарихка сәясәтче булып түгел, бәлки танылган наркобарон булып кергән. Кокаин короле үзенең законсыз эшчәнлеген яшермәгән. Дөньядагы кока-ин базарының 80 проценты өчен җаваплы булып, ул атна саен якынча 420 миллион доллар эшләгән. Пабло контрабанда юлы белән АКШка һәр елны 15 әр тонна кокаин керткән. Үлем порошогы сатып, Эскобар картеле ел саен 22 миллиард долларга баеп барган. Ул елына 2 миллиард долларын югалткан да, тик бу аның өчен проблема тудырмаган. Саклау урыныдагы акчасын күселәр ашаган, су җебеткән яки югалган, шунлыктан ел саен мөлкәтенең 10 проценты чыгымнар исәбенә язылган. Ул ай саен купюраларны кыстыру өчен резинкаларга гына да 2,5 мең доллар акча тоткан. Бервакыт, ягылмый торган йортта кызы Мануэла өшегәч, аны җылыту өчен әтисе 2 миллион доллар акчасын яндырган. Эскобар җиде ел буе – 1987-1993 – Forbes журна-лының миллиардерлар исемлегенә кертелгән. 1991 елда наркобаронны үз проекты буенча салынган La Cafedral төрмәсенә утырткannар, ул зинданнан бигрәк затлы клубны хәтерләткән: бассейн, бию мәйданчыгы, джакузи, сауна, футбол кыры – нәрсә генә булмаган анда! Туганнары һәм дуслары Эскобар янына теләсә кайчан бара алган, ә менә Колумбия хакимияте вәкилләренә төрмәгә биш километрдан якынрак килү тыелган. Әмма кеше кайгысында тупланган акчаның рәхәтен күрергә язмаган: төр-мәдән качып, яшеренеп йөргәндә полиция аның эзенә төшкән һәм Эскобар 1993 елда 44 яшендә атып үтерелгән.

(**“ИнтересNIK”**).

Канатлы пехота

Немецларның котын алган, “рус фанер” кушаматы тагылган У-2 җиңел моторлы самолетларын 1941 елның июлендә Ленинград-тан Казанга эвакуацияләнгән 387 нче завод җитештергән. Күчеп урнашып 1 атна үткәннән соң ук, Казанда җыелган беренче очкыч һавага күтәрелгән. План буенча көн саен 8 машина җыелырга тиеш булган, кайбер көннәрне исә 10-12 шәрне дә җыйганнар. 1944 елда очкыч исемен аны уйлап та-бучы авиаконструктор Николай Поликарпов хөрмәтенә По-2 дип үзгәрткәннәр. Бөек Ватан су-гышы елларында Казан заводында барлыгы 11 334 самолет җыелган (9 746 җиңел төнге По-2ВС бом-бардировщигы һәм 1588 По-2С санитар очкычы), эш тәүлек буе туктамаган. Гитлерчылар өчен әлеге төнге бомбардировщиклар артиллериядән дә куркынычрак булган – үзләренең тавышы да ишетелмәгән, тик килеп, бомбага тотып киткәннәр. Бәреп төше-релгән һәр самолет өчен немец солдатларына 5 мең марка һәм “тимер тәре” орденын биргәннәр. Совет бомбардировщикларының сугыштагы барлык очышларының 55 проценты Казанда җитеште-релгән По-2 бипланнарына туры килә. Рейхстаг өстендәге тәүге Җиңү байрагының иң беренче, иң атаклы фотосурәте дә По-2 бортыннан төшерелгән.

(**“АиФ”**).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

10 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00 «ШУЛЕР».. 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
14.45 «Татар халык җырлары».
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 20.00, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «ШУЛЕР». 16+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 0.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
12.05, 18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
15.30 «Заман көзгесе». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
19.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «УМНИК». 16+
15.00 «Еда здорового человека». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 Невский ковчег. Теория невозможного. Карл Булла.
8.00 Черные дыры. Белые пятна.
8.45 «КРАЖА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «А что у вас?» Сергей Михалков».
12.15 «Молнии рождаются на земле. Телевизионная система «Орбита».
13.00 Линия жизни. Александр Чубарьян.
14.00 «Мир за горами».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.25 «ВСЯ КОРОЛЕВСКАЯ РАТЬ».
17.40 «Шри-Ланка. Маунт Лавиния».
18.10 Солисты XXI века. Константин Емельянов.
19.00 Уроки русского. Чтения. Михаил Зощенко. «Встреча», «Прелести культуры», «Последняя неприятность». Читает Иван Стебунов.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Александр Дворкин. «Манипуляция сознанием в деструктивных группах».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 «Джентльменский ад. История одного концлагеря».
21.40 «Сати. Нескучная классика...»
22.20 «СПРУТ-3».
23.20 «Запечатленное время».
23.45 Цвет времени. Эдгар Дега.

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Сишәмбе

11 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
21.00, 0.15 «Соотечественники». 12+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
15.30 «Ватандашлар». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «УМНИК». 16+
15.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Короли Европы в последней битве за Англию».
8.45 «КРАЖА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Оленёнок». «Моржи». «Краснозобая казарка».
12.00 «Первые в мире».
12.20, 22.20 «СПРУТ-3».
13.20 «Игра в бисер» «Гайто Газданов. «Вечер у Клэр».
14.05 «Жизнь и смерть Чайковского».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
16.35 «ВСЯ КОРОЛЕВСКАЯ РАТЬ».
17.45 «Ярославль. Замок Никиты Понизовкина».
18.10 Солисты XXI века. Филипп Копачевский.
19.00 Уроки русского. Чтения. Надежда Тэффи. «Выбор креста», «Ревность». Читает Ольга Тумайкина.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Екатерина Гресь. «Любовь с точки зрения философии».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Искусственный отбор.
21.40 «Белая студия».
23.20 «Запечатленное время».
23.45 Цвет времени. Тициан.

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Чәршәмбе

12 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Туган авылым». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
17.00 Хоккей. «Металлург» - «Ак Барс». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
21.00 Документальный фильм. 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30, 0.15 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «УМНИК». 16+
15.00 «Еда здорового человека». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Короли Европы в последней битве за Англию».
8.45, 16.35 «ВСЯ КОРОЛЕВСКАЯ РАТЬ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 Муз/ф «Карамболина-Карамболетта».
12.20 «СПРУТ-3».
13.15 «Первые в мире».
13.30 Искусственный отбор.
14.15 «Джентльменский ад. История одного концлагеря».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Настоящее-прошедшее. Поиски и находки».
15.50 «Белая студия».
17.35 «Франция. Замок Шенонсо».
18.00 Солисты XXI века. Даниил Трифонов.
19.00 Уроки русского. Чтения. Аркадий Аверченко. «Здание на песке», «Знаток женского сердца». Читает Вячеслав Ковалёв.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Иван Хватов. «Эволюционное происхождение психики».
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Абсолютный слух.
21.40 Власть факта. «Доктрина Монро».
22.20 «СПРУТ-4».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Пәнҗешәмбе

13 октябрь
«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35 «Татар халык җырлары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00, 23.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
14.45 «Татар халык җырлары».
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+
0.55 «Если хочешь быть здоровым». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.30, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.30 «Кунак БИТ Шоу». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30, 0.15 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
19.15, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Йөрәктән-йөрәккә». И.Биктаһиров турында телеочерк. 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «УМНИК». 16+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Кавказский пленник». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+

21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.40, 10.00, 15.00, 19.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Короли Европы в последней битве за Англию».
8.45 «ВСЯ КОРОЛЕВСКАЯ РАТЬ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «Киноактриса Лидия Смирнова».
12.10 Цвет времени. Карандаш.
12.20, 22.20 «СПРУТ-4».
14.00 «Первые в мире».
14.15 «Франческа и Юра. Эпизод вечности».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Встреча в Абрамцеве».
15.45 «2 Верник 2».
16.40 «ЖИГОЛО И ЖИГОЛЕТТА».
17.20 Большие и маленькие.
19.45 Главная роль.
20.05 «Семинар». Александр Каплан. «Природа воли человека. Наши действия - это свободный выбор или расчет мозга?»
20.45 «Спокойной ночи, малыши!»
21.00 Открытая книга. Павел Басинский. «Подлинная история Анны Карениной».
21.25 Цвет времени. Ар-деко.
21.40 «Энигма. Андрей Хржановский».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК. СВОЯ ЗЕМЛЯ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Җомга

14 октябрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Татар халык җырлары».
5.50, 7.00, 7.00, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.30 «БЕР-БЕР ХӘЛ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
17.00 Хоккей. «Автомобилист» - «Ак Барс». 6+
20.00 «Туган җир». 12+
21.00 «Юлчы». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.00 «ХОРОШИЙ ДОКТОР».. 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Рабис Саләхов турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 21.25 «Әниемнең җылы кочагы». 6+
19.15 «Туган җир». 12+
19.40 «Заман көзгесе». 6+
20.10, 22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «СОБЛАЗН». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ПЛУТОВСТВО, ИЛИ ХВОСТ ВИЛЯЕТ СОБАКОЙ». 12+
15.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
15.30 «Мировой рынок». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Фантастика. 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.45 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.40 Новости культуры.
6.35 Святыни христианского мира. «Покров».
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Петр Великий. История с французским акцентом».
8.25 «Шри-Ланка. Маунт Лавиния».
8.55 «ВСЯ КОРОЛЕВСКАЯ РАТЬ».
10.20 «ЛЕРМОНТОВ».
11.55 Открытая книга. Павел Басинский. «Подлинная история Анны Карениной».
12.25 «СПРУТ-4».
14.05 Цвет времени. Михаил Врубель.
14.15 Власть факта. «Доктрина Монро».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Андрей Хржановский».
16.20 «ГРАН-ПА».
17.45 Солисты XXI века. Дмитрий Шишкин.
18.45 «Царская ложа».
19.45 Искатели. «Куда пропал Самсон?»
20.30 Линия жизни. Александр Аузан.
21.25 «НЕПОДСУДЕН».
22.50 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
11.00 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Шимбә

15 октябрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Татар халык җырлары».
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 Концерт «Безнең заман - наше время». 6+
14.30 «ЧАРОДЕЙКА».. 12+
16.20 «Өмет йолдызы». Эльмира Кәлимуллина концерты. 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый миру». 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.15 «ПУТЕШЕСТВИЕ ВО ВЛЮБЛЁННОСТЬ».. 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Рабис Саләхов турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 Спектакль «Кодача». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Гомер китабы». Лилия Муллагалиева концерты. 6+
23.10 Спектакль «Йосыф-Зөләйха». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Россия. Связь времен». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.10 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «В ОТРАЖЕНИИ ТЕБЯ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «МУШКЕТЕРЫ. НЕИЗВЕСТНАЯ МИССИЯ». 16+
15.00 «Клятва Гиппократа». 12+
15.30 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «МАДАМ». 16+
22.40 «ХИМИК». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Видели видео?»
14.35 «А У НАС ВО ДВОРЕ...» 12+
16.45 «Донбасс. Дорога домой». 16+
18.20 «Ледниковый период. Снова вместе».
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.45 «Мой друг Жванецкий». 12+
0.40 «Великие династии. Воронцовы». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.50 «Доктор Мясников». 12+
12.55 «ЗАТМЕНИЕ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ДЕВЯТЫЙ ВАЛ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.20 «ОДНАЖДЫ ЛЕТОМ».
9.35 «Мы - грамотеи!»
10.15 Неизвестные маршруты России. «Томская область. От Томска до Васюганских болот».
10.55 «НЕПОДСУДЕН».
12.20 «Эрмитаж».
12.50 Черные дыры. Белые пятна.
13.30 «Великие мифы. Одиссея».
14.00 «Корсика - между небом и морем».
14.55 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.15 «Рядом с медведями. Дневник воздушной экспедиции».
17.15 «СКАЗАНИЕ О СИЯВУШЕ».
20.15 «Энциклопедия загадок».
20.45 «ВЕРТИКАЛЬ».
22.00 «Агора». с Михаилом Швыдким.
23.00 Клуб «Шаболовка, 37».
23.55 «В КЕЙПТАУНСКОМ ПОРТУ...»

«НТВ»
5.10 «Спето в СССР». 12+
5.55 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.20 «Шоу Аватар». 12+
23.00 «Ты не поверишь!» 16+

Якшәмбе

16 октябрь «ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Татар халык җырлары».
6.00 «Ничек сезнең хәлләрегез?» Зәйнәб Фәрхетдинова концерты. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 «Полосатая зебра».
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.20 Раяз Фасихов концерты. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 Концерт «Безнең заман - наше время». 6+
14.30 Хоккей. «Трактор» - «Ак Барс». 6+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ПАРИЖ! ПАРИЖ!». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 Спектакль «Ничек кияүгә чыгарга?» 12+
9.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Габделҗаббар Кандалый турында телеочерк. 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «ҮКСЕЗЛӘР».. 12+
14.50 «Йөрәк җылысы». Филүс Каһиров концерты. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 Спектакль «Кояш төшмәгән җирдә». 12+
23.20 «Шаян хәлләр». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30 «Россия. Связь времен». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «МАДАМ». 16+
14.35 «Мертвые души. Дело Холостякова». 12+
15.30 «В ОТРАЖЕНИИ ТЕБЯ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «МУШКЕТЕРЫ. НЕИЗВЕСТНАЯ МИССИЯ». 16+
23.00 «ЖЕНЩИНА В ЗОЛОТОМ». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.25, 6.10 «МОЯ МАМА - НЕВЕСТА». 12+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.45 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 «Жизнь своих». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.40 «УБОЙНАЯ СИЛА». 16+
16.45, 23.45 «Романовы». 12+
18.50 «Поем на кухне всей страной». 12+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»

«РОССИЯ»
5.35 «МОЙ ЧУЖОЙ РЕБЁНОК». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
11.50 «Большие перемены».
12.55 «ЗАТМЕНИЕ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Энциклопедия загадок».
7.00 Мультфильмы.
8.30 «ВЕРТИКАЛЬ».
9.45 «Обыкновенный концерт».
10.15 Диалоги о животных.
10.55 Большие и маленькие.
13.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Николай Путилов.
13.30 «Игра в бисер» «Томас Манн. «Иосиф и его братья».
14.15 «Элементы» с Ильёй Доронченковым».
14.45 «РИМЛЯНКА».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.15 «Пешком...»
17.45 Передача знаний.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 «Это я и музыка...»
20.50 «БАРЫШНЯ-КРЕСТЬЯНКА».
22.40 «Коппелия».

«НТВ»
5.00 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
6.35 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер!» 6+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Сәрхушларның тормыш агышы

1981 елда туган Рафаэль Шадров Урыссу бистәсендә мәгълүм зат. Яхшы гамәлләре белән түгел, явызлыклар кылып танылган ул. Яшүсмер чагында җиңелчә җинаятьләр кылса, 2004 елда Ютазы районын шаулаткан ерткычлык эшли һәм Татарстан Югары суды тарафыннан балигъ булмаган кызны көчләргә омтылыш ясау һәм кыргыйларча үтерүдә гаепләнеп 17 елга ирегеннән мәхрүм ителә. Түбән Новгород өлкәсендәге Тоншаево колониясеннән 2019 елда иртәрәк азат ителеп Урыссуга кайткач та, урлап тотылып, шартлы хөкем алырга өлгерә. Димәк ки, Ютазы районы полициясендә даими исәптә тора ул.

Р.Шадровның Урыссуга кайтуы районда ышанычсыз сәрхушлар саны артуны белдерә. Әлбәттә, үзе кебекләр белән аралаша ул. Әйтик, торак-коммуналь хуҗалыгында эшләп йөргәндә, урлаган өчен мәҗбүри эшләргә хөкем ителеп шунда җибәрелгән 1985 елгы Дмитрий Малолеткин белән дуслаша. Шулай ук алар даирәсендә бераз өлкәнрәк Руслан Ферару, Ләйсән һәм Надежда атлы ике хатын-кыз да була. Бәян ителәчәк вакыйгаларга катнашы булмаган башка шешәдәшләрне санап тормыйк.

Узган елның 30 апрелендә кичкә таба «Авоська» кибете янында Д. Малолеткин белән Ләйсәнне очрата ул. Дмитрий бу көнне район үзәге урамнарын буйлап, аз-маз салгалап уздыруын, ошбу ханым белән эчәргә җай чыгарырга йөрүләрен әйтә. Шундый ук теләгә булган Рафаэль дә очрагач, уртак хыяллар тормышка аша, сәрхушлар Шадров фатирында сыйланырга керешә. Эчә торгач алҗып киткән Дима бераздан залдагы диванга авып татлы йокыга тала. Күп тә үтми, шул бүлмәгә кереп чыккан Ләйсән хуҗага өйдәге вәзгыятьнең кискенләшүенә китергән яңалыкны ирештерә, ягъни Малолеткинның урын-җирне чылатуын, хәтта идәндә начар исле күлдәвек тә булуын әйтә.

Ошбу хәбәрнең хак икәнен үз күзләре белән күргәч бик кәефе кырылган Шадров тыелып кала алмыйча, юеш диванда берни булмагандай йокы симертүче оятсыз кунакны ныклап дөмбәсләргә керешә, аяк-кулларын эшкә җигеп, Димага урыныннан торырга ирек бирми, идәнгә егылып төшкәнче тукмый. Шулай да бер кавымнан арага кергән гүзәл затны тыңлап тынычлангандай итә. Ошбу тынлык озакка сузылмый, өчәүләп янә өстәл янына утыргач та чыланган чалбарлы шешәдәшкә тагын ике-өч мәртәбә тамызып ала. Курка калган хатын-кыз бу юлы бәдрәфкә үк кереп кача, шау-шулар тына төшү белән аннан чыккач, канга баткан башын ике куллап кочып чүгәләгән Малолеткинны күрә. Шул мәлдә пәйда булган Надежда хәлсез ир-атны җитәкләп подъездга озатып керә. Өч сәрхуш янәдан эчәргә керешә. Ләкин аңа кадәр Шадров, фатиры идәннәрен сөртеп, кан һәм башка биологик калдыкларны юк итә. Чөнки полиция килү мөмкинлеген чамалый.

Чыннан да кичке сәгать 9 лар тирәсендә анда ике полиция хезмәткәре килә, чөнки подъездда кыйналган мужик ята дип хәбәр итүчеләр була. Идәндәге кан таплары аларны Шадров фатирына алып керә. Салып утыручы өчлек күрмәдек, белмибез дигәч, ышанып, оперлар җыештырылган фатирдан чыгып китә. Һәм теге кешене ашыгыч ярдәм алып китүен ачыклагач, Урыссу район хастаханәсенә юнәләләр.

Йөзе-бите җимерелгән исерек һәм пычрак юеш киемле ир-атны колач җәеп каршы алмыйлар әлбәттә. Ашыгыч ярдәм фельдшеры: «Малолеткин подъезд баскычына егылдым дисә дә, йөзе-битендәге күп санлы җәрәхәтләре бер тапкыр бәрелү нәтиҗәсе генә түгел икәнен күрсәтеп тора иде»,- ди. Дмитрийны кабул иткән табиб исә: «Йөзендә һәм күз төбендә ике «гематома» бар иде, аны сырхауханәгә салырга нигез булмады, үзе дә баш тартты, дорфа сөйләште, үз аягында чыгып китте», - дип белдерә.

Сүз уңаеннан, соңрак үткәрелгән экспертиза нәтиҗәләре белән кыскача таныштырып үтик. Анда Д.Малолеткиндагы ачык рәвештәге баш сөяге травмасы, баш түбәсе һәм чигә сөякләре сыну, авыр дәрәҗәдәге баш бәрелү (ушиб), уң күзгә кан саву һәм кеше сәламәтлегенә нык зыян китергән башка җәрәхәтләр санап үтелә. Малолеткинның эше хөрти икәне шактый вакыт узгач кына мәгълүм була. Әйтергә кирәк, 30 апрель вакыйгасына полициядә әллә ни игътибар бирелми, төгәлрәге, кыйнау очрагы буенча билгесез кешегә карата административ эш ачтык дигән булсалар да, кыл да кыймылдатмыйлар дияргә мөмкин, чөнки Шадров кына түгел, Малолеткин белән сөйләшергә дә вакыт тапмыйлар.

Малолеткинның этисе әйтүенә караганда, малае битендәге «бизәкләр»не икенче көнне генә күрә ул. Берничә көннән аларның төсе үзгәрүе, димәк төзәлә баруы сизелә башлый. Туймазыга йөреп эшләүче өлкән кеше ул көннәрдә улының исерек килеш идәндә аунап ятканын да, аек чакларын да күрә, ләкин 6 майда, ягъни бер атна узгач кына, шөбһәгә төшә, чөнки улы ялгышып сөйләшә башлый, этисенә башка исем белән эндәшә, үз фатирында килеш өемә кайтам дип әйберләрен җыя башлый һ.б. Кичкә таба эти кеше ашыгыч ярдәм машинасы чакыра, ниһаять. Бөгелмәдә үткәрелгән томография тикшеренүе эшнең җитди икәнен күрсәткәч, Малолеткин «Татнефть» җәмгыятенең Әлмәттәге сырхауханәсенә салына, анда 11 көн ятканнан соң, Урыссу больницасына кайтарыла.

Әйтергә кирәк, 7 майда Әлмәт сырхауханәсеннән хәбәр килгәч тә, Ютазы районы полициясе бик җәһәт эш итә. Р. Шадров бик тиз тоткарлана, икенче көнне гаебен тануы турында «явка с повинной» яза. Сәрхуш хатыннар да шаһит булarak күрсәтмәләр бирә. Р.Шадров суд карары белән сак астына ябыла. Д.Малолеткинның этисе улының баш авыртуга зарлануын, сөйләмә тоткарлыклы була башлавын әйтеп, Шадровка кырыс җәза бирүне таләп итә.

Р.Шадровның Д.Малолеткин сәламәтлегенә авыр зыян китерүе шик уятмый. Ләкин аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүче Рөстәм Яруллин тагын бер җинаять эше кузгата. Чөнки Рафаэльнең 1 майда, димәк, Малолеткинны кыйнаганнан соң икенче көнне үк 1976 елгы Руслан Ферарунын да тетмәсен тетүе ачыклана. Бусы да сәрхуш тормыш рәвеше нәтиҗәсе була, билгеле.

Русланның әйтүенчә, аның өенә кич белән 26 яшьлек туганнан туган энесе Хәмзә Котлыев килә, агайнеләр кимендә берәр литр аракы чөмерә. 1 майда көндез исерек кунак йокларга түнә һәм өч-дүрт сәгатьтән аны Р.Шадров уятып, телефонын сорап ала, ашыгыч ярдәм, полициягә шалтырата. Табиблар һәм формалы хезмәткәрләр бер-бер артлы килеп керә. Исерекләрнең бусын да, сырхауханәнең кабул итү бүлмәсеннән ары уздырмыйча, өенә кайтарып җибәрәләр, ләкин Руслан Ферару башындагы яраны эшкәртеп, җиде җирдән тегеп куялар.

Р.Шадров, шул ук Ләйсәнне иярттеп, Руслан өенә төштән соң килеп керә. Салып утырганда, хуҗа Шадровны элеккеге «мәгъшука»сы Надежда белән якыннан аралашуда гаепли башлый. Алдагы көнне Малолеткинны кыйнап та җәзасыз калган Шадров агач уклау белән башына тондырып, аны идәнгә тәгәрәтә. Күрсәң, үлә дип курка, әйтелгәнчә, кирәкле хезмәткәрләргә хәбәр итә.

Шадров беренче күрсәтмәләрендә Ферару кулына пычак алгач сукты дип үзен һөҗүмнән саклнучы итеп күрсәтә, аннан соң гаебен бөтенләй кире кага, күрсәтмә бирүдән баш тарта. Төп шаһит Ләйсән һәм Руслан үзе пычак тотуны кире кагалар. Шул рәвешле, Рөстәм Яруллин Р.Шадровка кеше сәламәтлегенә җиңел дәрәҗәдәге зыян китерү хакындагы тагын бер гаепләү белдерә. Ютазы район суды аны ике җинаять кылуда гаепле дип табып 5 елга ирегеннән мәхрүм итә.

* * *

Буа районыдагы Иске Тинчәләдә булган җинаять тә хәмер ярдәменнән башка гына килеп чыкмаган. 2012 елда әлеге татар авылындагы иске йортка Чуашстанның Канаш районыннан килгән Николай Николаев оялый. 1959 елгы абзый узган кышта икенче бер ташландык хуҗалыктагы мунчада көн күрә башлый. Әйтүенә караганда, аны утын ягып җылытып, шул ук мичтә ашарга пешереп була, кыскасы, ләүкәдә йоклап, чын сукбайларча яши ул. Рәсми кәгазьләрдә элек хөкемгә тартылганы булса да, хәзер үзен тәртипле тотуы, авылда канәгатьләнерлек бәяләнүе әйтелә аның. Әмма җирле халык арасында ошбу килмешәктән шикләнүчеләр бар. Әйтик, 1961 елгы Җәмил агай өендәге телефоны юкка чыгуын, дәлилләре булмаса да, аннан күрә. Башка кеше урларга тиеш түгел дип белдерә. Агайның ошбу бәяне авылдашы Гомәр Фәйзуллинны аклау йөзеннән уйлап чыгарылган дигән уйга да этәрә. Чөнки инде 64 яшендәге Гомәр абзый Николаевка һөҗүм итеп, җинаять эше кузгатылгач кына искә алына ул. Г.Фәйзуллин исә сукбай картны кесә фонарен чәлдерүдә гаепли.

Быел 3 мартта шушы мәсьәләне ачыклау йөзеннән барып керә ул мунчага. Аек баштан түгел, билгеле. Үзе 150 г эчтем дисә дә, дусты Җәмил икебезгә бер яртыны сындырдык ди. Николай да салмыш иде, тикмәгә генә кермәвен аңладым, ди. Чыннан да, Г.Фәйзуллин аңа авыл өйләреннән вак-төяк әйберләр, азык-төлек урлануы турында әйтә, кем эше, дигән сорауны ирештерә. Сукбай бурлыкларга катнашым юк дигәч, мич өстендәге 4-5 иске телефонны алып урамга, Җәмил дусты янына чыга. Г. Фәйзуллин Җәмил үзенең урланган телефонын танып алды дип сөйли. Җәмил, күрәсең, мәшәкатьтән башаяк дип, әлеге очрашуны кире кага. Николай исә эшләми торган бу аппаратларны электр тоташтырылмаган мунчада яктырткыч итеп кенә файдалануын әйтә.

Сүз уңаеннан, «разборка»га кергән Гомәр Фәйзуллинның, 2004 елда кеше үтергән өчен, 5 елга утыртылып, Түбән Карамалыдагы колониядән ел ярым чамасы алдарак азат ителгән кеше икәнен искәртик. Мунчада хәлләр тиз кыза, татар абзый кесәсеннән пәке чыгара, чуаш карты кулына тимер кисәү алып, чакырылмаган кунакка сугып та куя. Һәм котырынган Гомәр пәкене эшкә җигә, күкрәк, эч тирәсенә кадый, качып котылырга тотынган Николайның аркасына да чәнчеп өлгерә, мунчадан чыгып ычкынган «дошман»ның артыннан ташлана, ләкин, үзенең әйтүенчә, салкын кермәсен өчен ишеккә эленгән одеялга уралып тоткарлана һәм Н. Николаевны күз уңаеннан югалта, өенә кайтып китә.

Агачлар артына яшеренгән Николай, 10-15 минуттан торагына кереп, «112» телефонына шалтырата. Күршедәге Яңа Тинчәләдән авыл фельдшеры И.Җаббарова килеп җитә. Илмира канга манчылган абзыйның, сулыш алганда гырлавы буенча, үпкәсе яралануын шунда ук аңлый. Чыннан да, Буа сырхауханәсендә Н. Николаевтагы җиде үтәли җәрәхәтнең икесе сул үпкәгә, берсе бавырга кадәр кереп җитүе мәгълүм була. Суд-медицина эксперты әлеге өч яраны сәламәтлеккә авыр зыян китергән дип таба, калак сөяге, бил, боттагы ике яра җиңелчә булып чыга.

Салмыш тормыш агышы гомер көзендә ташландык мунчага китергән Н.Николаевны табиблар аякка бастыра. Шул ук эчкечелек аркасында юк сәбәптән бар булган вакыйга ялгызак Г.Фәйзуллин өчен дә фаҗигале тәгәлләнә. Тикшерү комитетының Буа районара бүлеге җитәкчесе урынбасары Дамир Әскаров аңа аңлы рәвештә кеше үтерүгә омтылыш ясауда гаепләү белдерә. Зарар күрүченең качып китүе һәм вакытында ярдәм күрсәтелүе аркасында гына исән калуы бәхәссез бит. Әлеге нәтиҗә Буа шәһәр судында да расланды: Г.Фәйзуллинга 6 ел ярым гомерен тимерчыбыклы коймa артында кырыс режимлы колониядә уздырырга туры киләчәк.

Наил ВАХИТОВ.

Иҗатында – яшәү яме

Төркиянең танылган рәссамы Ялчын Гөкчәбаг әсәрләреннән гыйбарәт «Үткәннәр озакка сузыла...» күргәзмәсе «Хәзинә» милли сәнгать галереясында 30 октябрьга кадәр дәвам итә. Ул Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музее һәм Төркиянең Казандагы генераль илчелеге тарафыннан оештырылды.

Илебез сәнгатьсөярләре аның картиналарын беренче тапкыр тамаша кыла. Югыйсә ул инде җитмешләп күргәзмәдә катнашкан оста. Шуларның унҗидесе – шәхси күргәзмәләр! Алар Төркия шәһәрләреннән тыш Лондонда, Скопье, Париж, Оман, Димәшкъ һ.б. калаларда да узганнар.

Рәссам 1944 елда Денизли провинциясендә туган. 1963 елда Анкараның Гази педагогика институтындагы сынлы сәнгать бүлеген уңышлы тәмамлый. 1990 елдан алып, Якын Көнчыгыш техник университетының сынлы сәнгать факультетында белем бирә башлый. Ялчын әфәнде төрле бәйгеләрдә җиңү яулый. Ул сәнгать һәм сынчылык өлкәсендәге дәүләт премиясе лауреаты да.

Оста үз әсәрләрен табигатькә, авыл тормышына багышлый. Алар барысы да ачык, якты төсләргә бай. Рәссамның әтисе Таһир укытучы булган. Әнисе – хуҗабикә. Я.Гөкчәбагның балачагы да авылдагы кечкенә йортта узган. «Мин гомерем буе тырышып хезмәт куйдым. Еш кына үз-үземә: «Без кемнәр? Бу җиргә ни өчен килгәнбез?» – дигән сорауларны бирдем. Бар да үтә дә китә... Шуңа күрә узып барган вакыт мөһим дә, кадерле дә. Сынлы сәнгатьтә мин үз балачагымны, авыл тормышын сурәтлим, алар минем өчен барыннан да мөһимрәк. Авылны җаным-тәнем белән сөям. Уй-фикерләрем белән мин әле дә шунда... Әйе, иҗатыма йогынты ясаган вакыйга да булды. 1974 елда җәмәгатем белән дуслардан, кунактан кайтып барганда, безне ыжгырып килүче машина бәрдерде. Бик җәрәхәтләндек, сөякләр сынган иде. Без хастаханәдә дә, өйдә дә озак яттык, гипста йөрдек. Шушы авыр вакыйгага кадәр мин озак вакыт абстракцияләр ясый идем һәм алар өчен төксе, авыр төсләр сайлый идем. Һәм менә шушы фаҗигадән соң тормышның искиткеч матур булуына, дөньяда яшәгән һәр көннең кадерле булуына төшендем, яшәү ямен аңладым. Мин, кош кебек, җирдәге бар мәхлуклар өстенә карап алдым төсле һәм авыл тормышының бар мизгелләрен дә барладым шикелле. Иҗатым миниатюраларны хәтерләтсә дә, барыбер башкача ул. 1975 елдан башлап озак еллар шушы юнәлештә иҗат иттем. Мин инде 64 ел шушы сәфәрдә. 3500-4000 гә якын картинамны киндерләргә майлы буяулар белән ясадым. Димәк, минем 3500 өлешем кемнәрнедер шатландыра. Бу – минем үзем өчен дә бәхет», – дип аңлата рәссам.

Ялчын әфәнде Анкараның «Армони» галереясендә эшли. Истанбулдагы үз остаханәсендә дә иҗат итә.«Озак еллар телеоператор булып эшләдем, шуңа күрә яктылыкны ничек күрсәтеп бирергә кирәклеген яхшы беләм. Еш кына һәрнәрсәгә өстән караган кебек карыйм. Чөнки еш кына вертолёттан камерага төшергә туры килде», – ди Я.Гөкчәбаг үз иҗаты үзенчәлекләрен барлап.

Күргәзмә тамашачылары бик үзенчәлекле өслүбтәге картиналарның җиңел һәм аңлаешлы булуын ошаталар. Рәссамның нәфис сызыклар белән оста эшли белүенә сокланалар. Аның әсәрләре тормышка дан җырлаган әсәрләр дип бәяләнә. Рәссамның бар картиналары да ватанына ихлас мәхәббәт белән сугарылганга күрә, күргәзмәне караучылар арасында Төркиягә гашыйк булучылар саны да артуы шик уятмый.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.



Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 30.09.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2773

16+